В 1261 г. мамлюкский султан Бейбарс провозгласил себя правителем Египта и Сирии. При этом титул халифа Бейбарс принять не мог, так как не имел на него прав. Выходом из сложившейся ситуации стало провозглашение халифом Абуль-Аббаса ал-Мунтансира, который был представителем династии Аббасидов, правившей в Арабском халифате. Но вскоре он был убит, новым халифом стал ал-Хаким. Таким образом, в Мамлюкском султанате сложилось формальное двоевластие, хотя халиф фактически не обладал никакими полномочиями, а был скорее церемониальным лицом.

После смерти золотоордынского хана Берке исламский фактор в отношении двух стран стал ослабевать в виду того, что последующие правители в этом государстве вернулись к вере своих предков. Однако дипломатические отношения между странами не прекратились.

После вступления на золотоордынский трон Узбек хана религиозный фактор в межгосударственных отношениях с мусульманскими странами снова стал одним из основополагающих. Особенно это ясно отразилось на страницах средневековых арабских летописей, которые отмечали особую приверженность золотоордынского правителя Узбек хана к распространению ислама. В 1314 г. в Каир прибывают золотоордынские послы с письмом для мамлюкского султана, в котором наряду с поздравлениями о расширении земель мамлюкского султана (речь тут скорее всего идет о победоносной битве армии ан-Насира в Мардж ас-Саффаре) также подчеркивается что Узбек хан проводил жесткую политику в отношении исламизации ордынской элиты [Тизенгаузен: 1884. С. 163, 437]. Со ссылкой на Ибн Касира, арабский летописец ал-Асади сообщает: «закон мухамеданский (шариат – С.Э.) стал там выше всех (других) законов. Он (Узбек)

устроил себе мечеть соборную, в которой совершал пять (установленных) молитв» [Тизенгаузен: 1884. С. 446].

В 1323 г. золотоордынские послы, прибывшие к мамлюкам в Каир, привезли письмо, в котором запрашивалась религиозная литература богословов шафиитского толка: «Джами ал-усул фи ахадис ар-расул» Маджетдина Абу ас-Саадата бин Асира (1150–1210), «Китаб шарх ас-сунна» Абу Мухаммад ал-Хусейна бин Масгуда ал-Багави (родился примерно 433 г.х – ум. 516 г.х); книгу шафиитского правоведа ар-Равьяни – «Китаб ал-Бахр ал-мазхаб» [Амин аль-Холи: 2002. С. 37].

Первая книга «Джами ал-усул фи ахадис ар-расул» Маджетдина Абу ас-Саадата бин Асира (1150–1210) – это сборник хадисов, источниками которого стали общепризнанные сочинения «Муватта» Ибн Малика, а также «Сахих» ал-Бухари и «Сахих» Муслима. Автор сборника, Маджетдин Ибн Асир, был братом известного историка Ибн Асира, который описал нашествие монголов на Среднюю Азию, Волжскую Булгарию, Русь и другие земли. Его летописный труд «Камил фи-т тарих» на сегодняшний день считается одним из важных средневековых арабских источников. Что же касается биографических сведений о Маджетдине Ибн Асире, то известно, что его семья происходила из знатного арабского племени, когда он подрос, отправился в Багдад, где получил знания от видных ученых своего времени. Маджетдин Ибн Асир также занимал высокое положение при дворе знатного эмира города Мосула Муджахида ад-Дина Каймаза.

Второе сочинение – запрошенное ордынцами в Каире, известное в мусульманском хадисоведении – «Китаб шарх ас-сунна» Абу Мухаммад ал-Хусейна бин Масгуда ал-Багави (родился примерно 433 г.х – ум. 516 г.х). Это сборник хадисов, выбранных из авторитетных «Сахих»ов ал-Бухари и Муслима и сформированных согласно определенным темам. Его автор, Хусейн ал-Багави, родился в городе Бага. Когда ему исполнилось 17, уехал из Бага в г. Марваруз, где стал изучать все направления религиозной догматики и мазхабы, впоследствии став приверженцем мазхаба имама аш-Шафи'и. Свои знания по мусульманскому фикху он получил у шафиитского улема кади Хусейна ибн Мухаммада ал-Марварузи. Самым известным из трудов ал-Багави является толкование Корана «Маалим ат-Танзил», который более известен как «Тафсир ал-Багави». Также он является автором сборника хадисов «Масабих ас-Сунна», который затем стал известен вместе с дополнениями ат-Табризи как «Мишкат ал-масабих». Сборник хадисов «Масабих ас-Сунна» стал одним из основных источников религиозно-дидактического сочинения золотоордынской эпохи «Нахдж ал-Фарадис» (1358 г.). Автор «Нахдж ал-Фарадис» Махмуд ал-Булгари чаще всего ссылался на этот сборник хадисов в

первой главе сочинения, повествующей о жизни и достоинствах пророка Мухаммада. В фондах Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского КФУ хранятся две рукописи «Масабих ас-сунна». Одна из них под номером 782-Т была переписана в Багдаде в 1358 г., другая под номером 747-Г в Египте в 1379 г. [Сайфетдинова: 2018. С. 65].

Третья книга шафиитского правоведа ар-Равьяни (ар-Руяни) (415 г.х. – 502 г.х.) – «Китаб ал-бахр ал-мазхаб», представляет собой сочинение по мусульманской юриспруденции (фикху). Фахр ал-Ислам Абу ал-Махасин Абд ал-Вахед бин Исмаил ар-Равьяни (ар-Руяни) являлся кади (судьей) шафиитского толка. Происходил из города Равьяна (Руяна), расположенного на севере Ирана. Он с целью обретения знаний и хадисов путешествовал в Бухару, Амаль, Нишапур, Мерв. При помощи главного кади Табаристана построил в городе Амале медресе, в котором преподавал основы мусульманской религии и фикха.

Более подробная информация о книгах, которыми интересовались в Золотой Орде, указывает на то, что несмотря на следования традициям мазхаба Абу Ханифы, религиозные деятели там также изучали и основы шафиитского толка. Однако об интересе к двум другим мазхабам – маликиитскому и ханбалитскому данных нет.

Основанием для заключения, что шафиитский мазхаб также был распространен на территории золотоордынского государства, может быть и то, что тогда были установлены тесные дипломатические связи Орды с мамлюкским султанатом Египта, в котором мусульманское судопроизводство в большинстве случаев осуществлялось согласно шафиитскому толку. Считается, что шафиитский толк зародился именно в Египте, здесь похоронен и основатель этого мазхаба имам Мухаммад аш-Шафии, мавзолей которого до сих пор сохранился в Каире. Многие ученые и богословы приезжали в Золотую Орду с целью распространения мусульманского вероучения, также и золотоордынские ученые отправлялись в Каир за поиском религиозных знаний, многие из них добивались звания шейхов и преподавали в каирских медресе. Поскольку большинство мамлюков по своему происхождению были тюрками, их язык, традиции и обычаи стали проникать в общественно-политическую жизнь Египта. Так, например, во времена правления в Египте мамлюков, имеющих тюркское происхождение, наряду с применением законов шариата также в правовую систему был включена и яса[1]. Как отмечал египетский ученый Амин аль-Холи: «Татары-мамлюки принесли с собой ясак, или Яса,– законы

[1] Яса́, Великая Яса (закон великой власти) – уложение Чингиз хана, которое он, по преданию, издал на великом всемонгольском курултае и которое постоянно подтверждалось его преемниками.

Чингис-хана, записанные, как говорят на стальных пластинах» [Амин аль-Холи: 2002. С. 34]. Такая правовая система была принята и в Золотой Орде. Это конечно вызывало некоторые опасения у мусульманских правоведов, которые отмечали этот период как кризис фикха, который «ограничил сферу действий фикха: по законам фикха решались только вопросы личной жизни людей и дела о выполнении религиозных обрядов» [Амин аль-Холи: 2002. С. 36]. Включение мамлюками в судопроизводство Ясы Чингизхана в некоторой степени завуалировало авторитет шафиитского толка в Египте. Некоторые мамлюкские султаны увеличили число кадиев – представителей четырех правовых школ, чтобы исключить необходимость главенства одной из них. В частности, султан Малик ан-Насир провозглашал равенство всех мазхабов на территории султаната и построил четырехунванное медресе, чтобы в нем располагались все четыре суннитские школы права. В Золотой Орде, как нам кажется, также не требовалось следование догматам какой-то определенной суннитской правовой школы.

Арабский путешественник Ибн Баттута, приверженец маликитского мазхаба, побывав в Золотой Орде в 1333 г. отмечал: «Весной 1333 г. соборной (пятничной) в городе являлась мечеть ан-Насира[1] (не сохранилась); ее имамом являлся шафиит Абу Бакр. Наряду с Абу Бакром в круг «отцов города» входили: старший кади ханафит Шамс ад-дин ас-Са’или, кади-шафиит Хидр, правовед-наставник ‘Ала’ ад-дин ал-Аси. [Крамаровский: 2014. С. 65].

Таким образом, уже тогда, несмотря на доминирующее положение ханафитской правовой школы, статус шафиитского мазхаба также был высок. Как отмечал М.Г. Крамаровский: «В столичном Сарае, судя по количеству мечетей с ханафитскими и шафиитскими кафедрами, их положение не было равновесно, поскольку соотношение составляло 12:1 в пользу ханафитской школы. Господство ханафитского мазхаба подчеркнуто повторяющейся несколько раз у Ибн Баттуты фразой: «Они (Кипчаки) ханафитского толку….». [Там же. С. 65].

Согласно М.Г. Крамаровскому: «В XIII в. господство религиозно-правовой школы Абу-Ханифы в тюркской среде опиралось на малоазийскую традицию, которую в XI–XII вв. принесли в Анатолию среднеазиатские тюрки-сельджуки. Успешному продвижению ханафитского права способствовала относительная терпимость ханафитов к доисламским традициям тюркской степи. Ханафиты достаточно лояльно относились к

[1] Скорее всего мечеть эта связана с именем мамлюкского султана Мухаммада ан-Насира, который поддерживал отношения с Золотой Ордой и даже заключил династический брак с представительницей элитных кругов чингизидов. (Об этом подробнее [Сайфетдинова: 2017]).

представителям других религий – христианам и иудеям, что было существенно для этно-конфессиональной ситуации как в городах Рума, так и городах Золотой Орды. [Там же. С. 66].

По своим позициям шафиитский мазхаб занимает серединное место между ханафитским, маликитским и ханбалистским мазхабами. В шафиитском мазхабе основными источниками признаются Коран и Сунна, однако в некоторых вопросах разрешается единодушное мнение или решение авторитетных лиц по обсуждаемому вопросу.

В поэме «Каландар-наме» Абу Бакра Каландара Руми, созданной в Золотой Орде, воспеваются достоинства всех четырех основоположников мазхабов. Абу Ханифу этот источник называет «предводителем мазхаба и религии Посланника (Аллаха), Аш-Шафии «предводителем и господином сподвижников», Ахмада ибн Ханбала «предводителем богобоязненных», имама ал-Малика «жемчужиной в море знания, Был этот муж деятельным [и] весьма кротким» [Абу Бакр Каландар Руми: 2017. С. 55–56]. Создатель сочинения «Каландар-наме» воспевал достоинства всех правоведов и призывал оказывать почтение к каждому из них.

В сочинении золотоордынской эпохи «Нахдж ал-фарадис» («Путь в рай», 1358) Махмуда ал-Булгари отдельные разделы второй главы посвящены описанию достоинств основателей четырех имамов. Имама Абу Ханифу автор наделяет эпитетом «имам агзам» – «величайший имам» и более подробно останавливается на биографических сведениях о нем (его принадлежности к табигыйнам[1], предложений о назначении на должность кади города Багдада и др.), а также описывает примеры из правовой практики. Описывая достоинства имама аш-Шафии, он рассказывал о том, что сам почтенный имам Ахмад Ханбал ходил в учениках у тогда еще молодого аш-Шафии, «шел позади его коня и держал попону» [Махмуд ал-Булгари: 2019. С. 299], халиф Харун ар-Рашид разрешал свои семейные проблемы у него. Махмуд ал-Булгари тем самым показывал, что еще в юности аш-Шафии обладал широкими религиозными знаниями и рассудительностью. Фасл, рассказывающий об имаме Малике б. Анасе, лишь на треть текста посвящен описанию достоинств Малика б. Анаса, остальное составляют коранические сюжеты о пророках Сулеймане и Ибра'име, что дает возможность полагать, что Махмуд ал-Булгари не обладал большими биографическими сведениями о нем. В десятом разделе второй главы он подробно останавливается на перечислении религиозности и благонравственности Ахмада ибн Ханбала. При этом важно

---

1 **Табиин** (араб. اَلتَّابِعُونَ) (вариант написания: **таби'ин**) (ед. чсл. таби'ий) – следующее поколение за сахабами. Поколение мусульман, которые были учениками и последователями сподвижников пророка Мухаммада (с.а.в.), непосредственно не общавшиеся с Посланником Аллаха.

отметить, что золотоордынский писатель и религиозный деятель Махмуд ал-Булгари не ставил целью популяризировать какой-то один мазхаб и его основателя и не призывал придерживаться идеологии конкретного мазхаба.

Таким образом, средневековые письменные источники указывают на то, что на территории Золотой Орды наряду с популярным ханафитским мазхабом распространение получил и шафиитский мазхаб. О популярности двух других мазхабов (маликитского и ханбалистского) каких-либо конкретных сведений нет, хотя при совершении судопроизводства, согласно шариату, скорее всего участвовали кади всех четырех правовых суннитских школ. Такая потребность в функционировании всех четырех правовых школ была предопределена вероятно правовой системой Золотой Орды, которая представляла собой симбиоз обычного права кочевников, системы норм права, регламентированной монгольскими правителями Яса, (ярлыки) и применением мусульманского права.

## Литература


1. Абу Бакр Каландар Руми. Каландар-наме: избранное / Пер. с перс. И.Р. Гибадуллина, М.Р. Шамсимухаметовой; общая и научная редакция, предисловие, комментарии И.Р. Гибадуллина. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 1044 с.
2. Амин аль-Холи. Связь между Нилом и Волгой в XIII–XIV вв. Казань: Изд-во Иман, 2002. – 49 с.
3. Крамаровский М.Г. Ибн Баттута о тюркском исламе // Золотоордынское обозрение. 2014. № 1(3). С. 62–74.
4. Кул Гали. Сказание о Йусуфе. Казань, 1985.
5. Махмуд ал-Булгари. «Нахдж ал-Фарадис». Путь в рай. Перевод. Транскрипция. – Сокращенный перевод на русский язык И.Р. Гибадуллина, Э.Г. Сайфетдиновой, Э.Р. Галиуллиной; Транскрипция Ф.Ш. Нуриевой / Общая и научная редакция И.М. Миргалеева. – М.: Исламская книга, 2019. – 320 с.
6. Почекаев Р.Ю. Право Золотой Орды. Налогообложение. Придворный этикет и протокол // Золотая Орда в мировой истории. Коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ. С. 179–196.
7. Путешествие Ахмеда-Ибн Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии ислама // На стыке континентов и цивилизаций… – М.: Инсан, 1996. – 768 с.
8. Сайфетдинова Э.Г. Источники религиозной мысли в Золотой Орде (по материалам произведения «Нахдж ал-Фарадис» Махмуда ал-Бул-

гари): монография / отв. ред. И.М. Миргалеев. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2018. – 164 с.

9. Сайфетдинова Э.Г., Гамаль Абдель Рехем И.Х. Династический брак мамлюкского султана Египта ан-Насира и царевны Тулунбай по данным средневековых арабских летописей // Золотоордынское обозрение. 2017. Т. 5, № 1. С. 116–125.
10. Тизенгаузен В.Г. Сборникъ материаловъ, относящихся к исторiи Золотой Орды, Томъ I: Извлеченiя изъ сочиненiй арабскихъ. СПб.: Тип. Императорской Академiи Наукъ, 1884. – 564 с.

## ФӘННИ-ПОПУЛЯР ЯЗМАЛАРДА ТӨБӘК ТАРИХЫ

## КРАЕВЕДЕНИЕ В НАУЧНО-ПОПУЛЯРНЫХ ПУБЛИКАЦИЯХ

*Дамир Таҗи*

### ТУГАН АВЫЛЫМ НИГЕЗЕНӘ АЛЫП КИЛГӘН СУКМАКЛАР

*(Чирмешән районы Түбән Кәминкә авылына 300 ел)*

Туган якка күзем төшсә, башым дин уйларым китә;
Йөрәк бәгърем яна башлап, түзәргә дәрманым бетә.
И аккош, син китәр булсаң, минем илгә җитәр булсаң,
Туганнарны күрер булсаң, сәлам әйтче син безләрдин...

*Татар халык мөнәҗәтеннән*

Уйланырга этәрә торган әлеге мөнәҗәтне автор очраклы рәвештә генә искә төшермәде. Авылда дөньяга килгән һәм читкә киткән һәр кеше туган авылын сагынмыйча калмый, хәтта шунда күп нужалар күрсә дә, инде шактый хәсрәтләр кичергән бу җиргә борылып карамыйм дип ант эчсә дә, барыбер күңеле белән булса да, туган авылына кайтып килә, аның урамнары, кырлары аша үтә, әби-бабасын уйлап юксынып куя.

Бүгенге көндә Түбән Кәминкә авылының 60–70% халкы туган җирендә түгел, ә төрле төбәкләрдә гомер итә. Алар салкын Себер, Оренбург якларына китеп тә яңа авылларга нигез салган. Әнә шулай авыл сыеклана, кечерәя һәм нигезләр коруга юл ачыла. Аларның күп санлы балалары, оныкларының да нәсел тамырлары авылдан булуына әллә ни исләре китми, шәһәрләрдә туганга күрә, ата-баба җирен ничектер үги дип кабул итә. Икенче яклап, ата-аналары үзләре дә туган җирнең тарихлары турында хәбәрдар түгел. Шундый күңелсез уйлар белән каләмгә тотынсам да, авыл тарихын өйрәнгән саен кәефем күтәрелә барды, үзем өчен дә, милләттәшләрем өчен дә яңа дөнья ачкандай булдым. Кәминкә гомуми татар тарихына бик нык бәйләнгән, аның аерылгысыз бер өлеше. Түбән Кәминкәнең дә горурланып сөйләрлек тарихы бар. Авыл нигезләнүгә 2024 елда 300 ел тула, шул гомердән бирле, бер кем дә аның тарихы турында бер кечкенә генә булса да җыентык язмаган. Әмма шулай да дөресен әйтик, бу вакыйгаларга кадәр

авыл тарихлары белән иң кызыксынган кеше, автор белән кардәшлек җепләре дә булган Әсгать Юныс улы Җамалетдинов, Түбән Кәминкәдә тирән тамыр җибәргән Бикмөхәммәт улы Даут нәселенең шәҗәрәсен төзегән (ревизия буенча Даут Тәкәев улы Бикмөхәммәт), матбугатта кайбер мәкаләләр дә бастырган. Бу шәҗәрә яхшы гына эшкәртелгән, аны Чирмешән төбәге тарихчысы Ясәви ага Шәмсетдинов архивта саклаган метрика дәфтәрләре белән документлаштырып, 2022 елда бер җыентык эшләде. Үземнең дә бу авыл турында күбрәк белү теләге кабынып китте, чөнки борынгы әби-бабаларым шул авылдан ич. Кармышта туган әбием Миннегаян Габделгаләм (1910–1997) кызының әнисе Гайнелмәган әбинең атасы – Кутәмә волосте старшинасы Шиһабетдин Хәбибуллин Түбән Кәминкәнеке, әнием Факиянең әтисе Әбүбәкер Мортазин да (1897–1942) Түбән Кәминкәнеке. Ул – авылда оешкан «Ирек» күмәк хуҗалыгының беренче рәисе. Биредә Мортаза, калач пешерүче Зиннур, Габделкәрим, Габдерәшит бабамнар яшәгән.

Авылның исеме гомер-гомергә Түбән Кәминкә дип аталган, рәсми кәнсәләрдә урысча Нижняя Каменка дип һәрдаим язып барганнар. Дөрес, авыл турында табылган беренчел документларда аның исеме Кәминкә (Каменка), «түбән» сүзе беркадәр вакыт узганнан соң өстәлгән. Ревизия кәгазьләрен тутыручылар аны Түбән Ташлык дип татарча язып тормаганнар, шул рәвешле Түбән Ташлык-Нижняя Каменка дигәне Түбән Кәминкә дип, татарча сөйләмгә яраклашып, халык теленә кереп киткән. Түбән Ташлык яки Түбән Кәминкә дисәк тә, ике исем дә бик матур яңгырашлы, күңелгә ятышлы, кайсын куллансак та, үзебезнең авыл исеме... Түбән Кәминкә – Олы Ташлык (Шушма елгасының сул кушылдыгы) инеше буендагы татар авылы. Чирмешәннән 25 чакрым төньякта. Якынча 1724–1730 еллар аралыгында нигезләнгән дигән билгеләмә дөреслеккә туры килә. Без моны 1745–1762 еллардагы ревизия мәгълүматларына таянып әйтәбез. Әлеге ревизияләр авыл тарихы турында иң беренчел чыганаклар. Аннан да борынгырак язмалар юк.

Авылдашыбыз Габдулла Салихның үз хисабына чыгарган 2013 елгы җыентыгындагы «Түбән Кәминкә авылына 1554 елда җиде мишәр нигез салган...» – дигән берничә җөмлә бернинди тәнкыйтькә дә сыймый, фактның кайсы чыганактан алынуы да әйтелмәгән. Китапта авыл тарихы да язылмаган. Анда Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларына кагылышлы төрле чыганаклардан алынган язмалар кергән. Шулай ук кайбер риваятьләрнең, телдән сөйләнгән имеш-мимешләрнең хакыйкатькә туры килмәве дә аермачык күренә.

Китапханәдә эшләгән Асия апа Гафиятуллина 1958 елларда авыл картларыннан авылга беренче күчеп килүчеләр турында язып алган риваять-

тә бирегә Югары Кәминкәдән качып килгән Габдерәхим белән Габдулла турында сүз бара. Имештер, «авылга ат караклары эз салган, алар шунда качып, үзләренең угры эшләрен башкарганнар»,– дип әйтүчеләр дә бар. Булмас димә, булгандыр. Риваятьләр чын хакыйкатьтән еаграк булса да, анда сер яшерелгән, еш кына мондый утырма хикәяләре чынга да ашып куя. Бу очрактагы риваять буш урында гына сөйләнелмәгәндер. Әлбәттә, узган гасырлардан килгән бу авазлар тарих киштәләрендәге язуларда күренми. Беренче күчеп килүчеләрнең Нижгардан, Алатыр өязеннән (хәзерге Чувашия Республикасы), Татарстан Республикасының Чүпрәле, Буа, Алексеевск районнарыннан булулары билгеле. Безнең төбәктә авылларның нигезләнүе 1731–1736 елларда яңа чик сызыгын төзү белән бәйле, һәм бирердән 1652 елларда ук Россиянең чик буе сызыгы (Закамская засечная черта) үтүе билгеле. Кармыш авылы тирәсендә Күтәмә ягыннан сузылган вал да шул хакта сөйли. Бу хакта төбәк тарихларына багышланган китапларда бик ачык итеп әйтелде, аны кабатлап тормыйбыз. Кәминкәгә ерак авыллардан килгәннәрдән кала, бирердәге чик буйларында хезмәт итүчеләрнең дә шунда төпләнеп калулары, гаиләләрен алып килүчеләр дә булгандыр. Әмма авылларның ревизия язуларында беренче килүчеләрнең чик буен сакларга яки төзергә килүләре турында ләм-мим бер сүз дә әйтелмәгән: «В деревне Каменке государственные служилые определенные к корабельный работе татары перешедшие из разных уездов»,– диелгән. Монда лашманчылар турында сүз бара. Күбесе авыр хезмәттән качып булмасмы дип һәм чукындырылудан куркып та туган авылларыннан чыгып киткәннәр. Әмма тәкъдирләрендә язылган «кара язмышлары» бирегә дә чабуларыннан өстерәлеп килгән.

1760 еллардан соң читтән керәшеннәр дә килеп урнашкан. Авыл турындагы язмалардан Д.А. Корсаковның 1908 елда чыккан «Сборник материалов по истории Казанского края 18 веке» китабында Түбән Кәминкәдә 1771–1773 елларда 137 татар һәм 15 чукындырылган татар яшәгәнлеге язылган (хатын-кызлар саналмаган). Тагын да борынгырак чорларга китеп карасак, хәзерге Чирмешән районы җирләре Нугай Урдасы биләмәсенә һәм Казан ханлыгына да кергән, иң әүвәле, Идел буе Болгарстаны да бу тирәләргә хуҗа булган.

1858 елгы ревизия язуларында Чистай өязе Иске Ибрай волостена кергән Түбән Кәминкәдә яшәгән 699 ир-атның һәм 704 хатын-кызның исеме язылган, җәмгысе – 1403 җан. Анда рус кешеләре дә яшәгән. Исемнәре: Яким Васильев, Егор Степанов, Андрей Семенов, Филипп Федоров, Никифор Иванов, Данила Борисов, Илья Гаврилов, Семен Тихонов, Герасим Андреев, Гаврила Михайлов. Боларны чик буе бетерелгәннән соң шунда төпләнеп калган солдатларның нәселен дәвам итүчеләр дип әйтеп

була. Моңардан тыш, авылда бер керәшен татары – Гафиятулла Иванов, отставкадагы өч татар, төрле сугышларда катнашкан солдатлар Мәһди Әхмәров, Насый Рәимов, Таҗи Әмиров яшәгән [ГАРТ. Фонд 3. Опись 3. Д. 387, 666]. Насый Рәимов метрикада «Насреддин Рәим улы 1780 елда туган»,– диелгән. Әтисе Рәим 1762 елгы ревизиядә күренә, 1838 елда вафат. Рәимнең атасы – Мостафа Рәҗәпов.

Өстә телгә алынган урыс кешеләренең нәселе авылда озак еллар яшәгән, кайберләре татарлашкан да. Ватан сугышына кадәр монда Жилиннар, Москвиннар, Ханжиннар, Картамышевлар һ.б. яшәгән. Бер керәшен татары, диелгән. Әйе, чыннан да, ул берәү генә, бәлки үз теләге белән керәшен булып калгандыр. Чөнки 1858 елда Түбән Кәминкә, Кармыш, Түбән Абдул һ.б. авылларда чукындырылганнардан саналган халык «отпавшие в Ислам» дип исәпләнгән. Бу хакта патша законы да булган. Әмма шулай да урыс православиесе әһелләре татар авылларында үз эшләрен туктатмаганнар, аның бер өлешен христиан дип санаганнар, законны белмәгән халыкны куркытып, алдалап, мәкерлек белән дә һәм җае булганда прәннек биреп тә үз якларына аудару өчен тырышлык куйган. Ләкин, үзләре язганча, «кире беткән татарлар ихтыярын» сындыра алмаганнар. Попларның итәк астыннан ут төртеп йөрүләре 1909 елларга кадәр дәвам иткән. Әгәр шулай булмаса, бу елда өч мәчетле авылның 36 йортында чукынганнар бар, дип язмаслар иде. Димәк, поплар бу татар авылының бер өлешеннән керәшен ясар өчен бик тырышкан.

Элеккеге заманнарда туучылар күп булган, шул ук вакытта медицинаның нәрсә икәнен дә белмәгән авылларда гади генә чирләрдән дә вафат булучылар бихисап. Дин әһелләре метрика дәфтәрләренә аларның исемнәрен зур төгәллек белән теркәп барганнар. Халык саны да яхшы гына артып барган. 1858 елда Кәминкәдә 1403 кеше яшәсә, 1859 елда халык саны 1426 га кадәр арткан, 241 йортта 713 ир-ат, 713 хатын-кыз яшәгән. Чагыштыру өчен: 1876 елда авылда 1608 җан, 1897 елда 1972 җан яшәгәнлеге мәгълүм. Бу вакытта авылда 1 янгын сүндерү машинасы булуын теркәп куйганнар. Машина дигәннәре су сиптерергә ясалган бер җайланма булса кирәк.

Халык арасында киң таралган тагын бер мәгълүмат. Кәминкә авылы 1773–1774 еллардагы Пугачев фетнәсе документларында очрый. Дөрес, Кәминкә дигән авыл башка төбәкләрдә дә булган. Пугачевчылар хәрәкәте Чирмешән районы аша да узган. Моны риваять яки уйдырма дип кенә әйтеп булмый. Авылларда Әшәлче поселогы ягыннан Түбән Кәминкәгә таба сугыш булган дигән хикәяләрне үземнең дә ишеткәнем бар. Әшәлче поселогының тау итәгендә ферма корылмаларына нигез казыганда кеше сөякләре, сөңгеләр, очлы тимерләр һәм ташлар чыгуы шул фетнәдә үте-

релүчеләрнең кабереме? Вакытында тикшерелмәгәнгә күрә, бу сорауга беркем дә җавап бирә алмый. Ә узган заманнардан килгән хәбәрне чынбарлык дип танырга туры килә: Иван Чернеев отряды Чирмешәннән 40 чакрым читтәге Каменка авылы тирәсендә хөкүмәт гаскәрләреннән булган полковник Хорватның җәза отрядына каршы сугышкан. Чернеев 31 гыйнварда Богырыслан ягына чигенә. Безнең җирле халыкның бу сугышка катнашып китүе билгесез, гомумән, бу хакта хәбәрләр юк. Анда райондагы Туймәт авылыннан бер кешенең катнашуы мәгълүм.

Авыл оешкан елларда административ бүленеш ягыннан Нугай даругасы Казан өязе составында саналган. Монда шуны да әйтергә кирәк, Казан өязе 1552–1920 елларда, ә Казан губернасы 1796–1920 елларда гамәлдә булган. Егерменче гасыр башында авылда 3 җәмигъ мәчете, мәдрәсәләр эшләп торган, гадәттә җирле халык игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән, крестьяннарның бер өлеше төрле хезмәткә читкә йөреп, гаиләсен караган. Авылда тегермән, ярма яргыч, 3 кибет булган. Әлеге чорда имана җирләре 1829 дисәтинә тәшкил иткән. Бу җир генә халыкны канәгатьләндерә алмаган. 1920 елларга кадәр авыл Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостена (татар телендә олыс) кергән. Күтәмә волосте 1860 еллардан соң оешкан. Моңарчы Иске Ибрай Лашман волостена буйсынган. Кайбер кискен хәлләрне Әккәрәй авыл җәмгыяте старшиналары караган. 1920 елдан соң Түбән Кәминкә – ТАССРның Чистай кантонында. 1930 елның 10 августында Беренче Май район үзәге буларак рәсми игълан ителгән. Иң кызганычы, Түбән Кәминкә авылында район үзәге оештыруны башлаучылар хакында бернинди мәгълүмат тә сакланмаган. Техник яктан бик уңай булу сәбәпле, район белән идарә итү, элек Самара губернасына кергән Чирмешән бистәсенә күчә. Моңа кадәр күп кенә рәсми эшләр элеккеге гадәт белән Чистай кантоны Күтәмә бистәсендәге волисполком аша хәл кылынган.

РСФСРның Югары Советы Президиумы указы белән Беренче Май районы 1963 елның 4 гыйнварында бетерелә. Районның күпчелек авыллары Лениногорск, Әлмәт, Октябрь районнарына һ.б. бүленә. Түбән Кәминкә 1963 елның 1 февраленнән 1965 елның 12 гыйнварена кадәр Лениногорск районы составындагы Кармыш авыл Советына буйсындырылган: Кармыш, Түбән Кәминкә, Иншар, Саклык, Әшәлче (Яшәүче) һәм Братство поселоклары. 1965 елның 12 гыйнварында РСФСРның Югары Советы Президиумы Чирмешән районы төзелүе турында карар кабул иткән. Өстә телгә алынган авыллар шул ук Кармыш авыл Советына караган. Колхозлашу елларында «Ирек» исеме алган, соңыннан «Татарстан» колхозы. Бу исем баштан ук 1924–1926 елларда Түбән Кәминкәдән аерылып чыккан Иншар поселогы колхозыныкы булган. Иншар поселогы

гының әүәлге исеме – Батрак. Күрше-күләндә яшәгән халык Иншарны еш кына Асташкы поселогы дип кенә атаган. Чөнки шунда гына, инешнең икенче ягында Осташкин починок исемле мохша тегермәнчеләренең 4–5 йортлык авылы булган, соңгы йорты 1943 елларда сүтелгән. Иншар 1958 елларга кадәр Түбән Кәминкә авыл Советына караган (аннан соң Кармыш авыл Советы), хуҗалык саны 20–22 дән артмаган. Бирегә беренчеләрдән булып йорт салган кешеләр – Ширияздан, Әбүбәкер, Шәймәрдан Мортазиннар.

Авыл тарихларын язганда күрше авыллар тарихына да күз салып үтү тиешле. «Югары Кәминкә авылы 1710 елдан билгеле»,– диелгән Татар энциклопедиясендә (Казан – 2002, 574 б.). Бу ялгыштыр дигән шик бар. Моңа ачыклык кертү өчен икенче-өченче яки, әгәр булса, беренче ревизия язуларын карап чыгарга кирәк. Бу авылга багышланган хезмәтләрдә дә ревизия дәфтәрләре искә алынмаган. Шул ук энциклопедия (1999 елгы басма) Яшәүче (Әшәлче) поселогын 17 гасырда нигезләнгән, дип язып чыкты (соңыннан дөресләнде). А.П. Семайкинның Күтәмәгә багышланган китабында «авыллары 1704 елда нигезләнгән»,– дип әйтүе дә дәлилсез. Күтәмәгә 1726–1728 елларда беренче булып ике татар кешесе килүе документлар белән раслана, әмма алар анда төпләнеп кала алмый...

Статистика мәгълүматларында авылда яшәгән халык саны: 1782 елда – 152 ир-ат (хатын-кызлар исәпләнмәгән), алга таба хатын-кызларны да исәпләп, 1859 елда – 1403 кеше, 1897 елда – 1972 кеше, 1908 елда – 1532 кеше, 1915 елда – 2541 кеше, 1920 елда – 2205 кеше, 1926 елда – 861 кеше (ватандашлар сугышы һәм ачлык елларда халык саны бик кимегән), 1949 елда – 773 кеше, 1958 елда – 873 кеше, 1970 елда – 1098 кеше, 1979 елда – 889 кеше, 1989 елда – 583 кеше, 2002 елда – 519 кеше, 2011 елда – 505 кеше. Иң зур проблема чәчүлек җирләре җитмәүдә булган. 1858 елда җан башына 3–4 дисәтинә җир туры килгән, ә 1906 елда ул 2,1 дисәтинәгә калган. Бу елда авылда 413 гаилә яшәгән, шулардан 9 гаилә җирләрен арендага биреп, авылдан вакытлыча китеп барганнар. Аз җирле әлеге хуҗалыкларда, Столыпин реформасына таянып, 1908–1910 елларда Себергә бәхет эзләп китүчеләр була. Алар Төмән өлкәсенең Яркәү (Ярковский) районында Аккүл (Юрты Дулепино, элек Тубыл губернасында) авылын төзегәннәр, кайберләре янәшәдә себер татарлары яшәгән Озерное-Күлавылына (документларда Юрт Озернинских Ялуторовского уезда Тобольский губернии) барып нигез корган. Бүген дә биредә кәминкәлеләрнең нәселен дәвам итүчеләр бар. Безнең яктан монда кунакка барып килүчеләр дә булды. Авылның иске мәчете дә бар, күлендә аккошлар йөзә, һәр җирдә иркенлек, матурлык күзгә чалына. Кайсы ягы беләндер безнең якларга да охшаш.

Кәминкәгә каяндыр, кайсы елдадыр җирсез 10 гаилә килеп төпләнгән, дигән хәбәрләр ишетелә. Тамак хакына алар баерак кешеләргә ялланып эшләгәннәр, ярдәмче булганнар, төрле һөнәрләр белгәннәр, якынтирә авылларда да алар хезмәтенә ихтыяҗ булган. Оренбург далаларына 1870 елларда күчеп киткән кәминкәлеләр дә игътибардан читтә калмады.

1904–1905 елларда рус-япон сугышында Кәминкәдән катнашучылар турында мәгълүмат табылмады. Ә менә Беренче бөтендөнья һәм Ватан сугышында катнашучыларның исемнәре табылуы – зур истәлек.

1920 елда «Кара бөркет һәм игенче» («сәнәкчеләр» дип билгеле) фетнәсе була. Совет власте хөкүмәткә дип крестьянның орлыкка дигән запасына кадәр тартып ала. Халык баш күтәрә. Фетнәчеләрнең кансызлыгы Әккәрәй, Бәркәтә, Түбән Кармалка, Чирмешән авылларында зур фаҗигаләргә китерә. Соңыннан анда катнашучыларның үзләрен дә үтә рәхимсезлек белән үтерәләр, төрмәләргә озаталар. Кәминкәдән дә бу хәрәкәткә кушылучылар булган. Совет властеның гаебе белән илдә 1921 елгы ачлык башлана, ел бик коры килә, халык күпләп кырыла, аларның исемнәрен дә язып бармаганнар. Мәетләрне берничә урынга, чокырларга ташып җирләгәннәр. Авылдан чыгып киткәннәренең дә күбесе юлда үлеп беткән. Халык нәрсә туры килсә, шуны ашаган, урлау һәм үтереш очраклары да булган. Хәтта үлгән хайван сөякләрен тегермәндә ваттырып-тарттырып, шуннан он ясап, ризыкка кулланганнар. Америка администрациясе ярдәме Түбән Кәминкә авылына да килеп җиткән, ризыклар кулга тапшырылмаган, беренче чиратта балаларны җыеп туендырганнар. 1919 елда чәчкән уҗым 1922 елда гына аннан-моннан шытып чыккан. Бу елларда кар да аз яуган. Ә менә 1922 елның февралендә ишелеп кар яуган. Кар урыны-урыны белән йорт, капка түбәләрен күмеп киткән. 1923 елда кайбер яшьләр Казанга укырга киткән; 1928 елда мәктәп бинасы салынган, 1929 елда хастаханә төзелгән, авыл эчендә, дөресрәге, авылның Иншар поселогына чыгып киткән ягында...

1930 еллардагы күмәкләшү чорында башланган репрессияләргә зур игътибар бирдек. Барысы да документтагыча язылды, үзебез уйлап чыгармадык. Әлбәттә, биредә 60–70 елга сузылган совет дәвере, колхоз тормышы аерым хезмәт язуны таләп итә, без аерым елларга гына тукталдык.

Бөек Ватан сугышы дәвере үзе генә дә аерым бер китап дәрәҗәсенә җиткерелде. Моңарчы билгеле булмаган исемнәр, солдатларның һәм тылда колхозда эшләүчеләрнең каһарманлыклары, кайберләренең күмелгән урыннары билгеле булды. Гаяз Мостафинга герой исеме бирү турындагы документлар музейга тапшырылды, Алтын йолдызы Кызыл Байрак орденына алыштырылган. Сугыштан соңгы тормыш, яшәеш... – барысы турында да яздык.

## Зират – адәм баласының мәңгелек йорты

Түбән Кәминкәнең дүрт зираты авылның элек-электән бик зур булуы турында сөйли. Центральная урамында зур зират бар. Ә элеккеге хастаханәдән ерак түгел урында, инеш буена терәп салынган зиратта мәҗбүри чукындырылганнар җирләнгән, дип сөйлиләр, анда исемсез гади ташларны күпләп күреп була. Ул ташларга язу төшерелмәгән, адәм вафат булгач та, кабер тапталып югалмасын дип, каян туры килә, шундагы ярдан куптарылган гади ташларны бастырып куйганнар. Алар төрле калыпта, очлылары, өч-дүрт почмаклылары бар, ягъни чокып язу төшерү өчен ташларның эшкәртелмәвен абайлау катлаулы түгел. Бередә, бу зиратның бер башында җирле хастаханәдә вафат булган төрле милләт кешеләре җирләнгән, дип тә әйтәләр, татарлар ул җиргә күмелмәгәндер. Каберлекләрне аерым бүлеп калдырмаганнар, кайда урын бар, шунда казып җирләгәннәр. Ачлыктан һәм тиф, бума кебек йогышлы авырулардан үлүчеләрне дә шунда җыйганнар. Алар шул хәтле күп булгандыр дип әйтеп булмый. Ни өчен үлгәннәрнең гәүдәләрен туган җирләренә алып китмәгәннәр? Бәлки йогышлы авыру таралмасын дип, мәетләрне хлорлап күмгәннәрдер. Өлкәннәребез әйтүенчә, Күтәмәдән һәм башка урыс-чуваш авылларыннан мондагы каберлекләргә зыярәт кылырга йөргәннәр. Бу халыкларда үз гореф-гадәтләре буенча, кырлар аша мәет алып кайту начар хәл саналган, имештер, авылга үләт, төрле бәла-казалар, бәхетсезлекләр килә, дип тә уйланылган. Әмма динсез яшәгән совет чорында хорафатларга ышанучылар булдымы икән? Халык хәтерендә бик сәер хәлләр дә сакланган. Мәсәлән, Борис Николаев хатыны Ольга Кәминкә хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшләгән. Балалары үлеп, шунда җирләгәннәр. Ниндидер вакыттан соң кабердән баланың җәсәден алып, Күтәмәгә күчермәкче булганнар, ләкин табут һәм бала да юк, имеш. Ышануы да авыр, кеше куркытыр өчен уйлап чыгарылган уйдырма кебек, әмма, булмас димә... Аңларга акыл җитмәгән нәрсәләр бу дөньяда гел очрап тора. Монда шулай ук кайсыдыр елда хастаханәдә тифтан үлгән Лотфулла бабайны җирләгәннәр (Әһлиулла исемле улы булган). Район хастаханәсендә дә биредә җирләнүчеләр исемлеге табылмады, ә алар булырга тиеш, һәм анда табибның соңгы заключениесе язылa бит. Тик мондый зур мәйданда хастаханә авырулары гына җирләнгән дип әйтү дөрес булмас кебек. Димәк, шунда, авылның башлангыч чорында ук кешелер күмелгән диярге була. Чыннан да, биредә керәшеннәр күмелгәнме соң? Монда совет чорында да берничә кеше генә күмелгән, ташларында язулар бар иле. Язулар дигәннән, эш болай: таш дип аталганы заманча шомартылган нәфис, дүртпочмаклы, калынлыгы 2–3 см булган 6 плитәдәге исемнәр. Плитәләр бастырып куелган, өсте ябулы тимер

корылмага беркетелгән. Салах бабай токымы монда җирләнгән нәселләренең исемнәрен истәлек итеп язып элгән. Иң соңгы күмелгән кешеләр 1955 ел белән чикләнә, башка исем-ташлар юк. Мисал өчен, исемнәрне күрсәтәбез: Салахова Хәдичә Сәлман кызы (1865–05.05.1955), Салахова Гишкури (Гыйшкынурый) (1885–28.02.1955), Салахов Минхәер, Салахов Сәлахетдин, Салахова Вәсилә (1918–1920), Шәмсетдин Миннехан улы. Зират озак еллар файдаланылмаган һәм хәзер дә анда кешеләрне җирләмиләр. Чыннан да, зиратның бу өлеше керәшеннәрнекеме? Саф мөселман Салаховларның керәшен зиратына нәсел-нәсәпләрен күмүләренә һич ышанып булмыйдыр, мөгаен. Алай дияр идең, керәшен дигәннәре дә чын керәшен булмаган, үз диннәрендә, үз гореф-гадәтләрендә яшәүләрен дәвам иткәннәр. Аннан соң Түбән Кәминкә, Кармыш авыллары керәшеннәре 1858 елларга кадәр ук «отпавшие в ислам» дип саналганнар. Иң кызыгы шунда, бу зиратны авыл халкы икегә, өчкә бүлеп карый. Монда күптән кешеләр җирләнмәгәч, бәлки сугышка кадәр, бәлки сугыштан соң, ике зират арасында берничә йорт төзелгән – Әкрәм Гарифуллин, Әхтәм Шәйдуллин һәм Әмин Вәлиевләр шул урында гаиләләре белән гомер иткәннәр. Ни өчен шундый урынга йорт төзүләре дә аңлашылып бетми. Әлеге урыннарда кеше сөякләре чыгу очраклары да булган. Димәк, башка җайлы урын булмагандыр. Бу җир, бигрәк тә зират тирәсе әллә ни кызыгырлык урын түгел. Фаразлар буенча, Әхтәм абзыйлар бакчасы белән ике каберлек арасында элек әвен базы булган. Анда вакытлыча бөртекле культураларны саклаганнар, соңыннан суктырганнар. Тифтан яки ачлыктан үлүчеләргә кабер казып өлгерә алмау сәбәпле, аларны 1920–1923 елларда шушы базга җирләгәннәр. Бөтен гаиләләре белән үлүчеләр дә булган. Шундый урын авылны икегә бүлүче инешнең икенче ягында, Заречная урамы артындагы зиратта да булган. Монда да яңгыр юган, мүкләнгән исемсез ташлар бар. Әхтәм Шәйдуллин белән Әмин Вәлиевләр йортлары арасында шактый зур аралыкны һәркем күреп белә. Керәшен зираты шунда дигән фараз дөрес түгелме икән? Центральная урамы артында тагын бер зират бар, мәйданы шактый зур күренә, кайсыдыр елда киңәйтелгән, алар да борынгы, шундый ук төрле калыптагы исемсез, кечкенә һәм зур ташлар еш очрый. Бу зиратларны аерым карап, тәртиптә тотучылар юк. Һәр урам ел саен өмә оештырып, гамәлдәге зиратларны чистарта, әрвахларның туганнары да монда еш килә, догалар укыла. Зират эчендә аерым зират кебек күренешләр күзгә чалына, ягъни бер нәсел үзенең кешеләрен элек-электән гел бер урынгарак җирләп, тирәсен тимер рәшәткәләр белән әйләндереп алганнар, анда ерактан тәртип күренеп тора. Зиратларда җил яхшы уйный, алар икесе дә (Заречная) бераз калкулык өстендәрәк урнашкан, урыннары отышлы сайланган. Бу зиратларга бер-

ничә гасыр дәвамында мәрхүмнәрне җирлиләр, шул исәптән бүгенге көнгә кадәр. Бездәге зиратларда, башка авыллардагы кебек, гарәпчә язылган иске ташлар юк дәрәҗәсендә, шулай да берничәсен таптык. Заречная урамы ягындагы зиратта бер кабер ташы: «Мифтахетдин бин Сираҗетдин 1327 елда вафат, вә фи йәүмил әхәд рәҗәб сәнәти 1909», диелгән, бүгенге календарьга күчерсәк, милади буенча 1909 яки 1910 елга туры килә. Центральная урамы ягындагы зиратта иске язулы ике таш бар. Берсендә Түбән Кәминкәнең беренче мәхәллә имам-хатыйбы Мирхәйдәр Нуретдинов җирләнгән, ул 26 ел мулла булып торган. Текст: «Әгузү.. бисмилләһи... лә иләһә.. вафат милла Мирхәйдәр җан ибн милла Нуретдин улы, 1910 сәнә миляди, 12 август, 1327(8) ел һиҗри, шәгъбән ае...». Икенче таштагы язулар укылмады диярлек, әмма исемне чамалап була: «Габдуллаһ бин Гарифуллаһ Йомагыл улы», дип укырга мөмкин. Елында, уртада ике сигезле генә аныклана. Әгәр шулай булса, бу таш XIX гасыр азагында куелган, дип әйтеп була. Метрика кенәгәсе буенча, әтисе Гарифулланың яшәү вакыты 1832–1883 еллар. Ташы бик матур эшкәртелгән, зур да түгел, укылмаса да, матур язылган, каллиграфистның чокып язганда ташны бераз бозуы сизелеп тора. Ташның түгәрәкләп эшләнгән өлешенең уртасында, өске якта уеп ясалган кечкенә чокыр да бар. Анда су җыела, яки әз булса да шунда су коялар. Бу исә мәрхүмгә карата булган хөрмәтне дә һәм фани дөньяга булган мәхәббәтне дә белдерә кебек. Әнә шул чокырчыктан сайрар кошлар су эчкән. Язулы ташлар, гадәттә, хәллерәк һәм дәрәҗәлерәк адәмнәрнең каберләренә куелган. Әлеге ташларны бик борынгылар дип тә әйтеп булмый, зиратларда XVIII–XIX гасырга караган бер генә ташъязма да юк. Әлеге кабер ташлары – 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр булган язма мирасыбызның матур бер үрнәкләре. Әлбәттә, совет чорының башлангыч дәверендә кабер өсләренә гарәпчә язулы ташлар куелгандыр. Вакыт узу белән сыйфатсыз йомшак ташлардагы язулар кар-яңгырлардан юылып юкка чыкканнар. Бүгенге көнгә кадәр бабаларыбызга ят булган кириллица графикасы татар зиратларында бер гасырлап файдаланыла. Ә бу инде көчләп тагылган икенче дөнья, икенче культура, бозылган милли исемнәр, төрле сурәтләр һәм пластик чәчәкләр, әмма бик «зәгыйфьләнгән» булса да, татарныкы әле. Зиратлардагы төрле ташларның әхлакый һәм мәгънәви эчтәлеге турында да күп сөйләп була. Авылда урам исемнәре дә бөек урыс телендә, һәркемгә яхшы таныш хәл, әмма моңа инкыйразга кадәр һич беркем кайгырмас.

Өстәге фаразлардан һәм өйрәнүләрдән чыгып шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: иң беренче зират авылның кайсы ягында ачылуын әйтеп булмый, әмма иң беренчеләре Центральная урамы ягында булгандыр дип ышанасы килә, мөселманнарныкы һәм керәшеннәрнеке – аерым зират-

лар. Авылда беренче үлүчеләрнең исемнәре ревизия язуларында 1740 еллардан соң күренә.

### Билал турындагы хикәягә аңлатма

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвәлен бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!
Бабалар кабре янында күңел зар,
Аталар рухының армандәсе бар...
Кара тупрак тулы мәзлум нидасы,
Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?

*Дәрдмәнд*

Центральная урамындагы зиратта Билал исемле кешенең җирләнгән урыны да билгеле, халык хәтерендә бу «шул кеше кабере» дип калган. Әгәр 1762 елгы ревизиядә язылган вафат булучыларны искә алмасак, бу монда күмелгән һәм исеме билгеле булган иң борынгы каберлек дип әйтеп булыр иде. Бүгенге чор нәселләре каберне чистартып, шунда истәлек ташы бастырып, «Билал» дип язып куйганнар. Янәшәсенә шул нәселне дәвам итүчеләр дә җирләнгән икән. «Билал – авылга нигез салучыларның берсе»,– дип әйтәләр. Билал нәселе – авылда бик булдыклы һәм танылган нәсел. Билал балалары Нотфулла, Сафиулла, Мотыйгулла, Гыйшкыруй, Могыйн исемле булган, дип хәтерләрендә калган.

Билал турында тагын бер хикәяне буыннан-буынга сөйләп килгәннәр: «Билал бабай тамыры әби патша Катерина заманыннан билгеле, ул Сәет батыр яугирләре төркемендә хөкүмәт гаскәрләренә каршы сугышып йөргән, хәзерге Алексеевск районыннан; Сәет явы тар-мар килгәч, үз авылына кайтырга куркып, икесе дә Гарифулла исемле кешеләр Түбән Кәминкәгә килеп урнашкан». Әлеге хикәядә берничә тарихи вакыйганың буталганы күренеп тора, тегеннән-моннан ишетелгән хәбәрләр бер дәверне генә чагылдыра кебек. Бераз ачыклык кертеп карасак, болай килеп чыга: Билал исеме әгәр әби патша (идарә вакыты 1762–1796 еллар) заманыннан билгеле булса, нәкъ шул чорда, 1773–1775 елларда Пугач яулары булуын һәркем белә. Авылына кайтырга куркып, безнең якларга Алексеевск районыннан килеп чыккан, имеш. Ул заманда шулай җан саклап, каңгырап, качып йөрүчеләр күп булган. Тарихи фактлар буенча, Пугачев командиры Иван Чернеевның Чирмешәннән 40 чакрым читтәге Каменка авылы тирәсендә патша гаскәрләре белән сугышуы билгеле. Беренче хикәядә Билалның авылга беренчеләрдән нигез салучылар рәтендә булу мөмкинлеге дә әйтелгән иде. Ләкин дәлилләр сүздә генә, чынбар-

лыкны яктыртмый. Билалны тагын да борынгырак баба дип карасак та, исеме иң беренче мөһим документ дип саналган икенче һәм өченче ревизия язуларында күренмәде. Ә менә Алексеевск дигәндә, ниндидер томанлы чынбарлык шәйләнә кебек. Шул районлагы Олы Тигәнәле авылыннан Кәминкәгә күчеп килүчеләр булган. Ә Сәет батыр (тарихта башкорт восстаниесе) яулары 1681–1684 елларда Нугай һәм Себер даругаларында кузгалган. Вахит Имамовның «Сәет батыр» повестенда (Яр Чаллы, «КамАЗ» нәшр., 1994 ел, 3–156 б.) бу баш күтәрүләр 1704 елның җәеннән башлана, дип язылган (Түбән Кәминкә авылының әле эзе дә юк). Димәк, Сәет батырны Түбән Кәминкәдә дә белгәннәр, ничектер хикәягә кереп калган бит. Сәет исемле яугирләр аннан да элгәререк булган. Мәсәлән, 1552–1557 еллар – Җансәет, Сарый-Батыр, Мәмеш-Бирде һ.б. җитәкчелегендә татар, мари, чуваш, мордва, удмуртлар урыс баскынчыларына каршы азатлык сугышы алып барган...

Бәлки Билалның ерак бер бабасы яки туганы Сәет батыр командасында йөргәндер дип тә фараз кылырга мөмкин. Билал бабайны ике яуның берсендә (Сәет батыр һәм Пугачев) катнашкан дип әйтеп булмый. Чөнки вакыт аралыгы шактый ерак. Хикәядә сөйләнгән вакыйгаларның Билалга бернинди дә катнашы юк. Авыл муллалары тутырып барган метрика китапларында еллар зур төгәллек белән язылган. XIX гасырда Сәет батыр яки Пугач яулары булмаган. Кабер ташына язылган Билал-Билалетдин 1835–1898 елларда яшәгән, хатыннары: Маһиҗамал Гатаулла кызы, Хәбибҗамал. Билалның этисе – Габделвәли Әхмәр улы. Габделвәлинең ир туганнары: Мәһди солдат һәм Габделҗәлил. Билал балалары: Бәдигөлкамал (1850), Могыйнетдин (1853), Фәхретдин (1855), Лотфулла (1856), Мотыйгулла (1865), Гатаулла (1873), Сафиулла (1870).

Могыйнетдин 1873 елда Мингаян исемле кыз белән кавышып, гаилә корган. Чистайдан кайтканда буранда адашып салкын тидергән, 33 яшендә үлгән, диләр, әгәр елы хак булса, 1886 елда вафат. Улы Мөбарәкша 1876 елда туган, хатыны – Әсма Габделкаюм кызы, никахлары 1896 елда теркәлгән. Мөбарәкша улы Мәгъсүм (1913) – Бөек Ватан сугышы ветераны, улы Азат Могыйнов (1959) әфган сугышында катнашкан. Исемнәр авыл мәчетләрендә имамнар язып барган метрика кенәгәләренә нигезләнеп бирелде.

Авылда язып алынган хәбәрләр буенча, Мөбарәкшаның кушаматы «моряк», кешеләр арасында дәрәҗәсе зур булган. Имештер, христиан дине әһелләре авылга бик еш килеп, чукынырга өндәп, халыкка «алтын таулары» вәгъдә итеп йөргәндә, аптыраштa калган кешеләр: «Морякнишләр, ул чукынырмы?» – дип, аңа караган. Ә «моряк» динен сатмаган, авылдашларына да поп тегермәненә «су ташырга» ризалык бирмәгән.

Мөбарәкша Могыйнов патша заманында авыл старостасы, таза тормышлы крестьян, совет чорында барлык мал-мөлкәтен колхозга бирсә дә, кулак дип гаепләнгән, әмма акланган, бераз колхоз рәисе дә булган. Үч алу нияте белән аның өстеннән бер авылдашы: «Элеккеге староста һәм кулак Могыйнов җыелышта советка каршы агитация алып барды»,– дип донос яза. Авылга кораллы кешеләр килеп, аны кулга алып, Чирмешәнгә илтеп ябалар. Иң кызыгы шунда, Мөбарәкша җыелышта катнашмаган, Чистайда булган. Бу хәлдән аны авылдашы Хатыйп Зыятдинов коткарган. Аның җыелышта булмаганлыгын документ белән раслап, совет концлагереннан коткарып кала. Шул кыска вакыт эчендә аның йорты да колхоз малына әйләнгән. Анда колхозга тимерче булып килүченең гаиләсен урнаштырганнар. Мөбарәкша гаиләсе белән Нәсибулла бабай йортында кыш чыга, ә яз айларында йортын кире кайтаралар. «Кулак Мөбарәкша» рәхмәт сүзе ишетмәсә дә, колхоз төзелешенә үзеннән өлеш керткән, төзелешне яхшы белгән, хәзергечә әйтсәк, прораб булган. Кагау тавындагы карьердан таш чыгарып, авылда 1927–1930 елларда хастаханә салганнар, таш нигез өстенә бура күтәргәннәр. Ул яңа бинасы төзелгәнче, 1970 елларга кадәр халыкка хезмәт иткән. Халыкка түләргә акча юк, ташылган ташларның күбесе кирәк булмагач, Мөбарәкша ташларның кубометрын 8–10 тиеннән алып, үзенә келәт салдырган, диләр...

Сүз уңаеннан тагын бер фактны искә алып китмичә булмый. Зиратта Билал исеме белән бәйле тагын бер кабер ташы бар. Өстәрәк сөйләнгән нәселгә бернинди дә катнашы юк. Таш шактый җимерелеп, ян-яклары яңгырлар белән юылып беткән, сыйфаты да әллә кем түгел, кирилл хәрефләрендә язылган исем дә бозылган. Кабердә Билалетдин (1870–1960) (ташта Билале сүзе генә күренә) улы Минхәер җирләнгән. Авылда нәселе яшәгәнлеге билгеле: Минхәер + Әбүбәкер + Алмаз + Фоат Минхәеров. Билалетдин – ясашный татар Гаделша улы.

## Атамаларга нинди серләр яшеренгән?

Без халык хәтерендә калган атамаларга да игътибар иттек. Еш кына ул атамаларда нинди дә булса хәбәр яшеренгән була. Авылны икегә бүлеп, Олы Ташлык (Олы Кәминкә-Большая Каменка) инеше ага. Аны бүлеп, икенче якка чыгу урыннарын «таш кичү» дип тә әйткәннәр. Инешнең авыл уртасындагы ташлы урыннан үткән тирәләрне «Айгыр ташы» дип атыйлар. Монда зур ташлар очрый, элек алар тагын да күп булган, алар хуҗалык максатларында да кулланылган, аларны кисеп-ватып та алганнар, каберләр өстенә дә бастырылган. Ташлык инешенең югары очтагы өлешен «Кече елга» дип йөрткәннәр. Түбән очтагысына (колхоз фермалары ягында) «Сай елга» дигән исем биргәннәр. Ә Елховой авылына таба киткән су ермагын «Тирән елга», диләр. Аның башлангыч урыны «Кое

башы» дип атала. Җәйге кызу көннәрдә басуда эшләүчеләр шуннан су алган. Совет чорында Тирмән буасы, Яшелчә буасы булган, хәзер алар юк.

Авыл һәм инеш атамасы «таш» сүзе белән бәйләнгән. Урысча «камень» сүзеннән «кәминкә» сүзе ясалган. Күршедә генә авылның адашы Югары Кәминкә гөрләп утыра. Төбәк тарихын өйрәнүче Ясәви ага Шәмсетдинов бу атама буенча кызыклы фикер әйткән: «Шик юк, татар, мәҗүси чувашлар бергә яшәгән бу авылның исеме урысча булмаган инде: ул йә Кәмин(ә) – аулак, тыныч, яшерен урын мәгънәсе, яисә, йә Кәрмин(ә), Камәнгә (у), шундый кабилә, ыру исемнәре булганлыгы билгеле. Гарәп, фарсы, татар, чуваш телләрендә сөйләшкән, укый-яза белгән халыкта русларның каменка сүзенә аваздаш бер сүз дә табылмас микәнни?!» – ди. Монда тагын бер гыйбарәне искәртеп үтик. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» китабында («Иман» нәшр., Казан – 1993, 223 б.) Кәминәнең ким, түбән дәрәҗәле, хур, яшерен дигән мәгънә белдерүе язылган. Урысча варианты тагын да кискенрәк яңгырый – ничтожный, позорный, скрытый. Әллә соң бу сүз көчләп чукындырылганнарга карата әйтелгәнме? Шундый кавемнәр безнең татар авылларында булган ич. Безнең тарих шул дәрәҗәгә төшкән ки (башка халыкларның тарихларын, диннәрен юкка чыгару өчен «өлкән абзый» бик тырышкан), һәр фаразда ниндидер код, тарихыбыз яшерелгән кебек, аны еш кына инкарь да итеп булмый. Тик шулай да, шәхсән үземнең, аксакал белән бәхәскә кермәстән, ике авылның да атамасы «таш-камень» сүзе белән бәйле дип әйтәсем килеп тора. Күрше авылның атамасы да документларга берничә калыпта кереп калган: Верхних Ташлов (Югары Ташлау, Ташлы); Каменный ключ (Ташлы Чишмә); Верхняя Каменка, Студёный ключ-тожь-Красный Яр-тожь (Югары Кәминкә, шулай ук Салкын Чишмә, шулай ук Кызыл Яр). Ясәви ага, төбәктә яшәгән халыкның авылларны башка исемнәр белән атавын да онытмаска кирәк, ди. Мәсәлән, Югары Кәминкәне тирә-як халкы Иске авыл, ди. Лашман – Яңавыл, Түбән Кәминкә – Түбән авыл, Сарабиккол – Әби авылы, Яңа Ибрай – Чәтрән һ.б.

Күрше Кармыш авылы белән Түбән Кәминкә авылы арасында Әләксий инеше бар. Бу шул тирәләргә хуҗа булган Алексей атлы сәүдәгәр исеме, ул шунда су тегермәне куйган. Түбән Кәминкә халкы тирмәнгә бик еш килгән, алыпсатарны шактый баетканнар. Шуның исеменә нисбәтле «Алексей тирмәне», «Алексей елгасы», «Әләксий елгасы», «Әләксий», «Урта тирмән» дигән атамалар халык сөйләменә кереп киткән. Әләксий тирмәненә алып төшә торган юлны «Чутыр юлы» дип йөрткәннәр, ул юл кыскарак һәм туры булган. Бу юлдан чутыр кушаматлы Идрис бабай Ивашкино авылына йөргән. Йөзе кара тутлы булганга шулай дигәннәр. Имештер, яшьләр шул юлдан чуаш авылына көмешкәгә чапкан.

Әләксий инеше белән Кармыш ягыннан килгән Сөлди (Сөлчә) инеше тоташкан урынны да «Әләксий кушылдыгы», диләр. Сөлди инеше сазлыклар аша еректан килә-килә ачык кояшта җылынып бетә, үзенә күрә сихәткә дә ия, диләр аны. Ә менә Әләксий инеше, киресенчә, чишмәләрдән туенганга күрә бик салкын. Ике инеш бергә очрашып кушылганнан соң, су үзлеге икенчегә әйләнә. 1935 елгы картада бу инеш «Күтәмә» дип бирелә, тегермән яки торак-амбар корылмалары, елга аша күпер салынганлыгы күрсәтелә (рабочий мост). Бәлки алар бу чорга инде юкка да чыккан булгандыр. Әләксий тирмәне, аның монда үзе һәм хезмәтчеләре, каравыл кунып кала торган урыс йорты булуы турында сөйләүче бик ачык дәлил бу. Күтәмә инеше (Кутеменка) элек безнең төбәктә волость (олыс) булып торган Күтәмә авылы эченнән диярлек килә. Күтәмә-Әләксий суына Юашка (Ивашкино) авылы ягыннан Шәрбән инеше дә туры килеп кушыла. Әләксий, Сөлди инешләре кушылган җирләрне Пекин–Мәскәү федераль юлы төзелеше кисеп үтә. Су агымы зур торбалар аша икенче якка күчерелгән. Сөлди, Күтәмә-Әләксий, Шәрбән инешләренең берләшкән сулары элеккеге Иншар поселогына 1–2 чакрым кала җирдәге Олы Ташлык инешенә кушылган урынны «Усия» дип бүгенге көнгә кадәр әйтәләр. «Усия» – урыс сүзе «устье», ягъни тамак, ике елга кушылган урын. Әләксий инешенең Күтәмә авылына кадәрге тармагын «Вахит инеше» дип тә йөрткәннәр. «Колхозлашу елларында кулак Вахит абыйны үтереп, шул инешкә ташлаганнар»,– дип сөйли халык. Бу фаҗигане икенче төрле дә сөйлиләр. Күтәмә авылына бара торган юл Шәрбән инеше аша уза. Вахитның атка тагылган тарантаста хатыны белән кемнәргәдер кунакка бармышы икән. Шул инешкә җитәрәк, ат нәрсәдәндер куркып, дулап китә дә, юлдан тирән чокырга барып төшеп, әйләнеп капланалар. Тарантас хуҗасы шунда җан тәслим кылган, һәм бу ямьсез урын «Вахит чокыры» атамасын да алган.

Олы Ташлык инеше – әйләнә-тирә мохиткә гүзәллек биреп торучы су чыганагы, ул вак балыкларга, сөлекләргә бай, урыны белән анда бака туйлары җырларын тыңлый аласыз. Бу инеш Югары Кәминкә поселкасы Кызыл Яр җирләрендәге сазлыклардан, җыелма сулыклардан һәм чишмә-кизләүләрдән туенып килә, анда коелар да булган. Түбән Кәминкә авылына җитәрәк Керкәле (Ибрай Каргалы) авылы ягыннан да чишмә суы Олы Ташлык инешенә килеп кушыла. Олы Ташлык 1980 еллар алдыннан юкка чыккан Саклык поселогы (Кармыш җирлеге) янында Шушма елгасына коя.

Күршедәге Кармыш авылы белән ике арада агучы Шәрбән (Олы һәм Кече Шәрбән) суына кадәр төшүче посадка (чәчүлек кырларын җилдән саклаучы агачлардан торучы калкан) халык сөйләменә «Кармыш посад-

касы» дип кергән. Аның тирәли сузылган юл Кармыш авылына килеп чыга.

«Шәрбән» атамасына аерым тукталып китик. Ул бик борынгыдан килгән сүз. Аксубай районында Шәрбән авылы, Шәрбән елгасы бар (Кирәмәт елгасының кушылдыгы). Әмма бездәге Шәрбән инеше ул яктан килми, бу сулыклар Югары Кәминкә белән Күтәмә авыллары арасындагы кырлыклардан һәм сазлыклардан саркып чыккан чишмәләрдән туена. Кем белә, элек су күп булган заманнарда бәлки ниндидер тоташлыгы булгандыр. Сүзнең шул тарафтан алынганлыгы яки шуңа бәйле булуы көн кебек ачык. Бу топоним бирегә ничек килеп эләккән, әйтүе кыен, моны ниндидер очраклылык дип тә әйтеп булмыйдыр, мөгаен, һәм Аксубай районына кадәр моннан шактый юл үтәсе. Шәрбән авылы 1680 елдан билгеле булса да, аның тарихлары тагын да ераграк гасырларга китә. Һәм, иң кызыгы, мондагы Шәһрибану чишмәсенә (гидроним), кыскартылган калыбы Шәрбән (ике иҗектән торган ойконим), имештер, 1100 еллап. Болгарда ислам динен рәсми кабул итүгә узган ел (2022 ел) шуның кадәр вакыт булуын һәркем белә. Ул гына да түгел, биредә бик күп археология истәлекләре табылган. Беренче һәм икенче Шәрбән шәһәрлеге, җирле халык телендә «кызлар капкасы», гомуми Болгар һәм монголларга кадәрге чор бу. Яки Идел буе Болгар дәүләтенә караучы 1–4 нче Шәрбән торлаклары, Шәрбән каберлеге...

Түбән Кәминкәнең эченә керсәк, элеккеге мәктәп янындагы тирән чокырны «Совет елгасы» дип йөрткәннәр, шул чорның истәлеге. Моннан елга аккан, хәзерге вакытта сазлыкка әйләнгән. Үз заманында шунда авыл Советы бинасы торганга шул исемне алган. Авылның бер башында Сәндерәле чишмә (кое) бар, астан караганда тау битеннән сәндерәдән аккан кебек су агып төшкәнгә шул исемне алган. Авылның икенче ягында Күкертле чишмә дан тоткан, тәме күкертле, анда төрле химик элементлар бар. Сәндерәле кое Югары Кәминкә ягына чыгып киткән якта тора, шул якны «Почта юлы» дип тә йөрткәннәр (совет чорында Югары Кәминкәгә барып почта алганнар). Аның каршысыннан ерак түгел, инкыйлаб (1917) елларына кадәр, Олы Ташлык инешендә бер бай буа ясаткан, имеш, ул дүртпочмак калыбында булган. Аның нинди максатларда кирәк булганын белүче юк. Бәлки ул анда тегермән куймакчы булгандыр. Буа озак тормаган, аны язгы ташулар бәреп киткән. Шул урыннар кипкәч, биредә иген киптергәннәр. Авыл эчендәге Мингата чишмәсе караучысы хөрмәтенә әлеге исемне алган. Бүген нефтьчеләр төзекләндергән килеш тора. Тагын Фонтан, Салкын чишмә, Югары чишмә, Изге чишмә, Камил чишмәсе, Хөҗҗәт чишмәсе, Кызыл Яр чишмәсе, Хәсәнша чишмәсе (кизләве), Вак чишмәләр – алар турында исемнәреннән үк беленә.

Калфак-калпак, Тәлпәк яки Түбәтәй исемендәге басу атамалары иң кызыклысыдыр, мөгаен. Картлар әйтүенчә, бер кыр түм-түгәрәк, түбәтәй формасында икән, аны милли баш киеменә охшатып шулай әйткәннәр.

Калпак белән түбәтәй – төрки халыкларда баш киемнәре һ.б. Бу атамалар белән җирле халык кыр-басуларны атап йөрткән, алар – авылның көньягында урнашкан 9 га җир биләмәсе, Югары Кәминкә белән ике арада ызан сызыгының чиге. Бу җирне Кагау тавыннан карасаң, ул аерылып тора, нәкъ менә калпакка охшаган. Шул кырның уртасында түбәтәй сыман түгәрәк ямь-яшел дымсу җир дә булган, вакыт узу белән ул җирне сукалап киптергәннәр. Тагын Алтылы дигән кыр бар. Ул Абасяк (Абый цык – мишәр диалекты) чокырына кадәр, шулай ук авылның көньягында, Олы Ташлык елгасының уң як ягына урнашкан 6 га җир. Бу җирне ерактан, өстән карасаң, алты санына охшаган. Шул җирлектә «Татарстан» колхозының сарык, тавык фермалары, әвен базы, кирпеч яндыру базлары урнашкан була. Алтылының көньягында, аңа терәлеп, Икеле кыры тора, зурлыгы чама белән 2 га, тау өстеннән карасаң, ул икеле санын хәтерләтә. Шуның сул ягында сарык табыры урыннары. Кара Чишмә белән Түбән Кәминкә арасындагы ызан сызыгы булган Кыркәминкә чокыры дип аталган бу җирдән ике авылның кайсысына юнәлсәң дә, үргә менәргә кирәк.

1980 елларда соңгы нигезе беткән Иншар поселогы белән Түбән Кәминкә арасын «черетмә», «черетмәлек», «черетмә урманлыгы» дип йөрткәннәр. Биредә сазлыклар, баткаклыклар, төрле су ерганаклары күп, инде кибеп юкка чыккан күллекләрне дә чамаларга була әле, торфлы урыннар да бар. Атама нәрсәнең дә булса черүе турында сөйли. Сазлыкларда черегән нәрсәләр күп булган. Кәминкәнең югары очында зур күл булуын картлар сөйләп калдырган, бу җир Габбас бабайлар тирәсендәрәк.

Иншар поселогының беренче атамасы – Батрак, поселокның яшәү вакыты – 1924–1980 еллар. «Татарстан» исемле колхоз булып оешкан, соңыннан бу исем төп авыл Түбән Кәминкәгә күчкән (ул баштан «Ирек» колхозы).

Заречная урамының төньяк-көнчыгышында Тирән елга дигән атаманы хәтерләүчеләр юктыр, мөгаен. Ул сусыз, кипкән, яр югарылыгыннан үлчәсәң, тирәнлеге урыны белән 2 метрдан артып китә, озынлыгы 1,5 чамасы ераклыкка сузыла; тирән елга урыны хуш исле куе печәнлеге белән дә данлыклы. Тирән елгага Ялхау посадкасы (Иске Баграж-Елховой) килеп тоташа. Бу посадка Әлмәт районы белән Чирмешән районнары арасындагы ызан сызыгына барып терәлә.

Түбән Кәминкә белән Елховой авылы арасында Сталин чокыры дигән сәер урынны белмәгән кеше юктыр. Бу хакта берничә хикәя сөйлиләр.

Имештер, Елховой авылы кешесе Миннекәев шуннан кайтып-китеп, Кәминкәдә совет властен оештырырга ярдәм иткән. Колхозчылар Сталинны бик хөрмәт иткәннәр. Чокыр янындагы күпергә юлбашчының портретын элеп куйганнар. Икенчесендә, имештер, шул ук совет чорында бу үтә алмаслык тирән чокыр аша бөртек ташыганнар. Хәлдән тайган, авырлыкларга түзәрлеге калмаган эшчеләр Сталинны кычкырып каргаган, «Ул идарә иткән еллар шул иләмсез чокыр төсле хәтәр, үтәргә катлаулы һәм газаплы»,– дип әйтә торган булганнар.

Өлкәннәребездән Габбас Гыйрфанов сөйләвенчә, Октябрь инкыйлабына кадәр авыл урамнарының берсен Арт урам дип йөрткәннәр. Шул тирәдә элек каенлык шаулап утырган, шуның уртасында күл булган, аны аккошлар да үз иткән. Боларның бүген берсе дә юк. Шул урамның бакчалары сулыкта торган яки су бик якын булган. Һәр йортның үз коесы булган, су өч метр тирәнлектән чыккан.

Авылда кечкенә таулыклар яки калкулыклар да күзәтелә: Вилдан тавы, Хөҗҗәт тавы, Кагау тавы; имештер, соңгысына Кагау кошлары оялаган. Күтәмә авылы ягына таба Кече Шәрбән аланы – халыкның җиләккә бара торган урыны.

Кагау атамасына аерым тукталып үтәсе килә. Анда берәр сер яшеренеп ятмыймы? Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә кагайту, каган, кагаю, кагу кебек сүзләр кергән. Кагайту – һавада, җилдә тотып киптерү (итне, балыкны һ.б.). Кагау атамасы каган сүзенә бәйле түгелме дип тә уйлаган идем. Кызганыч, туры килеп бетми. Каган – урта гасырларда төрки халыкларның хөкүмәт башлыгы титулы. Кагу-сугуга да туры килеп бетми, башкача аңлатмасы юк. Моны җирле диалектологик сүз дип кабул итик. Авылда каз бәбкәләрен саклаганда һавадан һөҗүм итүче каргаларны, козгыннарны, элегрәк хәтта бөркетләрне дә «кагау кэәш-кэәш, кагау», дип куганнар. Авылларда бүген бәбкә саклаучы малайлар-кызлар юк инде. Әнә шул кошларны гомуми итеп, кагау дип әйткәннәр булса кирәк. Икенче яктан, бу сүз җилпү хәрәкәте ясауны яки ике куллап һавага таба селтәнүне аңлата кебек (кошлар канаты турында). Әхмәт Ерикәй дә бер шигырендә: «Киң тугайда канат кага бер тургай»,– дигән (у хәрефе өстәсәң, кагау була). Афзал Шамов әсәрендә бер җөмләгә салган бу сүзне шул ук канат кагу (кагау) дип аңлап була: «Куначадагы әтәч, канат кагып, актыккы мәртәбә кычкыра да пырылдап җиргә төшә». Яки Гариф Гобәйчә: «Дилбегәне кагуга... алаша элеп алып китте». Заманында Олы Ташлык инеше ышыкланып аккан, зур булмаса да, ерактан ук горур һәм серле күренгән ташлы Кагау тау ярын бөркетләр дә, төрле козгыннар да үз иткән, шунда гына оя корган. «Авылда күп очракта козгыннарга карата кагау дип эндәшәләр иде»,– дип сөйли өлкәннәребез.

Айгыр ташы яки «айгыр ташлары» атамасын аңлатуы да авыр. Авыл эченнән узган инеш ярында яткан зур ташларны әнә шулай атаганнар. Алар дүртпочмаклы, махсус киселгәнгә дә охшаган. Барысы да үзлегеннән дүрт кырлы булгандыр дисәк тә, ышануы авыр. Ни өчен айгыр ташлары икән ул? Бәлки аның күләмен, зурлыгын айгыр җегәрлеге белән чагыштырганнардыр? Әллә борынгы заманнарда бу ташларны атлар белән тарттырып караганнармы? Шул ташларны кузгатырга 6–7 айгырның да көче җитмәс кебек. Әллә бер җор телле адәмнең ташларга карата шаяртып әйткән сүземе бу? Вәт табышмак! Айгыр ташлары янында чишмәләр дә бар. Чишмәләр, ташлар белән атлар арасында күзгә күренмәгән, колакка ишетелмәгән охшашлык бар кебек. Халыкның «айгыр ташы», «айгыр чишмәсе», «алаша коесы», «атлар улагы» дигәнен еш ишетергә мөмкин. Авыл кешесе әнә шундый мифологик кызыклы чагыштырулар уйлап тапкан.

Элекке заманда авыл йортлары Центральная урамындагы зиратка терәлеп үк торган яки Күтәмәгә китә торган юл уңаена төзелгән, ике арада посадка булган. Өлкәннәр авылның иң борынгы ягы Мәссәр абзыйлар ягындагы кырлыкта, ферма тирәләрендә булган, диләр. Монда җир астыннан су бик начар чыгу сәбәпле, халык Олы Ташлык инеше агымы белән аска таба йортлар төзи башлаган. Авылның Күтәмә ягында Матвей тау башы яки Матвей сырты дигән җир дә бар. Аны тау дип тә булмый, ул бер күзгә күренми торган калкулык кына. «Матвей» атамасы Күтәмәнең үзендә дә бар икән, исем шул якка ишарә булса кирәк.

### Халкымның чишмә башы – гасырлар төпкелендә

Әле авыллар нигезләнмәгән вакытта безнең төбәк сулыкларга, шифалы үсемлекләргә, төрле кош-кортка, җәнлекләргә бик бай булган. Хәзерге иген кырларында урманлыклар, әрәмәлекләр үсеп утырган. Соңыннан кешеләр килеп утыргач, урманлыклар киселә, ачык җирләр сөрелеп, бөртекле культуралар үстерелә. Бигрәк тә совет чорында әйләнә-тирә мохитка техник революция нәтиҗәсендә санап бетергесез зыян килә. Күп кенә агачлыклар, әрәмәлекләр юкка чыга, күлләр һәм ермаклар, сазлыклар кибә, сулыклар агулана. Совет дәүләте таралу белән нефть чыгару кимегәч, экологик җиһазлар кулланылгач, 1990 еллардан соң табигать савыга башлый, сулыклар чистара, әрәмәлекләр әкренләп терелә, инде ярты гасыр безнең якларда күзәтелмәгән торналар, аккошлар, җәнлекләр күренә башлый. Ләкин соңгы елларда Әшәлче битум заводы төзелүе табигатькә куркыныч тудыра. Битум, күкерт (сероводород) исе авылларга тарала, җир астында битумны эретеп алу технологиясе катламнарның табигый торышын зарарлый. Тирә-як авылларга аннан бернинди дә матди ярдәм килми диярлек. Бәлки аннан экологиягә өлеш чыгаруларын үте-

неп, дәүләт даирәләренең ишеген шакып торырга кирәктер, ишетми калмаслар, иншалла! Әмма җирле халык дәшми калуны өстен күрә.

Авыл тирәсендә зур елгалар, күлләр юк. Авылны икегә бүлеп, Олы Ташлык (Большая Каменка) инеше ага, аңа Алексей белән Сөлди инешләре кушыла.

Җир йөзендә бер тамчы суга зарыккан ком чүлле, зур далалы җирләр бар. Бу яктан караганда, Түбән Кәминкә агымсуларга, чишмәләргә бай. Авылга беренче нигез салучылар да бик акыллы, зирәк булганнар, чишмәле һәм бай уңдырышлы җирләрне сайлап ала белгәннәр. Безгә Аллаһы Тәгалә бүләк итеп биргән һәм дә борынгы бабаларыбыздан мирас булып килгән бу ганимәтләрнең кадерен беләбезме? Табигать безгә рәнҗеп, чишмәләр күзләре белән мөлдерәп карамыймы? Ерак гасырлардан агып килгән чишмәләребез безгә ни әйтергә телиләр, «онытмагыз, без – җирдә яшәешнең беренче чыганагы», диләрме? Бу хакта изге китапларда, риваятьләрдә, төрле мифологияләрдә күп тапкырлар әйтелгән, аңлатылган һәм адәм баласы әле тумаганда ук алдан кисәтелгән. Су – дөнья яратылышының башлангычы. Җир шул дөньяви дәрья эченнән алып чыгылган. Шунлыктан Су Тәңресе – төркиләр табынган уникe төп Тәңре сыйныфына керә торган илаһи зат. Ә Ислам дөньясында Зәм-зәм чишмәсе иң бәрәкәтле беренче чишмә булып санала, күп гасырлар буе мөселманнар шуннан су эчә. Имештер, чишмәдән агып чыккан су «зәм-зәм» дип челтерәгән. Гарәп тарихчылары раслаганча, Мөхәммәд пәйгамбәр Зәмзәм суын җирдәге иң яхшы су дип саный. Ни өчен эчсәң, ул шуңа хезмәт итә, суны эчкәндә уйлаганың чынга аша. Шушы изге суны эчеп, сәламәтләнергә, сусауны басарга, туенырга мөмкин. Мондый чишмәләрнең авылның Олы Ташлык инеше буенда күпләп очравы, төрле тәмгә, сихәткә ия булулары – үзе бер могҗиза.

Атамасы бик тә серле булган Айгыр ташы янындагы чишмәдә мөгаллимә Миңсылу Зәкиулла кызы мәктәп укучылары белән елына ике мәртәбә, яз айларында өмә оештыра, шунда ук балаларны аш-су белән сыйларга да вакыт таба.

Китап языласын белгән милләтпәрвәр авылдашлар Хәлимә Гайнуллина, Равилә Юнысова авыл чишмәләрен барлап, рейд үткәрделәр, чишмәләрне ведеотасмага төшерделәр. Рәхмәт яусын. Иң беренче итеп чишмәләрне искә алу – яхшы эш. Кагау тавыннан өстәрәк кенә Сәндерәле чишмәсе яки кое бар. Бу кое, һичшиксез, таш чыгаручы каторжаннарның, солдатларның яки гади эшчеләрнең кулы белән ясалгандыр, дип уйлап куйдым. Әгәр ул, чыннан да, чишмә икән, димәк, табигать аны илаһи көч белән үзе ясаган. Аксакаллар әйтүенчә, Кагау тавы өстендәге сәндерәле кое урынында зур тал агачы үсеп утырган, ул черегән (яшен ташы бәр-

гән дип тә әйтәләр). Төпке ягы аерылып, шуннан су агып торган, аннан халыкның су алуы билгесез. Үлән белән капланган, югалган шул чишмәне эзләп таптык. Әле суы да бар икән, дымлы урынны кул белән ерып җибәрү дә җитте, ул бөркеп кайнап, җан кереп, челтер-челтер агарга да тотынды. Ерганагын казып киңәйткәч, су ярдан аска, ирекка китте. Сәндерәле чишмәгә авылның көньягыннан төшсәк, инешнең уң ягында, калкулык өстеннән өч җирдән бәреп бер агымга кушылган Сәндерәле чишмә инешкә ага. Элеккеге заманнарда аның суы мул булгандыр, яз айларында бүген дә тирә-ягы чәчәкләргә күмелә, аңа бал кортлары хуҗа була. Аллаһының рәхмәте, Аллаһының могҗизасы бу. Ул чишмәле коены почта ташучы Сәгыйть Әхмәдулла улы Могыйнов карап, тәртиптә тоткан. Хәзер халык җае булганда чистартып тора. Әлеге кое-чишмә үз заманында бик тирән булган, дип сөйлиләр.

Түбән Кәминкә җирлегендә эчәргә яраклы 21 су чыганагы бар, аларның 6–7сеннән су алырга мөмкин. Егермеләп чишмәдән инеш аша салынган күпер янәшәсендәге Мингата чишмәсе генә төзекләндерелгән. Күкертле чишмәдән әле бүген дә су алучылар бар, кемгәдер шифасы тия. «Фонтан чишмәсе» дип йөртелгәне, суы фонтан кебек бәреп, ургылып чыкканга күрә шул исемдә. Чишмә урынында дүртпочмаклы таш булган, шуңа тимер торба ялганып, эченнән су чыга, сул ягыннан инеш ага иде, дип сөйлиләр. Ул борынгы, күптәнге чишмә, ә янәшәдәге инешкә килеп, керләр чайкаганнар, басмасы да булган, суы да шактый тирән икән. Халык бу чишмәне, аның тирәсен бик яраткан. Авылның Иншар ягы башында буа дамбасы куелгач, сусаклагычта су күтәрелә, язын эрегән кар сулары да шунда җыела. Ә чишмә су төбендә калса да яши, исеме дә халык хәтереннән чыкмый. Элек, буа дамбасы булмаган елларда, инешнең ике як яры да ачык булган, хәзер ярлар таллыклар, шунда ташланган чүпләр белән тулып, сулык урыны-урыны белән күренми диярлек. Бүген авыл тирәсендәге иң зур су чыганагы – Олы Ташлык инешендәге буа. Ул бик матур манзара булып тирә-якны бизәп тора, халыкның су керә, ял итә торган урыны. Кызу көннәрдә бирегә күрше авыл яшьләре дә килә. Буаны аккошлар, кыр үрдәкләре дә үз иткән, әллә кайлардан җыелган балыкчыларны да күрергә мөмкин.

Терлекләр лагерендагы Салкын чишмәдә ачымасын өчен сөт тутырылган флягаларны саклаганнар. Күп кенә чишмәләрнең исемнәре онытылган, чөнки бүген һәр йортка су кергән.

Авыл тирәсендә элеккеге чишмәләрнең эзе сакланган әле. Иң кызганычы, авыл урамнарына су колонкалары урнаштырылгач, бервакыттан соң өйләргә су кертелгәч, чишмәләргә игътибар кими, алар кадерсезләнә, чүп басып китә. Миншәһит Ибраһимов абзыйларның бакча башындагы

чишмәне элек Мөгания әби чистарткан, бүген Миңсылу Зәкиулла кызы карый. Чишмә Олы Кәминкә (Ташлык) инешенә агып төшә. Заманында авылның ике ягыннан да бирегә килеп су алганнар.

Хәсәнша бабай чишмәсе дә Олы Ташлык инеше буенда. Аның шифалы суын эчеп үскән балалар инде әби-бабайлар булган. Ул яр битеннән чыгып, челтерәп аккан, әле кайчан гына бирегә көянтә-чиләк аскан кызлар килгән, егетләр чишмәгә төшеп, сусауларын баскан. Инде барысы матур бер әкият кебек, көянтәнең нәрсә икәнен белмәгән буын да үсеп җитте. Шул бәрәкәтле чишмәне Мингата, Шәфикъ бабайлар чистартып, төзекләндергән, киңәйтеп торган, алар инде мәрхүм. Чишмә чистартылмаган, ләм белән тулган, чишмәгә килүче сукмакларны да үлән күмеп киткән. Чишмәгә берәр изге бәндә сукмак салырмы?

Камил һәм Алмаз абзыйлар бакча башында да итек киеп керсәң, баткаклык, чытырманлык эчендә калган чишмәләрне күрергә була. Без төшкәндә чишмәне Рамил Җамалетдинов чистартып ята иде. Чишмәгә элек тимер кран беркетелгән тимер бөжра куйганнар, ул да тора икән әле. Камил абзый куйдырган улакны да күрергә була. Камил чишмәсе. Аны күршедәге Туймәт авылы чишмәләре кебек тагын да матурайтып булыр иде. Читтән килеп берсе дә бу эшкә алынмас. Янәшәсендә тагын бер чишмә кешеләрдән ярдәм сорый. Яшьрәк вакытында бу чишмәне Марат Җамалетдинов казып, тирәнәйтеп, төзекләндереп торган. Монда да чишмә өстенә тимер бөжра куелган, ул казан сыман. Гадәттә чишмәләрне таш бөжралар эченә утырту, тирәсен таш белән әйләндереп алу киңәш ителә. Камил чишмәсе урнашкан ярым утрауны вак чишмәләр ергалап тора. Кай җиренә бассаң да, су бәрә. Әгъзамов Рөстәм абыйларның бакча башыннан алып Низамов Ришатлар бакча башына кадәр ике арада көчле тибешле чишмәләр күзгә чалына. Низамова Камилә апаларның бакча башындагы ярдан зәңгәр балчык чыккан, халык шуны аяк-кулларына, билләренә, җилкәләренә сылап, буыннарын дәвалаган. Тагын бераз аскарак юнәлсәк, күкертле Хөҗҗәт чишмәсен күрәбез.

Суфия апаларның бакча башындагы чишмәнең тәртиптә тотылганы ерактан ук күренә. Чишмә күңелгә рәхәтлек бирә торган көчкә ия диярсең, суы казандагы кебек кайнап тора, җанга тынычлык өсти сыман, тирә-ягында озын, зур агачлар шаулый. Чишмәләр су чыганагы гына түгел, рухыбыз көзгесе. Туган җирнең пакь сулары уй-ниятләребезнең чисталыгына үлчәм булсын.

Югары чишмә ике җирдән бәреп чыккан ә авылның югары очы Кызыл Яр тирәсендә. Бу тирәдә яшәүчеләр элекке заманнардан ук бирегә бер сукмактан йөргән. Суны ат арбасына мичкәләр, чаннар куеп та, кечкенә тачкалар белән дә ташыганнар. Бигрәк тә Мәгъсүм абый Могыйнов

гомере буе моннан флягалар белән су ташыган икән. Хәзер сукмагы да куе үлән астында калган. Элек чишмәнең ярлары да кечерәк булган, казлар пычратмасын өчен өстенә бурасы да, каплавычы да куелган. Хәсәнша бабай үзе исән чакта чын күңелдән караган аны. Чиләк белән батырып алгач та, суы куермый, чөнки комлы ташы гасырлар буе юылып килгән. Хәсәнша бабай чишмә сулары күбрәк килсен дип, бу ләмле җирне трактор көрәге белән казып киңәйткән, шул сәбәпле, яры да зураеп калган. Әмма, дөресен әйтик, табигать кеше нәфесенә буйсынмаган, су кимемәгән дә һәм артмаган да, үзе теләгән күләмдә тәртип белән бүгенге көнгә кадәр ургылып чыга, хәтта каралмаса да. Тик шулай да авылда төрле сәбәпләр белән су беткәндә чишмә кешеләрнең хәтеренә төшә, бирегә су алырга ашыгалар. Шул ук югары очтагы «Җиде вак чишмә» дигән урын да аеруча кызык. Җиде – мифик сан, аңа бәйле күп кенә табышмаклар, риваятьләр бар. Күбесе таш арасыннан саркып яки кайнап чыга. Аларны элегрәк Наил Гафиятуллин чистартып торган, бүген берничәсе генә каралган. Монда укытучы-мөгаллимә Миңсылу Зәкиулла кызы да үзенең укучылары белән килеп, зур эшләр башкара, ерганакларны ләмнән арындыралар, тирәдәге талларны кисәләр. Көне буе диярлек шунда казыналар. Аллаһының рәхмәте яусын үзләренә. Сөйләүләренчә, авылда тагын билгесез чишмәләр бар икән әле.

Өлкәннәребез хәтерендә Изге чишмә дигән матур урын да сакланган, аны яшьләрдән белүчеләр юк диярлек. Онытылган һәм каралмаган чишмәләрнең тагын берсе ул. Минҗамал әби аның иң соңгы карачысы булгандыр, мөгаен. Имештер, монда узган гасырлардан ук килеп догалар укыганнар, теләкләр әйткәннәр, илаһи көчтән нәрсәләрдер ялварып сораганнар. Бик хаста кешеләр өчен шуннан таң суы алып, суны өшкереп тә дәваланганнар. Еллар коры килеп, явым-төшемгә тилмергән вакытларда бөтен авыл әбиләре чишмә янына җыелып, намазлар укып, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр яудыруын үтенгәннәр, шунда ботка пешергәннәр. Ул бала-чага өчен зур бәйрәмгә әйләнгән, алар су сибешеп тә уйнаган. Шул ук көнне яки икенче көнне яңгыры да әзме-күпме сибәләп киткән. Шундый чишмәләргә карата сөйләнелгән утырма хикәяләрне һәр авылда ишетәсең, бигрәк тә өлкән буыннан. Имештер, чишмә суын, дога укып, үзеңә дигәнен уң, кешегә дигәнен сул кул белән аласың. Алган суны биек урынга куясы. Савытның капкачын өч тапкыр бисмилла әйтеп ябасың. Аны кайберәүләр 40 көн саклап та эчәләр. Таң суын иртәнге намаз арасында алалар дигәннәрен дә ишеткәнебез бар. Чишмәгә акча яки көмеш тәңкәләр ташламаска, дияләр, чөнки акча чиста әйбер түгел. Су төптән кайнап чыга, анда көч, нур салынган, шуңа бик туры карамаска әйтәләр. Чишмә өстендә бит юарга да ярамый икән. Чөнки синең битеңдә нәр-

сә генә булмаган – талаш яки пычрак, ә күз дөньялыкта ни күрмәгән. Бу гыйбарәләр чишмә суы чиста торсын, аңа кешедәге тискәре энергетика-мәгълүмат сеңмәсен өчен әйтелгән, «Су яхшыны да, яманны да үзенә бик тиз язып ала», дип юкка гына әйтмиләрдер. Безне чишмә тирәсендә төкеренергә, сүгенергә ярамый, ямьсез сүзләр әйтмәскә, дип өйрәттеләр. Әби-бабаларыбыз никадәр акыллы булган, болар барысы да безне кеше итүче тәрбияви чаралар ич. Ислам динендә чишмәләрне карау, киләчәк буынга калдыру инсанга савап, зур дәрәҗә өстәгән.

«Әгәр белсәгез, эчә торган суларыгыздан хәбәр бирегез». Ни хәлдә чишмәләрегез, кардәшем! Нәни дулкыннарга юл сал, фатиха бир, галиҗәнап Кеше! Сибгат Хәким әйтмешли, Шәйхи карт өстәп куя күк: чишмәләр тыгылмасын.

## Кое казысаң, үзең буе казы

Элек авылдагы коелар бик мөһим су чыганагы саналган. Арт урамда, ягъни Нагорная ягында йорт саен диярлек кое казыганнар. Бу урамны узган заманнарда «Бозау урамы» дип тә йөргәннәр. Коелардан бүген дә файдаланучылар бар. Элек шәхси коелар Азат Сәлманов, Габдрахман Гайнуллин, Минталип Закиров, Салих Юнысов, Мингаяз Хөснуллин, Фәсих Гафиев, Искәндәр Сәлахов, Гомәр Хөснуллин, Рәшит Моталлапов, Минсагыйрь Хөснуллин, Минненәгыйм Мусин, Бадамшиннар, Габделхак, Тәлгать Гыйрфановларда булган. Бу коелар бар да бер сызык буйлап казылган. Ул җир астындагы су юнәлешен күрсәтә. Борынгылар анысын да яхшы чамалаган.

Арт урамның артында колхоз кырлары башлана. Шунда 1930 елларда казылган Торналы коесын өлкәннәребез хәтерли. Шул тирәдә ат абзарлары торган. Имештер, Шентала, Чирмешән якларына йөк төяп киткән атлар юлларында очраган сулыклардан эчмәгән, кайткач, шул коеның гына суын эчкән.

Салих Юнысов йорты каршында бүген дә матур бер кое бар. Аны яңартуда Фатыйх Юнысов башлап йөргән. Коены күмәкләшеп казыганнар, бурасын каен агачыннан куйганнар. Бура белән җир катламы арасына тыгызлап каен ботакларын да ваклап салганнар. Суга каен тәме дә чыгып торгач, ул һәркемгә дә бик тансык булган. Бу кое 1960 елдан билгеле.

Центральная урамының көньяк өлешендәге кое Салих Кәлимуллин һәм Нурислам Сөләймановлар йортлары арасында казылган. Бу эшне 1961 елда Мәгъсүм Могыйнов оештырган, суы 12 метрдан чыга. Әлбәттә, бу авыр, әмма саваплы эш күмәк көч белән башкарыла, суга кадәр бура төшерәләр. Безнең көннәрдә ул ишелеп күмелә һәм бурасы чери башлагач, Азат Мәгъсүм улы күрше-күлән белән бергәләп, шуны төзекләндер-

гән, Барый абзый Гафиятуллин белән материаллар алып кайталар. Агач бура урынына бетон боҗралар куялар.

Центральная урамының төньягында Әсгать Мусин (хәзер монда Наил Закиров яши) белән Фатыйма Галәүтдинова йортлары арасында Әюп коесы бар. Бу коены казытуда Әсгать абыйның этисе Әюп бабай белән каршы күршеләре Шакир Мотаһаров көч салган. Кое 12 метр тирәнлектә, 1957 елда казылган. Коеның суы бүген дә бар. Аны тәртипкә китерүчеләр: Гали Шаһиев, Якуб Мотаһаров.

Тагын төньякка аскарак китсәк, Әхәт Закировлар турысында, Салих Идиятуллиннар белән Әнвәр Зариповларның нигезләре (элек монда Мәдхия Мотыйгуллина яшәгән) арасында, Әнвәр Зариповның элеккеге нигезләре (анда Рәхмәтулла бабай йорты) белән Шәһит Моталлаповлар арасындагы тыкрыкта да коелар булган.

Әхәт абыйлар янәшәсендәге коены Дәүләтша Ханов уллары Нәҗип, Азат, Марат казыган, аларга барлык күршеләре дә ярдәм итә. Кое 1990 елларда ташландык хәлгә килә, бурасы череп ишелгәч, аны ябып куялар.

Хастаханә йорты биләмәсендә дә кое казыганнар. Заречная урамындагы коены Рөстәм Әгъзамов җитәкчелегендә күрше-тирә бергә җыелып, 1960 елларда казыган. Ул 11–12 метр тирәнлектә, агач бурага корылган. Бу кое белән бәйле кызык бер хәлне әле дә хәтерләп сөйлиләр. Кое яныннан Зөһрә апа Әгъзамованың почтага барышы икән. Каршысына Азат Шәфиков килә. Ул исәнләшә. Зөһрә апа җавап бирергә дип борылса, Азат абзый юк, аты басып тора, теге коега барып төшкән. Зөһрә апа тиз генә чылбыр тагылган чиләкне кое төбенә төшерә. Бу ыгы-зыгыны күреп, Әсгать абый Җамалетдинов та ярдәмгә йөгереп килеп җитә. Азат абзыйның тәненә зыян килми, ул берни булмагандай үз юлы белән китеп бара.

### Җиде мишәр кыйссасын кем язган?

Түбән Кәминкәдә туган Габдулла Салих улы Зыятдинов (1936) һөнәре буенча инженер-геолог, электән үк әнисендә сакланган ниндидер дәфтәрләрдән кат-кат күчереп язылган китапчыкларны берләштереп, нәшриятта рус телендә тирән эчтәлекле монография бастырган: «Возникновение людей, племен, народностей, народов и наций, изменение их взаимоотношения с истечением времени, вопросы гражданства, 1000 неотложных и трудноразрешимых задач». Типография ООО «Глаголь», Казань-2013 год». Иң кызганычы, китапта кереш сүз юк. Үзенең нәселе турындагы мәгълүматларны һәм әлеге күчереп язылган дәфтәрләрнең язмышын китап эчендәге тарихи язмаларга ялгап җибәргән, һәм шактый гына аңлаешсызлык күзәтелә. Әмма шулай да, китап тарих укучылар өчен гаять кызыклы, аны анализлау, бәя бирү яки аңа рецензия язу безнең максатка керми. Анда телгә алынган тарихи сәхифәләр галимнәрнең хезмәтләрен-

дә киң колачлап яктыртылган инде. Ә бит бу китапларны ничек итеп уттан, үз тарихларыннан йөз чөергән мәнсез кешеләрдән саклаулары, аны кадерләп тотулары ул заман өчен үзе бер батырлык, бер гыйбрәт. Аның бер өлеше утта янгандыр дип уйлыйм. Татарны гыйлемле һәм китаплы, мәчетле халык, дип юкка гына әйтмиләрдер, мөгаен. Моны зыялы һәм милләте өчен җан аткан кеше генә эшли ала.

Мине иң гаҗәпләндергәне шул булды: «После взятия Казани в 1552 г., Иван Грозный не посадил на Казанский трон Шах-Галия, послал его собирать налоги с земель его же ханства в пользу Руси! Он из хана сделал налоговика! Этого было мало. В декабре 1552 г. и на земли мишчар Шах-Галия пришли налоговики и «крещенские» отряды, и мишчары поднялись против царских войск и участвовали с 1552–1557 гг. в восстаниях Среднего Поволжья... Много мишчар переселились в сторону Казани и Восточный Булгарии: на земли ляхыр[1], эсегиль, чермиш и типтар, т.е. на левобережье Камы и Иделя (Волга). Нашу деревню Түбән Кәминкә обосновали мишчары – 7 человек, сбежавшие от царских притеснений в 1554 г. Они женились на дочерях ляхыр (история возникновения деревни Нижняя Каменка), (226 бит)». Шул кыска мәгълүматтан кала авыл тарихы буенча берни юк.

Бу юлларны укыгач, бик күп каршылыклы сораулар туа. Түбән Кәминкәгә 1554 елда җиде мишәр нигез салган – бу язма риваятьме, әллә зур тарихка автор үзе фараз итеп өстәп куйган шәхси фантазияме, әйтүе кыен, чыганакның кайдан алынганлыгы әйтелмәгән. Казан ханлыгы чорына багышлап язылган хезмәтләрдә дә мондый мәгълүматның очрагань юк. Безнең төбәктәге авыллар әле 1730 еллардан соң гына билгеле, бәлки бу мәгълүмат изге нияттән уйлап чыгарылган бер хыялый фикер генәдер. Ул заманда нинди Түбән Кәминкә булсын ди. Шәхсән үзем, бу хәбәр бик кызыклы яки, мактанып, менә без бит бу, тамырлар әнә каян килә, дип күкрәк кагырлык булса да, кабул итә алмыйм, һич ышанырлык түгел. Шундыйрак бер фикергә Кармыш тарихларын язганда юлыктым. Анда да: «Казан ханлыгы чорында Иван Грозный куып җибәргән татарларның нәселе Кармыш авылында көн күрә»,– диелгән иде. Әйе, сүз дә юк, урыс балтасыннан һәм урыс тәресеннән курыккан халык хәзерге Чирмешән районнарына да килеп чыккандыр. Татар халкы җан асрар өчен кайларга гына качып китмәгән. Аллаһы Тәгаләнең әмере булмагач, «кара йөрәкләр» татар токымын юк итә алмаган, хәзер исә хәтта үзләренә дә юкка чыгу куркынычы яный. Шуны да әйтергә кирәк, әлеге китапта Габдулла ага искә алган «В записях деревни Каменка» дигән бүлек яки язма юк. Әллә соң ул Казан ханлыгын илбасарлар җимергәч, бу якка

[1] Локыр –казан татарларын мишәрләр шулай атаганнар (ред.).

качып килгән җиде мишәр хакындагы хәбәрне күз уңында тотканмы «в записях... » дип? Мин китапны кулга алгач та, бик зур язма көткән идем. Кызганыч ки, автор белән кара-каршы утырып, әңгәмә корып булмый.

Түбәндәге өземтәдә – Габдулла агада сакланган күчерелгән кулъязмаларның тарихы һәм туганнарының тормышы турында язылган истәлекләре. Шул караңгы елларда да халыкның киләчәккә, гаделлеккә өмет белән караулары, бабаларыбыз тарихы дип кайгырулары, нык рухлы оптимист булулары игътибарга лаек. Габдулла аганың әнисе Сәлимә апа Минхәер кызы Кармыш авылы кызы, диләр, Кәминкә килене булган. Ире Салих Түбән Кәминкәнеке. Димәк, бу китапларның Кармыш авылы кешеләрендә сакланганы яхшы аңлашыла. Салих гаиләсе белән 1946 елларда ук Үзбәкстанга күчеп киткән. Язмада танкист Хаматгали исемле кеше дә телгә алынган, автор аны «әтием ягыннан бабам», икенче урында «абыем» дип язган, ярыйсы гына буталган. Әнә шул Хаматгали «Сугыштан исән кайтсам, китапларны нәшриятта бастырам»,– дигән. Ләкин бу кешенең эзе фронтта югала, мондый исемле кеше Кармышта да һәм Кәминкәдә дә юк:

«...С целью покорения восточных народов, Пётр первый снарядил 6-ти тысячную русскую экспедицию. Ни один член экспедиции не вернулся на Русь. Хивинский хан боялся вторжения русских на его земли, так как у русских были пушки и винтовки. Отрядам Малой Орды было поручено заманить членов экспедиции вглубь степей. Русские прошли по пескам Кара-Кума, Кызыл-Кума. Остатки русской экспедиции погибли в песках близ Нураты. Так читала моя мать в моей молодости, не знаю, из какой книги. Я не встречал такие строки в книгах «Кто мы булгары? Что ожидает нас в будущем?», «Исторические записи мишара Хатыпа ибн Фатыха», «Письмо потомкам», «В записях деревни Каменка», «Минувшие дни Булгар», «Ислам в царской России» (последнее напечатано в СССР в 1936 г.).

Мать подлинники этих книг хранила у деда Аглям бабая. Она боялась пожара, так как он уничтожит ценнейшие книги, оставленные ей отцом Минхаиром. В 1916, 1920 гг. семья Минхаира дважды были погорельцами. Но дед спасал книги, они принадлежали народу, являлись удостоверениями булгар, татар Казани на владение землей, водными бассейнами, на пользование лесами, полями, богатствами земных недр.

Дед научил мою мать копировать эти книги, прятать от людей. Мать знала иероглифы, клинопись, разные шрифты арабской графики, обучалась латыни в Чистополе. Смерть деда оборвала учебу матери. Она жила в доме у сестры и там приводила все книги в порядок, переводила на татарский со старотатарского и тюрко-булгарского языков.

Во времена деда Минхаира «Письмо потомкам» было переведено на татарский язык Алексеем из Кутами. Мать «Письмо потомкам» переписывала дважды.

1927 г. мать вышла замуж. Отец был твердым, жестким человеком, знаниями не блистал, т.к. его учили только до афтияка, по нынешним меркам имел образование четырех классов.

1928 г. мать со своими соседками поехала в район. Там в избу-читальню сдала первую копию книги «Письмо потомкам». В это время там находился представитель райкома. Он взял книгу, выборочно прочитал и начал кричать на мать: «Салима, мы с русскими строим одно государство, твоя книжка мешает в сближении наций равноправных граждан». Рукопись матери он бросил в печку, а вечером отца вызвали в сельсовет и строго предупредили, чтобы мать не таскала древние книги.

Отец камчой избил мать, как ездовую лошадь. После этого она отнесла чемодан с ценнейшими книгами к своему деду Аглям бабаю. Когда отца не было дома, она со мной ходила к деду Агляму смотреть целостность книг. Когда отца забрали на войну, мать хотела принести эти книги домой, но побоялась. Брат Ханиф все таскал к знакомым, да, еще может случиться пожар. А все же дед Аглям и его жена были постоянно дома. Копию книг держали у себя, а подлинники были у Аглям-бабая. Но судьба книг была иная. Мы не горели. Мой отец Салих часто ездил в деревни и поселки, Кутему (раньше волостной центр), в Новотроицк пилить доски русским. За свой труд он привозил пиломатериалы, дрова, пшеницу, муку и мясо. Его отец Зиятдин был известным человеком, работал дорожник-мостовиком, а его отец Гафур был старостой в селе Нижняя Каменка.

Было жаркое лето 1945 г., все люди на сенокосе. Мы, пацаны у речки. Пожар начался с дома деда Агляма. Они со своей женой находились на дальнем огороде. В это время дети развели костер. Когда мы с мальчиками с реки прибежали на место пожара, дом был охвачен, люди с ведрами бегали вокруг дома, пожарники еще не приступили к тушению огня. Воду таскали с речки. Тут с поля прибежала мать и кинулась в горящий чулан. Её успели схватить и оттащить в сторону. Через несколько мгновений крыша дома рухнула, горящие головешки полетели вверх. Усилия пожарных не дали ожидаемого результата. Один за другим загорелись еще два дома. Горящие головешки угрожали пожаром всей деревне. Вдруг начался сильный ветер. Пожарники сменили тактику. Они начали обливать водой крыши близстоящих домов. В этот день силы всей деревни были мобилизованы на тушение пожара. Несмотря на это, 6 домов сгорели дотла, а вместе с ними и древние рукописи наших предков.

Мой дядя Хаматгали вернулся с финской войны. Я с матерью сидел у стола. Она мне читала про вождя скифов-фракийцев Гэгуне. Тут постучали в дверь. Мать крикнула: «Заходите». На пороге – военный. Мать заплакала и повела меня к нему, в слезах говорит: «Иди к дяде Хаматгали». Мать пошла на кухню, принесла хлеб и сахар (тогда сахар был дефицитом, поэтому его прятали от нас). Я стою перед дядей и смотрю на него, а он на меня. Хорошо запомнил, он был среднего роста, чуть выше матери, рябоватый, загорелый, на нем длинная, зеленоватая шинель, на голове остроконечный шлем, на воротнике ромбики из материи. Дядя оступил назад, присел, протянул ко мне руки и стал звать меня к себе. Я попятился назад, быстро поднялся на скамейку, а оттуда на стол, полез за наш медный самовар и чуть не опрокинул его. Дядя успел удержать наш большой самовар, аккуратно поднял меня на скамейку и усадил меня на свое правое колено. Тут подошла мать. Дядя на столе увидел раскрытую книгу о скифах, сшитую из ученических тетрадей. Он матери сказал: «Салима апа, ты молодчина, сына учишь нашей правде. А мы на фронте защищаем её. Ожидается война с немцами. Если вернусь живым, то о наших предках будут знать все. Добьюсь печати даже «Письмо потомкам». Скоро мой отец женил дядю. Потом Хаматгали обучал солдат Красной Армии на Кызыл-Яре. Иногда, по утрам, он заезжал к нам и забирал меня собой. На полигоне меня оставлял дежурному. Хорошо помню, стоящие рядами зеленоватые, брезентовые палатки, огороженные канавками.

Потом дядя уехал на войну. В ноябре 1941 г. в танке проехал через Красную площадь. Он защищал Москву, участвовал в окружении немцев под Сталинградом. Дважды горел на Курской дуге. В первый раз он писал матери в ученической тетради: «Танкта яндым, күзем күрми…». Адрес на треугольнике был подписан другим почерком, дядя вслепую не мог писать ровно. Мать не знала, как сообщить Накиба-женги о горе Хаматгали. Поэтому она вечерами плакала, а днем шла на полевые работы. Впоследствии десяти дней, вечером, к нам забежала Накиба-женги. Её круглое, красивое лицо горело огнем, глаза сияли счастьем. Она обняла мать, поцеловала её щеки, села рядом с ней на скамейку, меня посадила на колени. Только потом достала треугольное письмо дяди Хаматгали. А там написано: «Күзем ачылды, сугышка керәм…». Через несколько дней Накиба-женги получила «черное письмо». Не поверила. Она ждала Хаматгали 21 год. Когда дочь Наиля вышла замуж и уехала, она вышла замуж за престарелого мужчину. Дядя Наджиб, сын Аглям бабая, погиб в Отечественную войну. Его младшие братья Фатых и Хатып были направлены в ФЗУ и оба погибли в шахтах» (259–260, 272–273 битләр)…

# Түбән Кәминкәгә беренче күчеп килүчеләр

*Бу дөньяга килеп киткән адәмнәрнең*
*хисабы юк,*
*Үлемгә баш идермәскә бу дөньяның*
*китабы юк.*

Авылга беренчеләрдән булып килүчеләрне ачыклау өчен иң мөһимнәрдән саналган ревизия язуларын (ревизские скаски) өйрәнеп чыгу тиешле. Бу документлар кемнең кайда туганлыгын, яшәгәнлеген яки кайсы төбәккә күчеп киткәнлеген ачып сала, ул шулай ук халык санын күрсәтүче чыганак. Россия империясендә беренче ревизия 1718–1727 елларда узган, бу чорда Кәминкә турында бернинди хәбәр юк. Ә менә икенче ревизиядә (1743–1747 еллар) авылга беренче килүчеләрнең яки шунда яшәүчеләрнең барысының да исемнәре язылган. Бирегә якынча 1734–1738 еллар аралыгында Казан өязендәге Олы Тигәнәле авылыннан Дүсәй Искәндәров килеп, авыл урынын оештырган. Иң күп күчеп килүчеләр дә шул чорга туры килә. Ул йөзбашы (сотник) буларак, төбәккә халыкны урнаштыруда зур хокукларга ия булган. 1762 елгы өченче ревизия буенча, старшина Дүсәй – якын-тирәдәге Яңа Кади, Кара Чишмә, Иске Баграж (Елховой), Кәминкә, Кыязлы, Үтәмеш, Элмәле, Түбән Карамыш (Кармыш дигәне дә булган, ике аерым авыл булып теркәлгәннәр), Туймәт һ.б. авылларның йөзбашы. Аның идарә итүе Идел буе халыкларын урыс православиесе чиркәве тарафыннан кыргыйларча мәҗбүри чукындыру елларына туры килә. Дүсәйнең бу вакыйгалар чорындагы эшчәнлеген, сәяси карашын ачыкларлык хәбәрләр күренми. Әмма шунысы аермачык аңлашыла, үз карамагындагы татар авылларында беренче биш вакытлы намаз мәчетләре, бәлки әле җәмигъ мәчетләре дә аның хәер-фатыйхасы белән төзелгән дип әйтеп була. Әлбәттә, мондый кешегә рәсми патша даирәләре, чукындыру сәясәте алып баручы изге атакайлар шикләнеп, кырын караганнар. Православие чиркәвенең әлеге сәясәтенә хокукы чамалы гына булган Дүсәй дә моңа тулы көченә каршы тора алмагандыр. Татар авылларына чукындырылганнарны кертергә туры килгән, ихтыярсызлары үзләре теләп тә һәм куркытылып та, малга кызыгып чукынучылар булган, бу вәхши сәясәт татар авылларында тамыр җибәрә алмаган. Авылларга читтән килгән чукындырылганнарны урнаштыру, аларның санын арттыру, бөтен бер төбәкне урыслаштыру яки христианлаштыру, мәчетләр төзүне чикләү максатында бик мәкерле алымнар белән башкарылган. Йөзбашы Дүсәй Искәндәров һәм укымышлы дин әһелләренең эшчәнлеге, гомумән, җирле халыкның үз кыйбласында нык торуы нәтиҗәсендә генә бу «үләт казасы» таралмыйча кала. Ул гына да түгел,

Дүсәй бабай Түбән Кәминкәне зур авыл дәрәҗәсенә җиткергән, мөһаҗирләрне беренче булып ул кабул иткән, яңа торак нигезен күрсәтүче дә ул. Зур кәрван булып килгән күченүчеләрне дә төрле авылларга бүлгәләү аның фәрманы белән башкарылган. Һичшиксез, Түбән Кәминкәне нигезләүдә өлеше бик зур, шунда үзе дә яшәгән бит. Авылыбызга халыкны шул шәхес җыйган дисәк, бер дә арттыру булмас.

Дүсәй бабай Олы Тигәнәледән килгән, дидек. Хатынлыкка да шул авыл кызларын алган. Бу авыл Татарстан Республикасының хәзерге Алексеевск районы биләмәсендә тора. Ул бик борынгылардан санала, унҗиденче йөзнең беренче яртысында кенәз Өмрәк Мәмәшев җирләрендә төзелгән. Бирегә 1661 елда Уразгилде Яковлев җитәкчелегендәге йомышлы мишәрләр күчеп килгән. Унтугызынчы йөзнең беренче яртысында халкы алпавыт крәстияннәре (элекке йомышлы, шул исәптән морза Чокиннар, ясаклы татарлар, керәшен татарлары) катлавына керә. Халыкның төп шөгыле – игенчелек һәм терлекчелек, мичкә ясау, кәсепчелек һәм һөнәрчелек, 1878 елларда крәстияннәр баш күтәрүендә катнашкан, XX гасыр башында өч мәчетле, икътисади яктан Түбән Кәминкәдән әллә ни аерылмый кебек. Бу чорда Тигәнәле Казан губернасының Спас өязе Полянка волостена кергән.

Олы Тигәнәле авылында яшәгән Искәндәр картның ике улы булуы билгеле: өлкәне – Кормай, кечесе Дүсәй 1688 елда туган. Бу нәселнең бик булдыклы, кыю, халык арасында дәрәҗәле булганлыгы күренә. Олы Тигәнәле ревизия язуларында Кәминкәгә күчеп китүчеләр исемлегендә Дүсәй Искәндәров (елы күрсәтелмәгән) һәм абыйсының улы Нургали Кормаев (1694) язылган. Кормай бик иртә дөнья куйган. Нургали Кәминкәгә килгән булса да, монда озак яшәмәгәнгә охшаган, бәлки авыл урынын карап яки белеп, ошатмыйча киткәндер. Аның эзе башка авылда күренә. Ул бик соң гына өйләнгән, 1744 елда ишле гаиләсе белән яшәгән җиреннән чыгып киткән. Чебоксарка авылын (ТР, Яңа Чишмә районында) нигезләүчеләрнең берсе. Балалары шунда гаилә коралар. Ләкин бәхетсез татарга җил гел каршы дигәндәй, Чебоксарка татарларына тиешле җирләрне 1770 елларда бер урыс алпавыты сатып алган. Татарларга бер генә юл калган: чукынсалар гына шул җирдә утырып кала алганнар. Әмма алар диннәренә хыянәт итмиләр, бөтен булган мал-мөлкәтләрен арбаларга төяп, бу авылдан китәләр. Ни өчен абыйлары яшәгән Кәминкәгә килмәүләре дә аңлашылып бетми. Күрәмсең, бу вакытта анда да болытлар куера башлагандыр (чукындыру). Кормай нәселе Керкәле дигән авылга килеп чыга (ТР, Лениногорск районы). Нургалиның улы Габдри (1736) Чистай өязендәге Шахмай авылыннан Мортаза кызы Мәнәгә (1743–1787) өйләнгән, икенче хатыны Нәсихә

Габделмәннән кызы (1747–1789). Алар вафатыннан соң Чистай өязендәге Кармыш авылыннан Зифа Әмин кызын алган. Бу нәселнең дәвамчылары 1810 елларда Бөгелмә өязендәге Кодаш авылына күчеп киткәннәр. Татар авылларында яшәгән кешеләрнең кайсын гына алсаң да, ике арада туганлык җепләрен табарга була. Ә Дүсәйнең бүгенге көннәрдә дә нәселе авылда күп таралган. XX гасыр башында Түбән Кәминкәдә яшәгән Нургали Габделганиев (1901), Хәлиулла (1897) һәм Нуретдин (1900) Гарифуллиннар, Минфатыйх Гарифуллин (1904), Насыйбулла (1884), Касыймулла (1898), Хәсән (1903) Нигъмәтулиннар, Миндар Лотфуллин (1903) шуның дәвамчылары һ.б. Мәсәлән, Чирмешән районнары авылларында хуҗалык җитәкчесе булган Галимҗан бабай Сөләймановны (1898) фронттан кайтканда 1945 елда бандитлар үтергәнен һәркем белә. Иншар поселогында җирләнгән ул. Шәҗәрәдәге бабалары исемен санап китик: атасы Сөләйман, бабалары Фәйзулла – Габделфаяз – Гази – Биктимер – Дүсәй Искәндәров.

Укучыга төшенергә җиңел булсын өчен ревизиядәге исемнәрнең кайберләренә аерым тукталып үтәбез. Кәминкәгә Дүсәй бабайга кадәр дә кайбер гаиләләр килгән. Икенче ревизия язуларына да аларны беренче итеп теркәп куйганнар. Исемнәре дә, яшьләре дә, килгән еллары да хаталы язылганы аңлашыла. Аларның кайсы вакытта туган җирләреннән чыгып китүләрен белү өчен шул авылның беренче ревизиясен өйрәнергә яки карарга кирәк. Гомәр Тәнәев бирегә Долгий Остров авылыннан 1731 елда күчкән, ә улы, 16 яшьлек Шәфи 1721 елда килгән, диелгән (1705 елгы). Яшьләрен 1719–1721 елгы ревизия белән санасак, шуңа ышансак, бу вакытта Гомәргә 70 яшь булган (1651), ә 1731 елда аңа 80 яшь булыр иде. Монда шик туа. Олы яшьтәге Гомәр һәм аның улы Шәфи, чынлап та, Кәминкәгә килеп җиткәннәрме? Шәфи 16 яшендә ерак юлга чыгып киткәнме, әллә бу якларны карап кына кайтканмы? Моңа җавапны беркем дә язып калдырмаган. Әмма шунысы көн кебек ачык, алар Кәминкәдә яшәгәннәр. Кәминкәнең 1745 елгы ревизиясендә Гомәр Тәнәевкә – 60 яшь (ягъни 1685 елгы), уллары Чәләйгә – 23 (1722), Шәрифкә – 20 (1725), Чәләйнең улы Галигә – 2 яшь (хатын-кызлар күрсәтелмәгән). Шәфи күренми (аның шул ук Шәриф булуы мөмкин). Гомәр Тәнәев 1748 елда Кәминкәдә вафат, улы Чәләй яшьли 1752 елда дөнья куйган, Шәриф исә 1752 елда сөргенгә куылган. Чәләйнең улы Зәет 1746 елда, ни сәбәпледер, чукынган. Монда шуны әйтергә кирәк, Гомәр Тәнәев белән бергә авылдашы Исмәгыйль Ишмәтов (1700), аның улы Баязит та (1725) килгән, елы күрсәтелмәгән, шул ук 1730 еллар дип уйлап була. Исмәгыйль Кәминкәдә 30 еллап яшәп, 1761 елда вафат. Долгий Остров – хәзерге ЧР Батыр районының Озын Куак авылы, якынча 1601 елда нигезләнгән,

1796 елдан Сембер губернасындагы Буа өязе Батыр волостена кергән, элгәре Казан өязенеке.

Гомәр Тәнәевләр белән бер вакыттарак Нижгардагы Собачий Остров (Сафаҗай) авылыннан ике бертуган Әсәй белән Муса Җәфәкәевлар Кәминкәгә 1726–1727 елларда килгән. Дәлил: Әсәй Кәминкә кызына өйләнгән (1762 елгы ревизияне кара), улы 1727 елда туган. Иң беренче булып бирегә шулар юл ярган дип тә әйтеп була. Әмма без шулай да авылны җыючы Дүсәй Искәндәров дип әйтәбез.

Кәминкәгә Югары Чепкас авылыннан да гаиләләр күчеп килә. Бу авыл элек Сембер губернасы Буа өязенә кергән (элек Казан өязендә торган), исеме 1661 елдан билгеле. Үз заманында Казан ханлыгы чорында нигезләнгән дигән фаразлар бар. Бүгенге көндә ТР, Чүпрәле районы Чепкас-Илмәт авылы. Мәсәлән, шуннан Кормаш Кайбердин (Корман Акбердин, 1709) якынча 1738 елларда килгән, 1759 елда вафат, Аднагул исемле улы калган.

Сембер губернасының Буа өязе Яңа Тинчәле авылы (элек Казан өязендә) XVII гасыр башында оешкан (ТР, Буа районы). Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, алар Россия империясендә патша Романовлардан беренчеләрдән булып мәчет төзергә рөхсәт алганнар. Бу авылдан килгән кеше Хәсән Бибәков (1695), ике улы Габдерәшит (3 яшь) белән Габделмәт (1 яшь) 1743 елдан Кәминкәдә. Хәсән 1761 елда вафат, Бәшир исемле улы 1749 елдан рекрутлыкка бирелгән.

Сембер губернасының Буа өязе Дрожжанау волосте Кокшуват авылыннан (1796 елга кадәр Казан өязендә) Сәет Әхмәтовлар (1717 елгы; яки Әлмөхәмәтов) Шәрбән авылына 1729 елда чыгып киткәннәр. Әти-әнисе юлда үлгән булса кирәк. Яшенә ышансак, яшүсмер ерак юлга берүзе чыгып китмәс иде. Ә чынлыкта алар Шәрбән авылына кермәгәннәр, Кәминкәгә киткәннәр, башка сәбәпләр дә булырга мөмкин. Сәет 1752 елда вафат. Балалары Әит, Ярмөхәммәт, Зәбидә, Зәйнегөл тормышларын Кәминкәдә дәвам иткәннәр. Авылның дөрес атамасы – Кушкувак (Кушкуак), XX гасыр башында мәчет-мәдрәсәле, гөрләп торган авыл булган, 600 дән артык кеше яшәгән. Совет чорында авыл Чүпрәле районына кергән, 2002 елда ике кеше яшәгән, инде бүген алары да юк.

Осип Гомәров (1694) Малый Чилны авылыннан 1743 елда Елховый овраг авылына күчкән, диелгән, әмма эзе Кәминкәдә күренә. Бәлки бу авылны ошатмыйча киткәндер. Балалары: Кадер, Мөхәммәт, Динкәй, Шәфи. Кадер (Нәдер) 1782 елда вафат. Осип һәм аның улы Мөхәммәт малга кызыгып чукынып, 1762 елга кадәр авылдан киткәннәр. Кадер белән Динкәйнең нәселе авылда калган. Малые Чилны ЧРсындагы Красноармейский районы Кече Чаллы авылы булуы мөмкин, чувашча Кече

Челлы. Осип татарлашкан чуваш булса кирәк. Аларның күбесе чукындыруга кадәр балаларына татар яки төрки исемнәр кушкан. Чүпрәле районында Кече Чынлы авылы булуын да онытмаска кирәк.

Струлеевой овраг авылыннан Исай Кармышев (1680), улы Дәүләтша белән Кәминкәгә киткәннәр, елы һәм кайда киткәнлеге күрсәтелмәгән: «сошли до прежней переписи для жительства в разные уезды Казанского уезду за Волгу, а в которую деревню не показано». Авылның кайсы төбәктә булуы ачыкланмады. Исай Кәминкәдә 1752 елга кадәр яшәгән. Балалары кыска гомерле булган: Әбләзи (1735) 1757 елда, Сәмирхан (1740) белән Сәлимә (1743) 1748 елда вафат. Ә Дәүләтша (1716) исемлесе Ногай юлындагы «новопоселенную деревню Клявлино»га барып урнашкан.

Алатыр өязендәге Старые Какерли авылыннан Әит Димкәев (1690) Тәтемә авылына 1732 елда күчкән, диелгән. Әмма ул анда китмәгән, Кәминкәгә килеп йорт салган. Хатыны Бостан Сөендекова белән 6 бала үстергәннәр, барысы да Кәминкәдә төпләнеп калган. Бикбул исемле уларын 1756 елда рекрутлыкка алганнар. Иске Кәкерле авылы ТР, Чүпрәле районында, бу авыл Казан ханлыгы чорында ук булган дигән хәбәрләр бар. Сембер губернасының Буа өязе (шулай ук Казан губернасы Свияжский өязендә дә торган) Полевые Бикшики (Кыр Бикшиге) авылыннан Бәкәйкә (Бәчкә) Әсәкәев (1705) Белая Гора авылына 1737 елда чыгып киткән. Әмма ул анда тукталмаган, Кәминкәгә китеп барган; Батырша исемле улы булуы билгеле. Бүген бу авыл ЧР Батыр районына керә.

Сембер губернасындагы (элгәре өяз, административ-территориаль берәмлек) Шәйморза, Шатыршан, Иске Чокыр, Большой Терешка һ.б. авылларының беренче ревизия язуларында Кәминкәгә күчеп китүчеләрнең исемнәре һәм еллары табылмады. Әмма аларның шул авыллардан Кәминкәгә килеп урнашканлыклары Түбән Кәминкә авылының икенче ревизия язулары белән раслана. Сембер губернасы 1796–1928 елларда гамәлдә саналган. Әлеге тарихи шәрехнамәдә Россия дәүләт архивы документлары, борынгы актлар файдаланылды (фонд 350, оп.2, дело 1157, 3130, 2991 һ.б.). Монда шуны да әйтеп узабыз, без 1745 һәм 1762 еллардагы ревизия язуларындагы авыл исемнәренең бүгенге атамаларын, авылларның кайсы төбәкләрдә булуын ачыклауга омтылыш ясадык, беренче күчеп килүчеләрнең нәсел юлларын ачыкларга тырыштык һ.б.

*А.Г. Ахунов*

# ТАТАР ДӘҮЛӘТЛӘРЕ КУЛЛАНГАН СӘҮДӘ АКВАТОРИЯСЕ

*(Ахыры. Башын укыгыз №№ 3, 4, 2023)*

**4) Сәкъ-инә иделе (Дон) елгасының башы һәм Идел кушылдыгы Ука иделе (Ока) елгасы арасындагы «көнбатыш» «тартаннар»:**

Борынгы аурупа карталарында Дон елгасы «Сагину» дип күрсәтелә. Урта гасыр географларын аз гына төзәтеп, елганың дөрес төрки атамасы «Сакъ инә (ана) елгасы» булган дибез. Заманында Кубрат хан оештырган «Бөек Булгария» яки «Иске Булгария» биләгән җирләргә – Дон бассейнына хазар һәм буртас кабиләләре хуҗа була. Анда Шиһаб Мәрҗани телгә алган «Мәҗгария дәүләте» (Әл-Букри хезмәтендә – «Моджгария» – А.А.) оештырыла. «Киев Русе» җирләрен күрсәткән карталарда бу дәүләт белән ике арадагы чик «крайна Алания» дип теркәлгән. Дәүләт атамасы башкачарак та булуы ихтимал. Көнбатыштагы Днестр елгасын да кисеп узучы мәшһүр тарихи «Траянваллары» дәвамын тәшкил иткән ныгытмалар безнең Идел үзәненә үк килеп җиткәнен күпләр белми дә. Меңәр чакрымга сузылучы балчыктан өелгән, өстән караганда казналыктагы тешләрне хәтерләткән шушы ныгытмалар безнең халыкта «Сәд-и-Сагбан» (варианты – «Сәд-и-Шагбан» – А.А.) дип аталган. Томанлы, буталчык риваятьләрдән аңлашылганча, ныгытмаларны, имеш, «алыплар заманында» «еланнар патшасы Шаһморанга каршы» «Сам баба төзеткән». Бу вал «Гад кавемнәре яуларына каршы» төзетелгән ныгытмаларның өченче чиге булырга тиеш! 1613 елда Хессел Герритц төзегән «Московия картасы» буенча, сәд-валның көнчыгыш өлеше кайдан узуын билгеләү мөмкинлеген бирә. «Рось буе ныгытмалары» Сула елгасы буеннан соң, Сәкъ-инә иделе (Дон) башларын тәшкил итүче елгалар белән Ука иделенең (Ока елгасы Идел бассейны елгасы – А.А.) уң як кушылдыклары арасындагы субүләр сырт буенча дәвам иткән һәм, ахыр чиктә, Идел елгасының бүгенге Саратов, Волгоград шәһәрләре арасындагы уң як ярына барып тоташкан. Геритс картасында «туры сызыкны» хәтерләткән ныгытмалар бүгенге карталарда, чынлыкта, проекциядә «көянтәне» хәтерләтә. Әлбәттә, 1647–1655 елларда мәскәүлеләр тарафыннан төзетелгән һәм Тамбов, Мичурин (элекке Козлов) аша узучы «Татарский вал» («Белгородско-Симбирская оборонительная линия») белән тәңгәл килми, билгеле. Димәк, урта гасырларда «Идел Болгары» белән «Мәҗгария дәүләте» (Кубрат хан оештырган «Бөек (Иске) Болгар» урынында барлыкка килгән) арасындагы чик шушы «Сәд-и-Сагбан валы» буйлап узган! Бүгенге археологик эзләнүләр һәм аэросурәтләр

бу валның алга таба Иделнең сул як яр буеннан бүгенге Әстерхан шәһәренә кадәр сузылуын раслый. Кытай тарихында «елан-кешеләр явы» һәм якынча кайсы чорда шундый вакыйгалар булуы турында мәгълүматлар теркәлгән. Шулай ук тугандаш казах халкында да ныгытмаларны Сам-баба белән бәйләп бәян ителгән риваятьләр сакланган. Шушы ныгытмалар аша йөзгечләрне күчерә торган берничә «тартан»-«волок» булганы билгеле. Сәүдә су юлларын кыскартып, түбән Идел аша йөзеп тормый гына, Ука иделеннән Дон елгасына йөзгечләрне күчереп, Кырым якларына барып ирешергә мөмкин булган.

Ока елгасының уң як кушылдыгы Прона елгасына коючы Ранова елгасында берничә «тартан» булган:

1) **«Дубок тартаны»** – Ранова елгасыннан Дон буенда утырган порт-лиманлы Дубок кальгәсенә йөзгечләрне тартып күчергәч, Дон буйлап агым уңаена йөзеп киткәннәр;

2) **«Ряса иле тартаны»** («Рясная (Рясоилинская) переволока») – алда әйтелгән Ранова елгасыннан Хупта исемле кушылдык башындагы «тартан» аша Дон бассейны елгасы Урман Воронежы инеше буенча, Воронеж елгасына күчеп, елга тамагындагы олы юлда да урнашкан Юл-кирмән каласы (хәзерге Воронеж шәһәре) янында Дон кушылдыгы Воронеж елгасы аша Дон агымына эләккәннәр;

3) **«Кочур тартаны»** («Кочуровский волок») – шул ук Ранова елгасыннан аңа койган Юеш Полотебня инешеннән «тартан» аша Донга коючы Кочур тамагына йөзгечләрне күчереп, Дон буйлап йөзеп киткәннәр.

4) **«Вёрда – Юеш Табола тартаны»** («Вёрдо-Мокротоболский волок») – әйтелгән Ранова елгасыннан аңа коючы Вёрда инеше башына йөзеп менеп, «тартан» аша Дон бассейнына керүче Юеш Тобола елгасына йөзгечләрне күчергәннәр.

Ока елгасына коючы Мукшы (Мокша) елгасы кушылдыклары Цна һәм Вад елгалары башларыннан Донга коючы Хопёр елгасы кушылдыгы Ворона елгасы башлары бик якын урнашкан. Димәк, анда да «тартаннар» булган.

Ока һәм Дон елгаларын **Тайдула** каласы (Алтын Урда ханы Җәнибәкнең әнисе Тайдула тарафыннан нигезләгән бүгенге Тула шәһәре – А.А.) тирәсендә тартан, йә болак аша «ялгау» хаҗәте табигый. Ике олы сәүдә юлларын болак-канал ярдәмендә Петр I заманында тоташтырып, **«Ивановский канал»** казылган. Ока елгасы Упа исемле кушылдыгы аша Дон елгасы белән тоташтырылган.

Ока елгасы буенда расиф-пристань булган һәм олы коры җир юлында утырган **Кораб** (урыс телле чыганакларда **«Кураб»**, «кораб» («корабль») сүзеннән – А.А.) исемле кала булганы билгеле (хәзерге Орлов өлкәсе Кромы районы Пашково-Лужки авылы урынында). Күрәсең, монда йөкләрне

төяп-бушату урыны (перевалочная база; перекладной пункт) булгандыр. Хәзерге Брянск шәһәре тирәсендә, Десна елгасына койган Свинь инеше буенда урнашкан «Свен монастыре» (бүгенге Супонево авылы янында, Брянск өлкәсе) янында XVII гасырда «Кырым ханлыгы» һәм «Речь Посполитая» сәүдәгәрләре белән сәүдә итешү өчен «Свен ярминкәсе» оештырылган. Сәүдә юллары кисешкән урын булуны исәпкә алганда, урта гасырларда да бу тирәдә мөһим сәүдә базары урнашкан булуы мөмкин. Әйтергә кирәк, шул тирәдән Днепрга коючы Десна һәм аның кушылдыгы Сейм елгалары да башлана. Алда әйтелгән «җир кендеге» сыйфатламасына да тәңгәл килә торган урын!

**5) Сәкъ-инә иделе (Дон) һәм Идел елгаларының урта агымда бер-берсенә якынлашкан урынында булган «Бөек тартан» яки «Великий перевоз». Каспий, Кара һәм Азов диңгезләрен бергә бәйләүче елга-«тартан» сәүдә юллары турында.**

Идел елгасы үзенең урта агымында (чама белән бүгенге Саратовтан Волгоград каласына кадәр арада) Дон (Сәкинә иделе; Танаис) елгасы белән бик якын булып, 60–70 чакрым ераклыкта гына янәшә диярлек ага. Менә шушы арада Иделдән «Мәҗгария дәүләте» җирендәге Дон елгасына һәм киресенчә, Доннан «Идел Болгары» җирендәге Идел елгасына күчә торган өч «тартан» булган. Идел ярында урнашкан **Бәлҗәмин** (хәзерге Дубовка), **Сарычин** һәм **Тартанны** (хәзерге Волгоград урынында булганнар) исемле татар калаларында «тартаннар» булган. Шул «тартаннар» аша Дон елгасы буенда урнашкан лиман-портлы торак пунктларга корабларны күчергәннәр. *«В старину узкое пространство между Волгой и Доном, где обе реки сходятся на расстояние около 70 верст, называлось «переволокой»* (чынлыкта «Переволока» төньякта булган, монда «Великий перевоз» – А.А.). *Существовало три «волока»: между речками Камышинкой и Иловлей, от нынешней Дубовки до Качалино, от Царицына* (Волгоград – А.А.) *до Калача* (Калач-на-Дону – А.А.). *Междуречье Волги и Дона латинскими буквами было обозначено, как «Великий перевоз» на карте немецкого дипломата, барона Сигизмунда Герберштейна, приезжавшего в Московию послом от императора Максимилиана I в 1517 и 1527 годах»* [Исаева: 2012. https://vpravda.ru/kultura/mesto-dlya-vvoda-teksta-3473/.12].

Дүртенче тартан итеп **Сарытау** һәм **Үкек** исемле борынгы татар калаларының лиман-портларына тукталган корабларны янәшә генә сазлыктан башланган Дон елгасына коючы Иловля инеше (татарча «ләмле елга» буладыр) буйлап, корабларны ярым сөйрәтеп, ярым йөздертеп Донның үзәк агымына күчерә торган «тартанны» әйтергә мөмкин. Урта гасырларда Госман Төркиясе белән берлектә шушы арада болак-канал казылган. Бүген дә кулланышта булган «Волго-Дон каналының» барлыкка килү тарихы

Алтын Урда чорына бәйле. Дон елгасыннан Азак (Азов) диңгезенә йөзеп, аннан Кара диңгезнең көнчыгыш яры буйлап, Истанбулга барып булган.

Тасвирланган Идел һәм Дон елгалары арасындагы «тартаннар», чынлыкта, Каспий диңгезен Кара диңгез белән тоташтыручы «күпер» хезмәтен үтәгән. Әлбәттә, бу диңгезләрне Каф (Кавказ) таулары аша аккан елгалар аша да «тоташтырган» сәүдә су юллары булган. Тарихи чыганакларда Каспийга коючы Кура һәм аның кушылдыгы Аракс елгалары аша Кара диңгезгә коючы Фасис (Риони) елгасына күчелә торган борынгы су юлы хакында искә алына. Әмма VI гасырда Фарсы шаһы Хөсрәү I Ануширван Кавказдагы «Албания», «Иберия» һәм «Колхида» дигән тарихи өлкәләрне үз биләмәләре эчендә, ә «Таглы Джидан»ны тышта калдырып «Тимер-капус» («Бабел-әб-Ваб»; «Садд-ал-Либин») стенасын төзеттереп куя. Зур Кавказ сырты түбәләре арасындагы тарлавыкларны диварлар белән томалатып, үткелләргә тимер капкалар куйдырткан. Шулай ук Каспий диңгезенең көнчыгыш ягындагы Копетдаг таулары буйларында да борынгы «Сәд-и-Искәндәрүн» диварын ныгыткан. Борынгы Котлы («Готта») өлкәсенә, легендар Әйкә, Саба җирләренә илтүче юллар һәм Евфрат (Буранун; Фират), Тигр (Диҗлә) елга башлары бабаларыбыз өчен «Каф тау артында», «дивар тышында» торып калган. Дагыстандагы Дербент шәһәрендә бүген дә шундый бер капканы һәм дивар өлешләрен тамаша кылырга мөмкин. Билгеле инде, ике диңгезне «тоташтыручы» башка «маршрутлар» да булган: 1) Каспийга коючы Кума елгасыннан Ергени тавы һәм Ставрополь калкулыклары арасыннан аккан, Азов диңгезенә коючы, Маныч «бугазына» күчеп, Маныч-Гудило күле буйлап йөзеп булган. «Ергени» – калмыклар биргән атама, татарча «Улка тавы» булган, «улыкай» дигәннән; 2) Каспийга коючы Терек елгасыннан Кара диңгезгә коючы Кубань елгасына күчеп була торган су юлы булуы ихтимал. Чөнки борынгы «Хәзәр каһанлыгы» баш каласы Сәмәндәр Терек елгасы буенда урнашкан була; 3) Дон елгасының сул кушылдыгы Сал (Джурак-сал) елгасы, элгәре «Йөрүк Сал» дип аталып, төп сәүдә коры җир юлы ориентиры булган. Ихтимал, Каспий һәм Арал диңгезләре тоташ бер «Сармат диңгезен» тәшкил иткән чорда халык телендә «бугаз» дип аталучы Маныч сызасы да су белән тулы, ә Йөрүк Сал елгасы сәүдә су юлы булгандыр дибез. «Сал» атамасы урысчага «плот», «сплав» дип тәрҗемә ителә. Бу инде сәүдә су юлы белән турыдан-туры бәйләнешен күрсәтә.

**6) Тартар иделе (Обь) һәм Инәй-сай иделе (Енисей) елгалары арасындагы «Көнчыгыш тартаннары»:**

Бүгенге татар телле халык формалашкан тарихи ареал чикләрен исәпкә алып, көнчыгышта Обь һәм Енисей арасындагы «волок»-«тартаннарны» шартлы рәвештә «Көнчыгыш тартаннары» дип атау дөрестер. Чөнки

Җүчи олысына Енисей үзәне «кыргызлар биләмәсе» буларак кертелгән. Енисей атамасы якут телендә «ене сай» – «ана (инәй, әни, әнкәй, инәки) елгасы» дигәнне аңлата. Мәкаләдә шушы көнчыгыш төбәктә урнашкан «тартаннарны» санап чыгу белән генә чикләнербез:

Обь кушылдыгы Чулым елгасына коючы Кемчуг инеше буйлап йөзеп килеп, шунда урнашкан **«Кемчуг «тартанында»** («Кемчужный волок») йөзгечләрне Енисей елгасына күчереп юлны дәвам иткәннәр. «Тартан» хәзерге Красноярск шәһәре янында урнашкан була.

Обь кушылдыгы Кеть елгасы һәм Енисейга коючы Кас елгасы арасында да «тартан» булган. Хәзерге Енисейск шәһәре тирәсендәге ул тартан тарихи хезмәтләрдә **«Маковский волок»** буларак теркәлгән. Енисейск Ангара (Югары Тунгуска) елгасы тамагында урнашкан. Ангара буйлап көнчыгышка таба да су юлын дәвам итеп йөзәргә мөмкин булган.

Обь кушылдыгы Вах елгасы һәм Енисей кушылдыгы Сым елгасы башлары бер тирәдән башлана. Шул ук җирлектән Енисейга коючы Елагуй инеше дә агып чыга. Нәкъ шушы кечкенә «җир кендеге» уртасында тартан урнашкан булган. Аны шартлы рәвештә **«Вах-Сым-Елагуй «тартаны»** дип атап торыйк.

Тарихи документларда Обька коючы Надым, Пурпа һәм Таз елгалары урнашкан үзәнне «Мангазея өлкәсе» дип атаганнар. Тарихи өлкәнең үзәге Таз якасындагы Мангазея каласы (хәзерге Старотуруханск авылы тирәсендә булган) янында **«Инәй-сай «тартаны»** («Енисейский волок») яки **«Мангазея «тартаны»** урнашкан була. Таз елгасыннан көймәләрне Енисей кушылдыгы Турухан елгасына «тартан» аша күчергәннәр. Шушы Турухан елгасы белән Енисейга уң яклап койган Түбән Тунгуска елгалары тамаклары бер урында, хәзерге Туруханск шәһәре янында, Енисейга коялар. Димәк, сәүдә су юлы монда дүрт тарафка юнәлә дигән сүз.

**7) Су юлларын кыскарту максатында йөзгечләрне Идел бассейны елгаларының бер-берсенә күчерү өчен файдаланылган кайбер эчке «тартаннар»:**

– **«Чүпче – Очёр «тартаны»** – Очёр шәһәре янындагы Нократ иделенә коючы Чүпче (Чепца) елгасы белән Чулман иделенә (Камага) коючы Очёр елгаларын «бәйләүче» тартан. Соңрак «Әби патша заманында» тартан урынына болак-канал казылган диләр. Географик яктан Очёр елгасы «Барда татарлары» дигән этник группа бабалары оештырган тарихи «Гайнә» исемле «башкорт волосте»ның төньяк чиге «вазыйфасын» үтәгән.

– **«Дубна-Вора «тартаны»** – Булгы иделеннән Дубна елгасы кушылдыгы Кунья инеше буендагы «тартан» аша Клязьма елгасы кушылдыгы Вора суына коючы Торгош инешенә кораб-көймәләрне күчереп, Ока бассейны елгалары буйлап йөзеп булган.

– **«Лама «тартаны»** («волок Ламский») – Булгы иделенең уң кушылдыгы Шоша елгасы кушылдыгы Лама инеше башыннан «тартан» аша йөзгечләрне Мәскәү елгасына коючы Руза елгасына күчергәч, су буйлап Мәскәү елгасына йөзеп төшеп, алга таба Ока елгасы сәүдә юлына төшкәннәр. Бу «тартан»ны болгарлар кулыннан 1160 елда Владимир-Суздаль бөек кенәзе Андрей Боголюбский гаскәрләре тартып алган.

– **«Яуза «тартаны»** («Яузский волок») – Булгы иделеннән бүгенге Мытищи шәһәре тирәсендәге Держи инеше тамагыннан «тартан» аша Яуза елгасына күчеп, аннан соң Мәскәү елгасы буйлап йөзгәч, «тартан» аша Клязьма елгасына күчеп, аннары Ока елга бассейнына эләккәннәр.

– **«Меря «тартаны»** («Нерский» или «Мерьской» или «Клязьменский волок») – Клязьма елгасыннан Неря һәм Ушна инешләре арасындагы шушы «тартан» аша Оканың икенче бер кушылдыгы Мәскәү елгасына күчә торган була. Мәскәүлеләр **Икә** каласын (бүгенге Коломна шәһәре) яулап алгач, әйтелгән «тартан» аша узучы елга-тартан юлы урыс сәүдәгәрләре йөри торган төп сәүдә маршрутына әверелгән.

– **«Орехово-Зуево «тартаны»** («волочек Зуев») – шулай ук Клязьма елгасыннан Дроздна инеше башы белән Мәскәү елгасына коючы Мерьская кушылдыгы Понорь инеше арасындагы, шулай ук Клязьма елгасыннан, аның тамагыннан урап тормый гына да, Оканың өске агым буйларына элэгергә мөмкинлек бирә торган «тартан».

– **«Зөя – Сембер – Сызрань «тартаннары»** – бүгенге Сембер (Ульяновск) каласы янында урнашкан «тартан» аша Идел елгасыннан Зөя (Свияга) елгасы башына йөзгечләрне күчергәндә, Зөя уңае белән тамагына йөзеп төшеп, нәтиҗәдә Булгы иделенә (Волга) чыгып, яңадан югары агымга «әйләнеп кайтырга» мөмкин булган. Түбәндәрәк Иделгә койган Сызрань елгасы буйлап Зөянең агым башларына күчсәң – су юлы маршруты тагын да озынайган. Үзенә күрә «йомык» боҗраны хәтерләткән, «әйләнеп йөрергә мөмкин булган» маршрут килеп чыккан: «Булгы иделе – Идел елгасы – Сызрань елгасы – «тартан» – Зөя елгасы – Булгы иделе». Үзенә күрә суүткәргеч системасын корганда «байпас» ясау белән чагыштырырга мөмкин.

– **«Ык – Дим «тартаны»** – Кама кушылдыгы Ык һәм Агыйдел кушылдыгы Дим арасында булган «тартан» һәм «болаклар». БРндагы район һәм авыл исеме булган «Бишбүләк» атамасы – биш «болак» булуга ишарә иткән кебек. «Җир кендеге» таулары тирәсендә зур чыгымнар таләп иткән «тартан» булдырмас өчен, бер елга бассейнын икенчесе белән бәйли торган болаклар казу отышлырак булган. Шундый сәүдә корабларын йөздереп кенә күчерә торган болак-каналлар системасы Дим һәм Ык елгалары арасында булганга охшый. Җирле топонимнар арасында да моны раслый торган атамалар бар.

– **«Ашкадар – Дим башы «тартаны»** – Эстәрлетамак тоз расифеннән (иске язмаларда елга пристане шулай атала – А.А.) товар ташу өчен Агыйдел буйлап кына йөзеп төшелмәгән. Юл кыскарту һәм көнбатыш якта урнашкан якын-тирә авылларга турыга барып җитү максатында, Ашкадар елгасы буйлап аның башына йөзгечләрдә йөзеп менергә кирәк булган. Алга таба «тартан» аша Дим елгасы башына көймәләрне күчереп, кирәк икән, Дим буйлап, кирәк икән, Дим башыннан Ык елгасына күчеп теләгән урынга йөзеп барырга мөмкин булган.

– **«Аслыкүл «тартаны»** яки **«Дим – Чәрмәсән «тартаны»** – Шулай ук юл кыскарту максатында Дим елгасыннан аның Өйдрәк, Түлән, Корсак исемле кушылдыклары буйлап йөзеп барып, Чәрмәсән елга бассейнына кереп-чыгып йөзеп булган. Ханнар заманында «тартан» юлында яткан Аслыкүлне йөзгечләр күчерү процессында файдаланулары аңлашыла.

Барлык «эчке» «тартан»нарны тасвирлый китсәң, мәкалә артык озын килеп чыгар иде. Шул исәптән Сура елгасы бассейныннан «тартан»нар аша кайсы сәүдә су юлларына йөзгечләрне күчереп «маршрутларны» дәвам итеп, яисә кыскартып йөзеп булуны язып тормадык. Сүз уңаеннан, Сураның сул кушылдыгы Пьяна елгасы атамасы да югарыда әйтелгән төркиләрдәге Ана культы белән бәйле рәвештә «бианай» (кайнә; кайнана) сүзеннән үзгәргән булуы ихтимал.

**Сәүдәгәрлек тирәли сәясәт**

«Казан ханлыгы» яулап алыну белән «Мәскәү хөкүмәте» яңа колония халкы өчен дискриминацион кануннар кабул итә. Шул исәптән ислам динле казан татарларына моннан соң шәһәрләрдә яшәү, таштан төзелеш алып бару, тимер ясау, сәүдәгәрлек кәсепләре катгый тыела. Борынгы болгар бабалар чорыннан ук дөньяга «гадел сәүдәгәр халык» дип даны чыккан халыкның үзаңын (психологиясен) үзгәртеп кору процессы башлана. Моның белән Мәскәү хөкүмәте урыс купецларының гына шәхси монополиясен булдырырга омтыла. Тоз, мәгьдән (руда) белән сәүдә итүне дә дәүләт үз кулына алган. Әлбәттә, бу кануннар бөтен татар халкына берьюлы тәэсир иткән дигән сүз түгел. Халкыбызның этник группалары берничә мөстәкыйль дәүләттә яшәгән һәм аларның колониягә әверелүе төрле чорга караган. Мәскәү дәүләтенең, соңрак Рәсәй империясенең көнчыгышка таба җәелү процессы берничә гасырны эченә ала. Яулап алынган җирләрдә сәүдәгәрлек кәсебе тыелса да азат калган дәүләтләрдә сәүдә гөрләп чәчкә аткан. Өстәвенә, ныгытылмаган чикләр аша эчке базарларга, көнкүреш тауарлары белән беррәттән, кулдан-кулга күчеп булса да, көнчыгыш тауарлары да туктаусыз килеп торган. Яшерен контрабанда сәүдәсе кысуларга карамыйча, киң колач алган. Ислам динле «урталык халыклар» сәүдәгәре христиан динле «көфер халык»

белән сәүдә итешүне, гомумән, өнәп бетермәгән. Патша хөкүмәтендәгеләрнең «Бөек җифәк юлы» буендагы дәүләтләр белән сәүдә итешәсе килү, тәмләткечләр, җифәк, мамык, кәһва кебек тауарларны Рәсәй базар-ярминкәләрендә дә күрү теләге борынгы сату-алу традицияләре нык булган мөселман татар сәүдәгәрләрен арадашчы – «маклак»лар буларак файдалануга этәргән. Идел буе татарларында, берничә гасыр буе тукталып торса да, сату итүгә хирыслык каннан килгән. Урта гасырлардан ук татар сәүдәгәрләре коры җир һәм су юлларын иң яхшы белүче булып исәпләнгән. Мәкаләдә китерелгән дәлилләр аша моның серен ачыкларга тырыштык. Саналган сәяси сәбәпләр аркасында халкыбызда яңадан сәүдәгәрлек кәсебе җанланып киткән.

**Татарларда сәүдәгәрлек эшен яңадан тергезүгә бәйле кануннар**

Рәсәй империясе законнарының тулы җыентыгыннан [«Полное собрание законов: Т. IX–XX. 1830] татарларда сәүдә эшен тергезүгә булышлык иткән дәүләт кануннарын язып алдык:

11.06.1763 елда йомышлы казан татарларына төрле шәһәрләргә барып сәүдә итүне рөхсәт иткән Сенат указы чыга. Шул ук елның 7 августында Сенатның яңа указы буенча, Казан шәһәрендәге татар бистәсендә яшәгән йомышлы татарларга, бирелачәк «жалованная грамоталар» нигезендә, каршылыксыз сәүдә белән шөгыльләнүгә рөхсәт ителә.

07.07.1766 елда Сенат указы буенча, чик буе Оренбург һәм Троицк таможнялары оештырыла. Канун приказчик булып хезмәт иткән татарларның яшерен сәүдә итүләренә киртә кую максатында да әзерләнгән.

22.11.1776 елда «мишәр һәм башкорт старшиналарына һәм «башка шундый татарларга» сәүдә кәсебен рөхсәт итүче хөкүмәт Сенатының указы дөнья күрә.

08.07.1782 елда Әби патшаның (Екатерина II) барлык шәһәрләрдә дә сәүдәгәрләргә үз йортында лавка ачуны рөхсәт иткән указы игълан ителә.

04.09.1787 елда Әби патшаның генерал-поручик барон Игельстромга бирелгән указы буенча, татар мәчетләре каршында кәрван-сарайлар оештырырга боерыла.

16.12.1787 елда Әби патшаның генерал-поручик барон Игельстромга бирелгән яңа указы нигезендә, Сәгыйт бистәсе («Оренбург Каргалысы») татар сәүдәгәрләре Уфа губернасы иррегуляр гаскәрләре составына беркетелә.

05.06.1792 елда Әби патшаның Уфа губернаторы Пеутлингка бирелгән тагын бер указы нигезендә, Сәгыйт бистәсендә яшәгән «крестьян, мещан, купец» татарлар губернада оештырылган иррегуляр гаскәргә кертелә һәм аларга теләгән очракта «мещан һәм купец» булып язылырга рөхсәт бирелә.

**Академик тарихта бәян ителгән сәүдә су юллары**

Тарихи сәүдә су юллары турында сүз чыкса, академик тарихта урыс сәүдәгәрләре кулланган маршрутларга гына басым ясала, аларның мөһимлеге күпертеп күрсәтелә. «Киев Русе», «Владимир-Суздаль кенәзлеге» һәм «Московия» башкалалары аша уза торган *«из Варяг в Греки»* һәм *«из Варяг в Персы»* дигән маршрутлардан башкасы телгә дә алынмый дисәк, хата булмас. Иң әүвәл шул су юлларына тукталып китик. Мәшһүр **«Карман – Юнан юлы»** түбәндәгечә узган: *«башта Балтыйк диңгезеннән Нева елгасы аша Ладога күленә кергәннәр. Ладога күленнән Волхов елгасы аша Ильмень күленә йөзелгән. Аннан бу күлгә коючы Ловать елгасы белән барып «тартан» («волок») аша Днепр (Вар; Борисфен) башына күчкәннәр. Алга таба Днепр елгасы буйлап Кара диңгезгә йөзеп төшеп, «Сыер (Сәвер) кичүе» (урысча «Коровьи брод») дип аталган диңгез юлы белән Византия башкаласы Царьград – Константинопольга барып ирешкәннәр»*.

Икенче маршрут **«Карман – Фарсы су юлы»** түбәндәгечә узган: *«Балтыйк диңгезе – Нева елгасы – Ладога күле –Волхов елгасы аша Ильмень күленә йөзеп үткәч, күлгә коючы Пола һәм Явонь елгалары белән Селигер күленә кергәннәр. Аннан «тартан» аша Булгы Иделе елгасына коючы Селижаровка инеше буйлап Идел елгасы бассейнына эләккәннәр. Булгы Иделеннән Иделгә кереп алга таба су буйлап йөзеп, Каспий диңгезенә үткәннәр. Алга таба Каспий диңгезенең көнчыгыш яры буйлап йөзеп барганда – Абескун каласы лиман-портына, көнбатыш яры буйлап йөзгәндә – Тимер-капы (Дербенд), Бакы, Энзели лиман-портларына кадәр барып алга таба коры җир юлыннан фарсылар пайтәхете Рей (Тегеран) каласына җиткәннәр»*. Бу юл укучыга «Селигер юлы» буларак та билгеле. Тасвирланган су юлы маршрутын сәүдәгәрләр Юнанга (Греция) бару өчен дә кулланган. Татар сәүдәгәрләре, сәяси сәбәпләр аркасында, язылган су юллары «маршрутларын» өлешчә генә файдаланган. Чөнки ислам-шәрык дөньясының аерылгысыз өлешен тәшкил иткән безнең сәүдәгәрне христиан дөньясы үзәкләре аз кызыктырган.

Алда әйтелгән сәүдә «маршрутларын» тасвирлаучы тарихчыларның югалып кала торган «йомшак» ягына игътибар итәргә кирәк. Шартлатып: «Фәлән җиргә фәлән су чыганаклары аша барып җителә»,– дип санап чыгалар, әмма кире кайту юлы турында сүз чыктымы – уңайсыз хәлдә калалар. Кемдер: «Киреге – агымга каршы йөзгәннәр»,– дисә, кемдер: «Бурлаклар кире тартып мендергән»,– дип әйтә. Кайберсе: «Көймә-корабларны арбага салып кайтарганнар яисә, ташлап калдырганнар»,– дигән тузга язмаган версия тәкъдим итә. Агымга каршы меңәр чакрым араны йөзеп кара!? Зур чыгымнар сарыф итеп кораб төзет һәм ташлап калдырмы? Агымга каршы йөзү, йөзгечне тагып, тарттырып бару – бары тик

кыска маршрутларда гына кулланылу кагыйдәсен онытырга ярамый. Агым уңаена кырын ятып дигәндәй, көч сарыф итмичә генә йөзү мөмкинлеге булу – су маршрутының бәһасен тәшкил иткән дә инде!

**Татар сәүдәгәрләре кулланган төп (магистраль) сәүдә «маршруты»**

«Тартан» юлларын һәм болакларны, шартлы рәвештә, елгалар белән тоташ су маршрутлары дип исәпләгәндә гигант бер «акватория» килеп чыга. Аның татар халкы бабалары оештырган барлык дәүләт башкалалары аша узуына да игътибар итәргә кирәк! Чыганаклар су юлларын үтү юлын татар сәүдәгәре яхшы белүен хәбәр итә. Моның сере, әлбәттә, бабаларыбызның әйләнә-тирә табигатьне туктаусыз өйрәнүе, күзәтүе, сорашып-белешүе һәм бар белгәнне мирас итеп буыннан-буынга тапшыра килүендә.

Елгаларны шартлы рәвештә географик киңлек (меридиан) буенча төньяктан көньякка таба яисә, киресенчә, көньяктан төньякка таба «буйга агучы» елгаларга бүлергә мөмкин. Шулай ук географик озынлык (параллель) буенча, көнчыгыштан көнбатышка таба яисә, киресенчә, «аркылыга таба агучы» елгаларга бүлеп була. Диагональ буенча, «чапырыш якка таба» агучы елгалар да сирәк кенә очрый. Идел, Дон һәм Днепр бассейннарында аларның кушылдыклары ничек агуына карап, «тартан»нар, йә «болак»лар аша, йөзгечләрне күчерә-күчерә төньякка таба хәрәкәт итәргә мөмкин булган. Мәсәлән, көньякка таба аккан Идел елгасының төньякка таба агучы Зөя, Сура, Ык, Дим, Сөн кебек кушылдыклары бар. Ока, Клязма, Чәрмәсән кебек елгалар «аркылыга» – көнчыгыш-көнбатыш юнәлештә аккан кебек. Кыскасы, елгалар ничек урнашуын, агым юнәлешләрен, «тартан» урыннарын бик тә яхшы белгән санаулы кешеләр генә Днепр, Идел елгасы буйлап йөзеп төшкән корабны башта елгаларның агымсыз «тоба» урыннарына күчә-күчә агымга каршы барып, аннан елгадан-елгага күчерә-күчерә, Идел башларына йөздереп кире кайтара алган. Идел елгасы элек «җиде тармак булып» Каспийга койган. Аның бер тармагы, риваятьләр буенча, ясалма канал – «болак» булган, ул исә Сарай калалары порт-лиманына гына түгел, хәтта бүгенге Волгоград шәһәре тирәсендәге «тартан»га кадәр үк йөзеп барырлык итеп казылган, имеш. Урта гасырларда агымга каршы йөзү проблемасы да шулай уңай хәл ителгән булса кирәк. Вакыты җиткәч, археологлар үз сүзен әйтер дип уйлыйбыз. Ә безнең татар сәүдәгәрләре бик тә уңайлы һәм җиңел «маршрут» буенча йөзгән. Башта Идел елгасы буйлап, агым уңаена «кырын ятып кына» Каспий диңгезенә йөзеп төшкәннәр. Аннары диңгезгә Узбой, Зеравшан һәм башка элек бу диңгезгә койган Әму-Дәрья кушылдыклары буйлап йөзеп барып, «тартан»-болаклар аша, Арал диңгезенә һәм Сыр-Дәрья елгасына йөзгечләрен күчергән. «Казык уртасы» тирәсендә урнашкан Урта Азия базарларына шулай йөзеп барылган. Урта гасыр Төркия карталарында Балхаш

(Каһан, Хакан) күле тирәсендәге Баласагун каласы «дөнья уртасы» итеп күрсәтелә. Алга таба сәүдәгәрләр Җаек, Җим (Эмба), Тургай кебек елгалар һәм аларның кушылдыкларыннан «Җучи олысының» тәүге пайтәхете Орду-Базар тирәли урнашкан базарларга йөзеп менгән. Анда «тартан»нар һәм алда искә алынган «Җиде болак каналлары системасы» буенча, йөзгечләр Тартар иделе (Обь) кушылдыклары Тубыл, Ишим елгалары башларына күчерелгән. «Бөек Төрки каһанлыгы» башкаласы Баласагуннан Зәйсән күле аша тарихи «Җидесу өлкәсе» сулары һәм Бухтарма, Кара Иртыш, Катунь («хатын елгасы») елгалары аша күчә-күчә Обь елгасы башына эләгеп, урабырак бара торган маршрут белән дә йөзеп булган. Каспий һәм Арал диңгезләре уртак су чыганагын тәшкил иткән чорда тасвирланган катлаулы күчеш ясауның кирәге дә булмаган диләр. Азактан инде, сәүдә кораблары агым уңаена Обь елгалары буйлап, «Себер ханлыгы» үзәк калалары – Искәргә, Чинги-турага йөзеп төшкән. Аннары йөзгечләр Тубыл елгасы кушылдыклары: Тавда, Тура, Исәт һәм Уй елгаларына коючы Урта Урал тауларының көнчыгыш итәкләреннән агып чыккан кушылдыклар буенча йөзеп менгән. Сәүдә кораблары алга таба кайда «тартан», кайда «болаклар» аша Идел бассейнына керүче Кама, Караидел һәм Агыйдел елгаларына коючы Урта Уралның көнбатыш итәкләреннән агып чыккан елга башларына күчерелгән. Соңыннан Идел бассейны елгаларының агымы буйлап татар дәүләтләренең үзәк калаларына кире әйләнеп кайтылган. Су юлын кыскарту максатында кайбер сәүдәгәрләр «тартан»нар аша башка елгаларга күчә-күчә йөзгән. Татар сәүдәгәре шулай тулы бер «әйләнеш» ясап, сәүдә итә-итә кире үз йортына кайтып җиткән. Көнбатыш Себер ягында «әйләнеш» ясап, Урта Азия базарларына барып-кайту эше җиңелрәк ысул белән башкарылган. Көньякка агучы Җаек елгасы буйлап йөзеп төшкәч, Обь кушылдыгы Тубыл һәм Ишим елгалары буйлап, кире төньякка тагын агым буйлап әйләнеп кайтылган. Шулай, кыска юл белән тулы «әйләнеш» ясап, йөзеп-кайту мөмкинлеге булу – «тулы канлы» яңа мөстәкыйль дәүләтләр (Кимәк каһанлыгы, Нугай Урдасы һ.б.) туугa җирлек тә булган, ахры. Димәк, түбәндәге су юлы маршруты – урта гасыр татар дәүләтләренең әйләнеп йөзеп йөри торган төп сәүдә магистрале булган: **Идел елгасы – Каспий диңгезе – Әму-Дарья елгасы – X** (бу билге белән алга таба «тартан»нарны билгелибез – А.А.) – **Сыр-Дарья елгасы (алтернатив юл – Арал диңгезе һәм Җим елгасы аша) – Тургай елгасы – X – Ишим елгасы (альтернатив юл – Иртыш һәм Обь елгалары аша) – Тубыл елгасы – X – Кама елгасы (альтернатив юл – Караидел һәм Агыйдел елгалары аша) – Идел елгасы.**

Төп сәүдә маршрутының көнбатыш «тармагы» турында да язып үтәргә кирәк. Югарыда язылган Идел-Дон якынлашкан урындагы «тартан»нар аша Дон елгасы буйлап йөзеп төшеп, Азов (Азоу; Әҗәк) диңгезе

«акваториясенә» кергәннәр. Азов диңгезеннән Кара диңгезгә йөзеп кереп, төньяк яр буе татар җирләре – «Кырым», «Үр-җир»гә («Ор»), «Буджак» җире базарларында булганнар. Аннан тагын да арырак, Дунай елгасы буйлап йөзеп, елга һәм алда тасвир ителгән «Шаһморан валы» арасына «кыстырылган» төрки халыклар яшәгән төбәкләргә – тарихи «Мутьян җиренә» һәм борынгы Скиф-Дакия чиге булган – «Алута»га кадәр барып җиткәннәр. Димәк, урта гасырларда татар дәүләтләренең көнбатыш якка йөзеп йөри торган төп су юлы маршруты түбәндәгечә булган: 1) ерак су юл: **Идел елгасы – Х – Дон елгасы – Азов диңгезе – Кара диңгез – Дунай елгасы – Ольт елгасы – Дунай елгасы – Кара диңгез – Кавказ елгалары – Каспий диңгезе – Әму-Дарья елгасы – Х – Сыр-Дарья елгасы (алтернатив юл – Арал диңгезе һәм Җим елгасы аша) – Тургай елгасы – Х – Ишим елгасы (альтернатив юл Иртыш һәм Обь елгалары аша) – Тубыл елгасы – Х – Кама елгасы (альтернатив юл – Караидел һәм Агыйдел елгалары аша) – Идел елгасы;** 2) кыска маршрутлар: а) **Идел елгасы – Х – Дон елгасы – Азов диңгезе – Кара диңгез – Дунай елгасы – Ольт елгасы – Дунай елгасы – Кара диңгез – Днепр елгасы – Х – Ока елгасы – Идел елгасы;** б) **Идел елгасы – Х – Дон елгасы – Азов диңгезе – Кара диңгез – Дунай елгасы – Ольт елгасы – Дунай елгасы – Кара диңгез – Азов диңгезе – Дон елгасы – Х – Ока елгасы – Идел елгасы.**

Бәян ителгән төп сәүдә су «маршруты» бүгенге татар халкы этник группалары яшәгән төбәкләрне, татар теленең таралыш ареалын тулысы белән колачлый. Коры җир юлларын тасвирлаганда моның шулай булуы тагын да тулырак исбатланыр. Шушы киң төбәктә «тел-лөгат алмашып», аралашып яшәгән тугандаш кабиләләрдән уртак бер тел һәм уртак бер этнос формалашуы табигый булган. Татар халкын вакларга, аның этник группаларын бер-берсеннән читләштерергә тырышкан көчләргә җавап йөзеннән, уртак сәүдә һәм ара юллары системасы булуы – кире какмаслык төпле дәлил булып тора. Моны тарихчыларыбыз һәрчак истә тотып, ассызыклап күрсәтә белергә тиеш!

### Кулланылган әдәбият

1. Александра Исаева «От Волги к Дону», «Волгоградская правда», 10.08.2012. https://vpravda.ru/kultura/mesto-dlya-vvoda-teksta-3473/.
2. «Полное собрание законов Российской империи с 1649 года», Т. IX–XX. СПб., 1830. Уфа. 2022–2023.

*Р.Р. Аскаров*

# ТРИУМФ И ТРАГЕДИЯ КИГИНЦЕВ В 1930-е ГОДЫ

Верхне-Кигинский район Башкирской АССР образовался 20 августа 1930 г. (с 1935 г. – Кигинский район). Прошло чуть больше года и по району прошла первая «чистка». Она, словно каток, больно затронула сельчан, местные партийно-советские и комсомольские организации, правоохранительные органы, руководство района.

19 ноября 1931 г. состоялось заседание бюро Кигинского РК ВКП(б), в котором рассмотрели «засоренность и неспособность ряда партячеек, как деревень Кульметово, Тугузлы и другие в вопросе хлебозаготовки». РК ВКП(б) решил: исправить допущенные ошибки, выполнить все директивы обкома ВКП(б), решительно привлекать срывающих хлебозаготовку к партийной и судебной ответственности. Почему такая строгость? Чем она была вызвана? В 1931 г. в стране началась политика принудительных хлебозаготовок, когда отменили даже решение выдавать колхозникам по 1–1,5 кг зерна на трудодень. Далее наступил искусственный голодомор 1932–1933 гг. Именно тогда решили ликвидировать кулаков – зажиточных крестьян, отказавшихся идти в колхозы.

Прибыв к месту назначения, активисты – посланники райкома партии, проводили совещание с местными коммунистами, организовывали сход крестьян – бедняков с целью разоблачения подрывной деятельности кулачества против советской власти. На сходах принималось решение: «покончить с врагами советской власти».

На основании собраний, с помощью местных коммунистов, комсомольцев, активистов, так называемые «враги советской власти – кулаки, подкулачники, муллы», среди которых большинство составляли честные труженики, были доставлены в райцентр. Им было разрешено взять с собой теплые вещи, одеяло, подушку, посуду для приема пищи, продукты на несколько дней. Вначале их собрали во дворе школы. Затем в овраге за селом сделали карду и арестованных перевели туда. Кругом был выставлен вооруженный караул. Среди арестованных оказались не только мужчины, но и дети, женщины, даже с грудными детьми, люди разных возрастов. После всех формальностей, арестованных отправили на телегах на станцию Сулея, где их ждал товарный состав. Посадив по 20–30 человек в каждый вагон, двери закрыли и состав тронулся. Так раскулаченные, «враги советской власти», ни в чем неповинные сельчане, оказались в далекой Иркутской области, в основном, в пос. Черемхово.

Настоящие бесстрашные коммунисты открыто высказали свое видение происходивших фактов. Тогда бюро РК ВКП(б) «за правооппортунистическую линию в хлебозаготовках. За дискуссии о реальности плана» снял с работы секретаря РК ВКП(б) Туганова, председателя райисполкома Кульмухаметова (в 1927–1928 гг. учился в Казани, получил юридическое образование) и директора МТС Гумерова. Во всю мощь заработал маховик репрессивной машины. Только в 1931 г. исключили из рядов партии 21 человек, партвзыскания получили 36, сняли с работы – 9 человек. Были распущены две партийные организации и два сельских совета (Нижне Троицкий и Леузинский).

Настоящий погром понес Кигинский комсомол. Сняли секретаря РК ВЛКСМ Хабиба Ганиева (он пошел в армию, прошел путь от рядового до генерал-майора, а генеральское звание получил в военном 1944 г.). Из двух уволенных комсомольских работников один был старший брат моего дедушки Ахун Галиаскарович. Его «вина» была в том, что он женился на дочери муллы из д. Вакиярово. Ахуна разъединили с семьей; Жамиля Галиаскарова (Галяутдинова) с малолетней дочерью Флюрой оказалась среди репрессированных в пос. Черемхово. В 1939 г., после долгих переживаний, Ахун добровольно поехал к своей семье. Только в середине 1990-х гг. их сын Рифат Ахунович с супругой Зенфирой Бариевной (родом из Татарской АССР) установили контакт с родственниками в Башкортостане и побывали на родине своих предков.

В начале 1930-х гг. исключили из рядов районной комсомольской организации 70 ее членов, взыскание наложили 14 комсомольцам. А две первичные организации и два бюро первичных организаций были распущены [Красная Башкирия: 1931. 14 октября].

В 1929–1935 гг. в районе все мечети, медресе и церкви были отобраны решением местных властей и переданы под школы, клубы, избы-читальни. Среди репрессированных оказались также духовные лица. В этой связи хочется привести два примера человеческих судеб.

Гафур мулла Баймухаметов из с. Еланлино оказался в тюрьме, его жена Банат и старшие дочери – в пос. Черемхово. Младшую Марьям, которой было неполных 3 годика, распределили в детдом Челябинской области. В 2012 г. ко мне обратился праправнук Гафур муллы Богдан Баймухаметов из поселка Черемхово с просьбой помочь в поиске родственников в Кигинском районе. Он, в свою очередь, помог мне установить контакт с Зенфирой Бариевной и ее дочерью Дилярой Рифатовной.

Тучи репрессии сгустились над верхнекигинским муллой Камалом. Его брат Гата Мухаметьянов, был известным человеком в районе. Как большевик-революционер, активный борец за советскую власть, он по-

советовал Камалу уехать за пределы района. Мулла так и сделал. Со своей семьей тайно убыли в неизвестном направлении. Его дом и надворные постройки решением правления колхоза передали колхознику Махмуту Галиаскарову.

Мои дедушка и бабушка поставили новый дом и перешли жить туда весной 1935 г. Помнится, бабушка Фатиха не раз с гордостью говорила, что наше хозяйство особенное, святое, так как на этом месте проживал мулла («мулла йорты»). Она вспоминала, что после войны как-то пришел старец, прочитал аят. Бабушка дала ему подаяние, угостила чаем. Старик на прощание поблагодарил хозяйку, выразил радость за аккуратное состояние дома и хозяйства. Также поведал о том, что давно на этом месте проживал он со своей семьей. Это был Камал мулла.

Параллельно с партийными судами безостановочно работала гильотина правоохранительных органов – НКВД и прокуратура. В течение сентября-декабря 1931 г. были осуждены по ст. 61 УК – 94 кулака и 24 зажиточных человека, по ст. 107–17 человек, в том числе 14 бедняков-колхозников, за убой скота 1 кулак, 3 колхозника, 23 работника правления, 14 работников сельсоветов и 1 работник райисполкома [НА РБ. Ф. 933. Оп. 1. Д. 878. Л. 206; Ф. 1100. Оп. 2. Д. 5. Л. 28; Д. 18. Л. 11; Д. 23. Л. 39].

Днем и ночью истребляли «врагов народа», а они возникали вновь и вновь. Так, в отчете отмечается, что «в октябре-ноябре 1931 г. выявлены еще 139 кулацких хозяйств». Сталинская репрессивная машина была наподобие вампира, требовавшая периодически человеческую кровь [Красная Башкирия: 1931. 5 ноября].

Вскоре наступил перелом. Хлебозаготовка 1932–1933 гг. показала победу и преимущество колхозного строя. В Верхне-Кигинском районе колхозы сдали государству 135374 ц. зерна (91,7% к плану), единоличники – 5,448 ц. (60% к плану), кулаки – 3006 ц. (55% к плану). В 1933 г. район с честью выполняя план продажи хлеба государству, поднялся с колен и твердо встал на ноги. На трудодни колхозники получили по 5,2 кг пшеницы против 2,6 кг в 1932 г. На столе появился хлеб и люди перестали испытывать голод. Надо признать и тот факт, что эта победа далась ценой перегибов и человеческих страданий. Но что поделаешь, это наша с вами история и от нее никуда не уйти.

Беда одна не приходит. Отсутствие должного уровня демократизации общества сделало возможным и формирование культа личности, и нарушение законности, произвола репрессии в 1930-е гг. Массовым репрессиям подвергались многие тысячи членов партии и беспартийных.

По данным, полученным из архива бывшего КГБ РБ в 1993 г., число репрессированных в Кигинском районе составляет 425 человек (кроме

раскулаченных). Эти печальные события коснулись представителей всех национальностей, проживавших на территории района. Среди репрессированных были: 140 башкир, 138 татар, 136 русских, по 3 эстонца и немца, 2 белоруса, украинец, латыш и чуваш. Из 425 «врагов народа» колхозники составляли 235 человек, крестьяне-единоличники – 135, учителя – 7, муллы – 10, председатели колхозов – 2, заведующий Райпо, работники райкоопсоюза, РВК и так далее. К высшей мере наказания были приговорены 39 человек, высылке без указания срока с конфискацией имущества – 9 и высылке на срок от 3 до 10 лет – 342. Только 35 осуждённых были реабилитированы отсидев в тюрьме несколько месяцев. Среди пострадавших были также женщины. Например, Хабира Юсупова их Верхних Кигов, 1915 г.р., домохозяйка, и Мария Федорова, учительница Вязовской начальной школы. По некоторым сведениям, муж Хабиры Юсуповой работал в Министерстве торговли БАССР, попал под сталинский «каток» и за собой «потянул» молодую жену. Хабира вернулась в район, а её мужа расстреляли.

В результате ложных доносов в атмосфере недоверия и боязни погибли простые труженики разных возрастов: Андрей Русин (пос. Ивановка) расстрелян в 1938 г. в возрасте 71 года, Денислам Набиуллин (с. Верхние Киги) расстрелян в возрасте 53 лет, Мухаметьяр Набиев (с. Еланлино) расстрелян в возрасте 58 лет. Парферий Юшков расстрелян в 1942 г. в возрасте 39 лет. Самыми молодыми из осужденных на высылку были Егор Тряшин (с. Леуза), Биктимир Садыков (с. Еланлино), Шагиахмет Мирсаяпов (д. Петрушкино). Им было только по 18 лет.

Жертвами сталинских репрессий стали активные колхозники, умные и талантливые деятели, порой люди далекие от политики.

Вот удостоверение, данное Минияну Насырову о том, что он содержался под стражей в Уфимской тюрьме с 23 ноября 1937 г. по 2 марта 1938 г. Освободился же он не просто так, а благодаря своей непреклонности и несгибаемости перед несправедливостью и беззаконием. Собрав 15 папиросных бумаг, прошив их ниткой в виде блокнотика, М. Насыров обратился лично И.В. Сталину с заявлением проверить правильность действий со стороны Кигинского РК ВКП(б) в отношении него и восстановить его в рядах партии. За что пострадал редактор Кигинской районной газеты «Социализмга» (?). Выступая в с. Еланлино на собрании партактива, он вместо слов «Весенний сев колхоз имени Сталина начал не организованно, тянул район назад. Занимался вредительством…», пропустил первые слова. Предложение приобрело другой смысл, будто сам Сталин занимался вредительством. Дальше – больше. За призыв молодежи стать селькорами и превратить районную газету в «районную правду», Насырова обвинили в

игнорировании роли газеты ЦК ВКП(б) «Правда». М.И. Насыров участвовал в советско-финской и Великой Отечественной войнах, он был оперуполномоченным «Смерш»а, дошел до Берлина. В послевоенные годы работал учителем, заведующим Кигинского РОНО.


Минша Сагадиев

Минша Сагадиев, выпускник Казанского университета, учитель татарского языка и литературы Верхнекигинской средней школы, был расстрелян в 1937 г. в возрасте 45 лет. Его обвинили в «татарском национализме» по ложному доносу директора школы. По воспоминаниям его ученицы, впоследствии известной и всеми любимой певицы Фариды Кудашевой, Минша Сагадиев знал все произведения Габдуллы Тукая наизусть и ходатайствовал об открытии татарской школы в каждом населенном пункте. 6 ноября 1936 г. был арестован как «татарский националист», «враг народа» и 3 августа 1937 г. был расстрелян известный ученый-тюрколог Нигмат Хаким (родом из с. Еланлино Кигинского района). Он свободно владел более чем двумя десятками восточных языков, опубликовал около 50 работ. Ученый оставил «вариант Н. Хакима» эпоса «Идегей» (из выступления И. Надирова, завотдела народного творчества ИЯЛИ КФАН на заседании Ученого совета от 13 декабря 1988 г.) [Возвратим имя твое истории: 2002].


Барый Аминев

Думается, расстрел Нигмата Хакима ускорил арест крупного военного начальника, его родственника, Барыя Аминева. Биография Аминева известна по архивным документам до начала 1930-х гг. Затем данные отсутствуют. Известно, что Аминев и Тухачевский дружили семьями, жили в одном подъезде печально известного «дома расстрелянных» на Берсеневской набережной Москвы-реки. Барый Аминев – наш славный земляк – участвовал в Гражданской войне, с 1918 г. навсегда связал свою жизнь с армией. Закончил военную академию в Москве. Занимал высокие посты. Он был арестован и исчез в 1937 г. по «делу маршала Тухачевского».


Мухаметнур Ульданов

Мухаметнур Ульданов, родом из Верхних Кигов, с 1923 г. работал в органах юстиции Башкирской АССР, был членом коллегии адвокатов и юрисконсультом. В те годы в Уфе образовался тесный круг интеллигенции, куда входили выпускники Московского университета юристы Сергей Петрович Гончаров и Николай Петрович Моисенко, красавец и умница Ульданов, судья Кутлуяров, врачи Соболев и Татаринов. Следует добавить, что Сергей Петрович был внуком Дмитрия Николаевича Гончарова – брата Наталии Гончаровой, жены А.С. Пушкина. К Сергею Петровичу в Уфу наведывался Бонч-Бруевич, соратник В.И. Ленина. Вместе с другим замечательным человеком – В.П. Кипарисовым, они занимались поисками дома С.Т. Аксакова. К сожалению, М.У. Ульданов 15 ноября 1937 г. был арестован. НКВД сообщил о его кончине 2 января 1943 г. Справедливость восторжествовала 13 декабря 1957 г. и Мухаметнур Ульданов был реабилитирован, все обвинения с него были сняты. Кстати, одна его племянница, Райса Ахмадиева, была солисткой Башкирского государственного театра оперы и балета. Племянник – Юлий Султанов, долгие годы работал в МИДЕ СССР, РФ, будучи специалистом по странам Ближнего Востока, генконсулом в Алеппо (Сирия), сопровождал Н.С. Хрущева, Л.И. Брежнева, Б.Н. Ельцина на переговорах с лидерами Палестины, Египта, Ливии, Саудовской Аравии и других стран.

В 1925–1926 гг. председателем Верхне-Кигинского волисполкома работал Нурулла Зинуров. Получив здесь заслуженную, хорошую характеристику, он поехал в Москву на учебу в Коммунистический университет трудящихся Востока (КУТВ). По окончании университета, по распоряжению ЦК он был направлен на Донбасс, в шахты Горловки, Макеевки, Петровки. В 1933 г. он вернулся в родные края, затем его направили в Аскинский район для организации МТС. 4 ноября 1937 г. его исключили из рядов ВКП(б) как сына кулака, «врага народа». Он уехал в Москву в надежде восстановить справедливость и не вернулся. Декабрьским днем 1937 г. его беременную жену Фахиту и пятерых детей – старшей дочери было 14 лет, младшему Граниту – 3 годика, выгнали из дома на улицу. После долгих мытарств они поселились у очень старых людей, которые ничего уже не боялись. В 1938 г. Фахита с детьми вернулась в родное

с. Лаклы, но от «врагов народа» все отвернулись, даже родственники. Отец Нуруллы также не пустил невестку с внуками и внучками в дом. Разрешил им жить в коровнике, где они жили целый год. Только после XX съезда КПСС получили документ о том, что Нурулла Зинурович Зинуров умер в местах лишения свободы 31 августа 1943 г. в Томской области [Зинуров: 1991. С. 159–176], а также о его реабилитации.

Пострадал талантливый журналист Гали Каримов, родной брат известного поэта Ханифа Карима.

Таких примеров можно привести много. Что мы можем сделать для них? Только одно – стряхнуть пепел забвения с их имен, вернуть их народу. Это и станет нашим истинным покаянием.

## Литература

1. Возвратим имя твое истории… Сб. док, материалов и воспоминаний о Нигмате Хакиме. Составители: Р.Р. Аскаров, А.З. Сакаев, И.Ш. Мухаметов. Уфа, 2002.
2. Г. Зинуров. Судьба отца // Возвращенные имена. Уфа, 1991.
3. Красная Башкирия. 1931, 14 октября
4. Красная Башкирия. 1931, 5 ноября.
5. НА РБ. Ф. 933. Оп. 1. Д. 878; Д. 5; Ф. 1100. Оп. 2. Д. 18; Д. 23.

*Р.И. Ишмухамедова*

# ТАТАРСКИЕ СЕЛА САРАТОВСКОЙ ГУБЕРНИИ В УСЛОВИЯХ ГОЛОДА 1921 ГОДА

*Засуха 1921 г. поразила главные зерновые регионы страны: Поволжье, Северный Кавказ, юг Украины. В условиях вызванных Первой мировой и Гражданской войнами экономической разрухи засуха быстро переросла в небывалые по масштабам голод, болезни и смертность населения. Голод охватил более 31 млн человек и стал острой общегосударственной проблемой.*

*В Саратовской губернии из 2,9 млн человек уже к осени 1921 г. голодало 40% населения, при этом голод сильнее всего ударил по сельскому населению, которое составляло 2/3 всего населения губернии. В полной мере испытало на себе пагубные последствия засухи татарское население. По данным Всероссийской переписи 1920 г. в губернии проживало 11 тыс. татар, до 90% их – в 70 селах.*

*По документам, отложившимся в ГАСО, конкретно в фонде Управления уполномоченного Полномочного представителя правительства РСФСР и УССР при всех заграничных организациях помощи России по Нижнему Поволжью, мы можем восстановить картину, сложившуюся в татарских деревнях Саратовской губернии. Татарское население разделило мрачную участь многих русских, мордовских и чувашских деревень Саратовской губернии. В данном сообщении акцент будет сделан на татарские села Хвалынского, Петровского и Новоузенского уездов Саратовской губернии.*

Голод в губернии начал чувствоваться с весны 1921 г. Уже в это время крестьяне некоторых уездов питались суррогатами: желудями, травой, лебедой и т.д. – сухим, жарким летом 50% полей было выжжено в Хвалынском и заволжских уездах. Катастрофическая засуха 1921 г. определила почти полный неурожай в Петровском уезде Саратовской губернии. «Урожай хлебов в Петровском уезде был незначительным, дав в среднем по 8–9 пуд. на десятину, а в некоторых (Бегучевской, Порзовской, Лопатинской) собрали лишь 2–5 пуд. с десятины» [Известия: 1921. №263, 9 нояб., С. 2.]. Жалкого урожая хватило не надолго, население стихийной волной двинулось с насиженных мест, продавая домашнюю утварь сельскохозяйственный инвентарь за бесценок. Стихийное выселение уменьшило население многих уездов. Из Хвалынского уезда выселилось около 50 тыс. человек, из Дергачевского – около 40 тыс. человек [Черная година: 1922. №1. С. 28]. В Селе Суляевка Пылковской волости за один

год (с 1921 по 1922) количество населения уменьшилось на 813 человек, дворов – на 113 [О голоде: 1923. С. 175].

Резко уменьшилось число крупного и мелкого скота в Бегучевской волости Петровского уезда: в 1915 г. лошадей было 1959 голов, коров – 1138, овец – 4903, а в 1922 г. осталось – 840 голов, коров – 539, овец – 1277.

О тяжелом положении населения Хвалынского уезда сообщается в статье «В царстве голода», которая вышла на первой странице газеты «Известия Саратовского Совета Р. и Кр. Деп. Губисполкома и Губкома» от 1 ноября 1921 г. По словам автора статьи, «Особенно тяжело трагичное положение в татарском селе Зарыклей. Обходя крестьянские дома натыкаешься на кошмарные картины. Дети часто брошены родителями, убежавшими неизвестно куда. Несчастные малыши сами добывают и готовят себе пищу из суррогатов» [Известия: 1921. 1 нояб., С. 1] Эта ужасающая картина дополняется цифрами, данными в статье, напечатанной в газете 5 ноября 1921 г. в этом же издании: «В деревне Зарыклей Старо-Лебежайской волости умерло от голодной смерти 100 детей, 60 человек взрослых. 100 человек переселились в урожайные губернии, в деревне осталось 858 человек, голодающих в буквальном смысле этого слова» [Там же. № 51, 5 нояб., 1921. С. 1].

В 3-х км от Старой Киремети в Акташском лесу на поляне бьётся сердце любимого родника классика татарской поэзии Хасана Туфана. С давних времен этот родник называется «Акташ», что в переводе на русский язык означает «Белый камень». Если бы родник умел говорить, то поведал бы нам, как Хисбулла (так звали поэта в детстве) приходил сюда, чтобы наслаждаться журчанием воды и тишиной. Хасан абый уехал из Киремети в 14-летнем возрасте, и только через 56 лет, в 1970 г., он вновь побывал в Акташском лесу и попил родниковой воды с ладошки, не пролив ни капли…

К роднику можно добраться пешком или на машине, если погода не дождливая. За родником ухаживают братья Гаряфетдин Гайсович и Галимзян Гайсович Сабировы, они каждый год его чистят. Уровень воды постоянный. Вода чистая, холодная, можно пить. Родник Акташ окружен пышной растительностью. Вокруг растут березы, дубы, ивы.

Родник течет в пруд (*Мунчала буасына*), где раньше вымачивали липовое лыко, чтобы получить мочалку. Лыко – это не только мочалка. Старокиреметцы считались умельцами из лыка делать лапти, корзины и т.д. Выражение «лыка не вяжет» означает, что человек либо пьян, либо неполноценен, он даже не может плести, например, лапти. Вижу, я чуть

отошёл от темы… Затем ручей течет по краю леса, и соединяется с ручейком Салкын чишмә. Так рождается река Акташ (*Әрәмә елгасы*), которая впадает в реку Киреметь.

### «Гайса абый чишмәсе»

В двухстах метрах от Акташского леса, в сторону деревни, находится родник «Гайса абый чишмәсе». Гайса абый Сабиров при жизни ухаживал за этим родником, теперь эту обязанность возложили на себя его сыновья. Вода в роднике прозрачная, чистая. Родник впадает в реку Акташ (*Әрәмә елгасы*).

### Родник в лесу, возле пчельника

Раньше в Акташском лесу было 40 га земли, которую использовали под пашню. Сейчас там растут березы, а две из них – это знаменитые березы.



В 1970 г. Акташский лес посетил поэт Хасан Туфан, и, по словам очевидцев, он очень долго стоял, прислонившись к этим березам. Рядом находится «Аю аланы», на этой поляне свои пасеки имели: Сали бабай – мой прадед, он имел прозвище «Аю», Мухутдин бабай – дед Гали абый Мухутдинова, Нурулла бабай Ишмухамметов – сын Ишмухаммета Сабитова, самого богатого человека в дореволюционной Старой Киремети и другие. Родник имеет деревяный сруб, вода чистая, холодная, прозрачная. Все пасечники воду для себя и пчел брали именно из этого родника. В жаркую погоду к этому роднику прилетают много пчел. Они здесь утоляют жажду, а также набирают воду, как нектар и несут в улей. Вода нужна пчелам для приготовления кашицы (смесь из меда, нектара и пчелиного молочка) личинкам...

### «Фарбиза апа чишмәсе»

Надежда Минапова: «За огородом Низамутдиновой Сании апа течет родник. Раньше за родником следила Низаева Фарбиза апа (*урыны оҗмахта булсын!*). Вроде и сам родник называется «Фарбиза апа чишмәсе» (20.10.2020).

Надежда Минапова права, действительно, там когда-то был родник. К сожалению, его нынешняя судьба известна немногим жителям деревни. 24.10.2020 г. я позвонил в Заинск Лейле апа Ахмеровой – дочери первого имам-хатыба Старой Киремети Хасанжана Ахмерова. Я знал, что Лейла апа

является родственником Низаевой Фарбизы апа, поэтому я попросил ее разузнать о судьбе этого родника. На следующий же день Лейла апа обрадовала меня информацией об этом роднике. Фарбизы апа уже давно нет в живых, но ее дочь Фануза Валиуллина поделилась воспоминаниями об этом роднике. Лейла апа всю добытую информацию продиктовала мне по телефону:

– Этот родник действительно существовал, но, чтобы добраться до него, надо было еще пройти определенное расстояние после огородов. В 2000 г. Фарбиза апа понесла к роднику пустой пчелиный улей и вместе с сыном Замиром опустила его в родник. В течение многих лет родник, «одетый» в необычное одеяние, обеспечивал людей вкусной чайной водой. Пока не случилось непредвиденное. В 2012 г. вечером в овраг, где журчал этот родник, упал комбайн, который убирал урожай с полей. Родник был разрушен. Люди остались без родниковой воды. Позднее (со слов Фанузы) Ильфат Миниханов и Радик Минабутдинов опустили в родник бетонное кольцо. *Алланың рәхмәте яусын!*

***– Лейла апа, а вы видели этот родник?***

– Как же, еще 2012 г. я побывала у этого родника, и попила изумительно вкусной воды. *Ходаем, бу чишмәнең суы беркайчан да сарыкмасын иде!*

***– Как назывался этот родник? Что говорит по этому поводу дочь Фарбизы апа?***

– Ее дочь говорит, что все, кто брал воду из этого родника, всегда говорили, что это «*Фарбиза апа чишмәсе*», как же иначе, она же ухаживала, чистила. «*Бөтен кеше әнигә рәхмәт әйтеп дога кыла иде*»,– *ди Фәнүзә*.

– Лейла апа, родников в Старой Киремети очень много, по новым подсчетам более 15 родников подпитывают реки Акташ и Киреметь...

## «Зәмзәмия апа чишмәсе»

***Рассказала Роза Сибгатуллина:*** «Где был наш дом, через наш огород текла маленькая речка, и там был родник, мы его называли «*Картәни чишмәсе*», а жители села «*Зәмзәмия апа чишмәсе*». Картэни – папина мать, она всегда чистила этот родник, я помню, мы ведрами таскали оттуда воду и поливали грядки. Узнать бы, этот родник там есть или уже нет?» (20.10.2020).

***Рассказала Ирина Ишаева:*** «Я сходила к роднику, о котором писала Роза Сибгатуллина, этот родник, по словам жителей, называли «Зәмзәмия апа чишмәсе» (Замзамия апа – бабушка Розы)» (21.11.2020).

## «Әбиләр-бабайлар чишмәсе»

*(продолжение телефонного разговора с Лейля апа Ахмеровой)*

– Равиль, Фануза вспомнила еще об одном роднике. Недалеко за домом Киямова Агзама абый был родник, который назывался «Әбиләр-ба-

байлар чишмәсе». Пожалуй, это был самый старый родник в нашей деревне, по крайней мере, так считали раньше. Этот родник был «одет» в липовую кору. Фануза с детства носила отсюда воду, чтобы заварить вкусный чай. Также она приносила воду своей первой учительнице Киямовой Хадиче апа...

– Даже название этого родника указывает на его древность. Лейла апа, наша деревня – это царство родников!

– *Аллага шөкер!* Только этому царству требуется постоянное внимание, иначе оно может исчезнуть.

**Родники чувашской стороны Старой Киремети.**

26.07.2020. На странице группы «Старокиреметский СДК в «ВКонтакте» одна из энергичных и деятельных активистов Старой Киреметы – Ирина Михайловна Ишаева выложила видео «Живи, родник, живи!»,



где уроженка нашей деревни Юлия Федотовна Бочкарева (проживает в пгт. Аксубаево) рассказывает о родниках, расположенных на чувашской стороне С. Киремети. Вот ее рассказ: «Эти родники очень дороги для меня. С детства я к ним ходила, конечно, сначала с мамой. У родника, где я стою раньше был деревянный сруб, рядом есть другой родник, там тоже был такой же сруб. К этим родникам мы ходили за родниковой водой, а для скотины воду брали из колодца. У нас есть и другие родники, но они чуть подальше отсюда. Здесь рядом жила бабушка Пелагея и это ***«Родник бабушки Пелагеи»***, а другой, что рядом – это ***«Родник тёти Лизы» (Кузьминой)***. Моя мама по вкусу воды определяла с какого родника я брала воду. Она говорила: «Ты, Юля, ходила не на тот родник, надо было ходить к роднику бабушки Пелагеи. Там вода самая вкусная». Слава Богу! Теперь эти два родника соединены между собой (в один родник) трубой, которая выходит у речки. Я сейчас, спущусь, и напьюсь этой воды. Вспомню свое детство, своих родителей, свою маму, которая впервые привела меня к этому роднику. Вода тут такая вкусная, такая хорошая, она силы прибавляет. Вы, только послушайте, как она журчит, как будто со мной здоровается и разговаривает. Я хочу к этой воде прикасаться и пить ее ладошками, чтобы чувствовать ее силу и вкус. Смотрите какая вода чистая, студеная, она как живая, когда я ее пью, у меня душа отдыхает. Я знаю деревни, где вообще нет родников, нам же

сильно повезло. Я горжусь нашими родниками! Дай Бог, чтобы родники были всегда, а вода в них никогда не иссякала!».

Я уверен, посмотрев видео «Живи, родник, живи!», вы, также, как и я, будете впечатлены удивительно эмоциональным рассказом Юлии Федотовны о родниках, к которым она с детства приходит за водой.

Она с коромыслом на плечах, на фоне красивого пейзажа, под журчание ручья и пения птиц, воспевает родники чувашской стороны нашего села.

Привожу некоторые комментарии к этому видео:

***Римма Зиганшина:***

– Спасибо, Юлия Федотовна! Мы тоже ходили именно сюда за родниковой водой! Вкус этой воды нам не забыть. Помним и благодарим!

***Равиль Салиев:***

– Юлия Федотовна, мне тоже захотелось, хотя бы чуть-чуть плеснуть родниковой водой, чтобы освежиться.

***Ирина Ишаева:***

– Друзья, вас еще ждёт много интересной информации, хочется донести до вас многое, но на это приходится тратить уйму времени и сил, все сразу не получается. Благодарю всех, кто с нами на одной волне.

***Татьяна Цветкова:***

– Благодаря таким людям, как Ю.Ф. Бочкарева, Р.Г. Зиганшина и другим землякам, живущим, как в Старой Киремети, так и на чужбине, продолжает жить родная земля! Хочется также поблагодарить И.М. Ишаеву, и сказать ей огромное спасибо за плодотворную работу по сбору и обработке информации о значимых событиях в жизни нашего села. Пусть ваш труд и хлопоты заметят, и оценят по достоинству!

## «Тихон родник»

***Рассказала Ирина Михайловна Ишаева (художественный руководитель Старокиреметского СДК):*** «Позади огорода участника Великой Отечественной войны Тихона Васильевича Михайлова был родник. В народе его называли: «Тихон родник». Люди брали воду из этого родника, когда-то к нему была тропинка. Этот родник располагался между двумя оврагами, по переулку. Мы, с Юлией Федотовной Бочкаревой пытались его отыскать, но, увы, из-за зарослей обнаружить его не удалось. Конечно было обидно, что не нашли, но у нас была надежда, что его нам покажет Василий Александрович Архипов. Мы встретились, и получили его согласие, показать нам «Тихон родник».

На второй день (1.10.2020 г.) наши поиски продолжились уже с помощью нашего проводника Василия Александровича,– продолжила свой рассказ Ирина Михайловна,– представьте себе нашу радость, мы нашли заветный родник. Нашли! Мы были в восторге от находки.



Первым начала разговор ***Юлия Федотовна***:

– Здесь рядом жил ветеран войны, мы его звали дядя Тихон, возможно он первым обнаружил этот источник, поэтому и родник назвали его именем.

– Может он сам выкопал? – предположил Василий Александрович.

– Это может быть, даже сруб сохранился. А родник глубокий, вода чистая и прозрачная. Смотрите, вот отсюда вода выходила, она журчала. Я и сейчас хочу уловить это журчание. Немного расчищу руками. Ой, журчит, журчит,– удивилась Юлия Федотовна,– вода такая холодная и вкусная! Только родник надо обустроить и проложить сюда дорогу, людям, на радость, а пока сюда можно прийти только по лугам, но там не безопасно.

От радости я с пафосом заявила на камеру:

– Сегодня произошло важное событие для жителей нашего села. Мы обнаружили давно забытый «Тихон родник» и вписали его в историю нашего села».

***Рассказал Василий Петрович Кузьмин:*** «В 2010 г. с Божьей помощью в С. Киремети была открыта часовня (рядом со Святым источником). Накануне открытия этой часовни произошло чудо – в высохшем от жары роднике вода вновь потекла в полную мощь. Вот такая история» (5.11.2016).

### Безымяный родник

Этот родник расположен в огороде Елизаветы Иванчиной (Глухаревой). Там все еще лежат старые бревна от сруба. Родник давно заброшен, он не имеет конкретного названия.

### Вблизи поляны «Чүлмәк эшни» есть родник…

Недалеко от чувашской стороны деревни, вблизи поляны «Чүлмәк эшни», с незапамятных времён был родник, он давал прохладу и воду людям, идущим в лес или из леса. Родник и сейчас стоит на месте, а вот поляны уже нет, там посадили ели, и растет лес. Со временем родник засорился, зарос травой, и представлял печальное зрелище. Вода стала мутной, непригодной для питья, так как исчез отток воды, и родник постепенно превращался в болото. В 2010 г. родник очистили, поставили сруб (руководил работами В.П. Кузьмин).

Эти полумеры проблему до конца не изжили, но они позволили в дальнейшем собраться силами и устранить «головную боль» этого родника.



В 2018 г. жители села решили благоустроить этот родник. Один из активных жителей села Николай Михайлов объявил сбор денег с населения. Вскоре начались строительные работы. Собранных денег хватило в основном на очистку и каптаж родника. Из-за финансов дело замедлилось, и строители в 2019 г. обратились к главе сельского поселения Андрею Владимировичу Парфенову за помощью. Вскоре строителям выделили необходимые деньги. Рабочим удалось обеспечить отток воды из родника, соорудить крышу, настелить полы из брусчатки, сделать подпорные стены.

Над благоустройством родника безвозмездно работали: Николай Михайлов, Анатолий Трофимов, Олег Тяманов, Владимир Симаков, Михаил Муртазин, Анатолий Новичков, Виниамин Муртазин, Андрей Парфенов, Николай Маланчев, Ильмир Минниханов, Виктор Муртазин, Виталий Трофимов, Вадим Парфенов, Григорий Парфенов, Михаил Маланчев, Валерий Филипов. Так, общими усилиями, родник забил в полную силу. Люди благодарны каждому, кто внёс посильный вклад в это благое дело. Родник освещён. Живи, родник, живи!

**Родник Тимка**

Находится в живописном месте на левом берегу р. Киреметь, действует с 1930-х гг., обустроен в 2000 г.

***Село моё родное, любимое! Здесь много красивых и неповторимых родников. Мне очень хочется, чтобы они были благоустроены и не забыты, а когда-то заброшенные родники были вновь возрождены, чтобы мы могли прийти туда, как в дни радости, так и в дни печали.***

*Фотографии Ирины Ишаевой*

*Фәүзия Бәйрәмова*

# АТЛАСИ ҺӘМ ТУЙКИННАРНЫҢ КАЗАНГА КАЙТУЫ...

Сентябрьнең соңгы көннәрендә Казанның милли тормышында зур вакыйгалар булып узды – Татар китабы йортында бертуган Туйкиннар атналыгы уздырылды. Кем соң ул – Туйкиннар, милләт ни өчен аларны шулай зурлап искә ала? 1938 елның 15 февралендә Һади Атласи белән бергә атып үтерелгән абыйлы-энеле Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар алар, педагоглар, язучы-тарихчылар, золым корбаннары...




Татар китабы йортында уздырылган «Туйкин көннәре»ндә катнашучылар. Казан. 29.09–07.10.23.

Бөгелмә-Шөгер төбәгендә туып-үскән бу туганнар гомер буе балалар укыткан, дәреслекләр, фәнни һәм әдәби хезмәтләр язган, халык авыз иҗатын җыйган, аларны матбугатта бастырганнар. Ләкин кайбер хезмәтләрен, бик теләсәләр дә, Казанда бастырып чыгара алмаганнар. Шулай ук аларның Казанда яшәү һәм эшләү хыялы да тормышка ашмый. 1937 елны бертуган Туйкиннарны Казанга тоткын хәлендә, богаулап китерәләр һәм халык дошманы, дип атып үтерәләр. «Укытучылар эше – Атласовщина» дип аталган бу җинаять эше буенча Бөгелмә-Әлмәт төбәгеннән 107 татар кулга алына, алар арасында иң күбе укытучылар була, аннан муллалар, хезмәткәрләр. 1937 елның октябрь аенда берьюлы 24 кешегә суд була, 9 кешене атып үтерергә хөкем итәләр. Шул тугызның икесе абыйлы-энеле Туйкиннар була...

Моңа кадәр алар эшләп киткән Бөгелмәдә һәм нәсел дәвамчылары яшәгән Әлмәт шәһәрендә Туйкиннарны зурлап искә алалар иде. Ниһаять, алар менә Казанга да әйләнеп кайтты... Мәдәният министрлыгы белән музейлар берлеге, Татар китабы йорты уздырган мондый атналык тарихта беренчесе һәм ул Туйкиннардан башланды.

Бертуган Туйкиннарга багышланган атналык 2023 елның 29 сентябрендә музей күргәзмәсе белән башланып китте. Бу күргәзмәдә Кәбир һәм Фазыл Туйкиннарның китаплары, тарихи фотолар, документлар, бертуганнарның шәхси әйберләре куелган иде. Борынгы Туйкә нәселенең туган төбәге булган Зәй-Каратай (Лениногорск районы) авылы музеennан да махсус күргәзмә алып килгәннәр иде.

Туйкиннарга багышланган бу чаралар атна буе дәвам итте. 30 сентябрь көнне иртәнге якта зиратта, репрессия корбаннары мемориалында алар рухына Коръән укылды, исемнәрен әйтеп, дога кылынды, чәчәкләр салынды. Биредәге ак мәрмәр ташларга шул елларда атып үтерелгән меңләгән кешенең исеме уелып язылган. Алар арасында 1938 елның 15 февралендә атып үтерелгән Һади Атласи, Кәбир Туйкин, Фазыл Туйкин, Гани Алтынбаев, Касыйм Исхаков, Сабир Уразманов, Барый Фәттахов, Зәкәрия Фәттахов, Рәшит Яруллин исемнәре дә бар. Барый Фәттахов белән Зәкәрия – аталы-уллы, Барый хәзрәткә 63 яшь, улына 28 була. Һади Атласи белән Рәшит хәзрәт – баҗайлар, Фәттаховлар белән хатыннары ягыннан туганнар. Рәшит Яруллин – киләчәктә дөньякүләм танылу алачак тарихчы Әхмәт Тимернең әтисе. Лашман мулласы Касыйм хәзрәт Исхаков – Гаяз Исхакыйның туганы. Күрәсез, иң затлы татарларны, милли элитаны, сайлап алып юк иткәннәр...

Мемориалга Казаннан, Әлмәттән, Уфадан, Бөгелмәдән, Лениногорски районының Зәй-Каратай авылыннан Туйкиннарның нәсел дәвамчылары килгән иде. Алар бабаларының исеме уелган таш янында башларын иеп, озак басып тордылар,шул исемнәрне бармаклары белән капшап, гүя аларның җаннарын җылытырга теләделәр...

Аннан соң эш Татар китабы йортында дәвам итте, анда «Туйкиннарның иҗади һәм педагогик мирасы» дип аталган темага түгәрәк өстәл утырышы узды. Мәгърифәтче мөгаллим, язучы, телче, тарихчы, фольклорчы Фазыл һәм Кәбир Туйкиннарның иҗаты әле аз өйрәнелгән, әмма инде таянып сөйләрлек хезмәтләр бар. Галимә, филология фәннәре кандидаты Эльмера Ханнанова-Галимҗанова әле 2004 елда ук «Фазыл Туйкинның иҗат мирасы (иҗат ысулы һәм мотивлар)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаган булган. Түгәрәк өстәл утырышында да ул төп докладны ясады, Фазыл Туйкинның иҗаты буенча күп яңа мәгълүмат бирде. Шунысын да әйтергә кирәк, Эльмера ханым иске татар теле буенча белгеч, текстолог,

Фазыл һәм Кәбир Туйкиннарның хезмәтләрен гарәп әлифбасыннан кириллга күчергән шәхес, аңа Аллаһның рәхмәтләре булсын!

Ә шагыйрә Эльмира Шәрифуллина исә әле 1972 елда ук Фазыл Туйкин иҗаты буенча Казан дәүләт университетында диплом эше язган, фәнни җитәкчесе Мөхәммәт Мәһдиев булган. Туйкиннарга багышланган чарада Эльмира Шәрифуллина да катнашты һәм чыгыш ясады. Ул шул вакытта ук Уфага барып, Фазыл Туйкинның хатыны, балалары белән очрашкан, алардан күп мәгълүмат алган. Эльмира ханым Фазыл Туйкинның 1912 елда басылып чыккан «Җырлар әхтәрисе» дип аталган китабын, гарәп хәрефләреннән кириллицага күчереп, 2017 елда яңадан бастырып чыгара, ул чарада катнашучыларга да таратылды. Әфәрин, Эльмира ханым, сез тарих төпкеленә китеп барган бер милләт каһарманын, аның исемен, мирасын яңадан дөньяга кайтардыгыз! Сезнең бу җыелышта Туйкиннар турында кат-кат «Алар милләткә тезләнеп хезмәт иткәннәр» дигән сүзләрегез йөрәкләргә уелып калды...

Бөгелмәдән тарих фәннәре кандидаты, Һади Атласи исемендәге иҗтимагый фонд җитәкчесе Алсу Мөхәммәтдинова үзенең чыгышын тәҗрибә уртаклашу белән башлап җибәрде. Бер көндә атып үтерелгән Һади Атласи да, бертуган Туйкиннар да Бөгелмәдә милли мәгарифкә нигез салучылар булып тора. Аларның бу эшчәнлеге совет властеның беренче елларына туры килә. Мәгърифәтче-мөгаллимнәр бирედә татар мәктәпләре, балалар йортлары ачалар, үзләре үк шунда укыталар, яңа чор өчен яңа дәреслекләр язалар. Юкка гынамы аларга каршы ачылган җинаять эше дә «Укытучылар эше» дип атала, 1936–1938 елларда шул төбәктә кулга алынган 107 татарның 54 е укытучы була. Күреп торасыз, хакимият элек тә иң беренче эш итеп милли мәктәпләрне, мөгаллимнәрне юк иткән, Алсу ханым бу хәлләр турында җаны әрнеп сөйләде...

Бөгелмә шәһәрендә 1994 елдан бирле Һади Атласи фонды эшләп килә, биредә милли рухны заманында Атласи һәм Туйкиннар тотып торган кебек, бүген дә бу урыс шәһәрендә татарлыкны шушы фонд, аның тирәсенә берләшкән милләтпәрвәрләр саклап тора. Биредә һәр елны февраль аенда Атласига һәм аның белән бергә атып үтерелгән татарларга багышлап, Хәтер кичәсе уздырыла. Әле ярый аларны искә алырга Бөгелмә бар, шушы татарларыбыз бар!

Мин исә үземнең чыгышымны «Һади Атласи һәм бертуган Туйкиннар: уртак хезмәт һәм уртак язмыш» дип атадым. Әйе, аларның милләткә хезмәтләре дә, фаҗигале язмышлары да уртак булган. Әйткәнемчә, Һади Атласи да, бертуган Туйкиннар да – мәктәп-мәдрәсәләр тоткан, укыткан, дәреслекләр язган мөгаллимнәр. Алар үзләре дә мәдрәсә белеме алган дин әһелләре. Атласи белән Туйкиннарның тагы бер уртаклыгы – алар

тарихчылар. Һади Атласи әле инкыйлабка кадәр үк үзенең данлыклы «Себер тарихы», «Сөембикә», «Казан ханлыгы» китапларын язып бастырган була, аларны милләт белә, таный. Ә менә Кәбир һәм Фазыл Туйкәнең 1919 елда Ырынбурда басылып чыккан «Төрек тарихы» китабын бик азлар гына белә әле. Энциклопедик дәрәҗәдәге бу хезмәт өч томнан торырга тиеш булган, әмма шушысы гына чыгып калган, башкалары юкка чыккан. Бу китап дәреслек рәвешендә язылган, укырга җиңел, мәгълүматка бик бай. «Бертуган Туйкиннар» китабына кереш сүз язган галим Миркасыйм Госманов та Туйкиннарның бу хезмәтен югары бәяли, «... бертуган Туйкиннарның «Төрек тарихы» исемле дәреслек китабы эчтәлегенең киңлеге, тәкъдим ителгән материалларның байлыгы җәһәтеннән шул чорда татарча язылган һәм басылып чыккан тарихи хезмәтләр арасында иң күренекле урыннарның берсен биләп тора», ди ул. Миркасыйм Госманов аларны тарихчы буларак «Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдин һәм Һади Атласилар салган сукмаклардан барганнар» дип яза.

«Төрек тарихы» хезмәте белән «Бертуган Туйкиннар» китабында танышырга була, аны галимә Эльмера Ханнанова-Галимҗанова гарәп хәрефләреннән кириллга күчереп, тулысынча бастырып чыгарган. Мин бу китапны русчага да тәрҗемә итеп, ике телдә яңадан аерым китап итеп бастырып чыгарырга тәкъдим иттем. Ни кызганыч, Туйкиннарның Уфадан килгән кайбер нәсел дәвамчылары татарча бөтенләй белмиләр булып чыкты...

Әйткәнемчә, Атласи һәм Туйкиннарның төрмә тарихлары да уртак. Һади Атласины милләт өчен төрмәгә беренче тапкыр 1909 елда утырталар, шушы ук елны имам-мөгаллим Кәбир Туйкин да яңача укыткан өчен төрмәдә утырып чыга. Һади Атласины икенче тапкыр 1921 елда, өченче тапкыр 1929 елда төрмәгә утырталар, 1931 елда Фазыл Туйкинны да хөкем итәләр. 1933 елда Соловкидан кайткан Һади Атласи Бөгелмәдә эш таба алмый, 1934 елда гаиләсе белән Казанга күчә, 1936 елның июлендә, алтмыш яшенә бер ай кала, аны тагы кулга алалар һәм төрмәгә ябалар, бу юлы инде мәңге чыкмаска... 1937 елның гыйнварында Фазыл Туйкинны, февральдә абыйсы Кәбирне авылдан богаулап Казан төрмәсенә китереп ташлыйлар. Ел буе кыйнап, газаплап, 1937 елның 28 октябрендә хөкем карары чыгаралар, 1938 елның февралендә 9 татарны, бәйсез төрки-татар дәүләте төзәргә теләгәннәр, дип, атып үтерәләр. Мин Казанда аларга суд булган, хөкем карары чыгарылган бинага истәлек тактасы куярга, дигән тәкъдим ясадым. Ул – элеккеге НКВД клубы, Менжинский клубы, дип тә йөрттеләр, хәзер анда Пушкин исемендәге рус мәдәният үзәге. Казанда Һади Атласи, Туйкиннар һәм алар белән бергә атып үтерелгән татар зыялылары истәлегенә бер нәрсә дә юк. Аларның хәтта каберләре дә юк... Истәлек тактасының үрнәге Бөгелмә шәһәрендә бар, аны Һади Атласиның улы Угыз Атласов әтисе

һәм бертуган Туйкиннар укыткан мәктәп диварына куйдырган иде. Хәзер шушы эшне Казанда эшләргә кирәк, монысы инде татар зыялылары эше…

Түгәрәк өстәл утырышында, галимнәрдән тыш, Туйкиннарның нәсел дәвамчылары, туганнары да чыгыш ясады. Әлмәттән төбәк тарихчысы, Габдрәхим Утыз Имәни, Ризаэддин Фәхреддинның нәсел шәҗәрәләре турында уникаль китаплар язган Әлфия Ямаева, Казаннан Туйкиннар атналыгын уздыруда иң күп көч куйган нәсел дәвамчысы – Татарстан Мәдәният министрлыгының Җәмәгатьчелек шурасы әгъзасы Эльвира Рысаева, Бөгелмәдән Туйкиннарның нәсел дәвамчысы Әлфия Сафина, Әлмәттән «Тамырлар – Корни» тарихи һәм мәдәни мирасны өйрәнү, саклау һәм үстерү фонды директоры, Туйкиннарның мирасын саклау өчен зур эшләр башкарган Марат Туйкин бабалары турында якты хәтирәләр белән уртаклаштылар.

Көннең икенче яртысында Туйкиннарның туган төбәге булган Зәй-Каратай авыл мәктәбе укытучылары һәм укучылары чыгыш ясады. Соңрак милли бәлешле табында Туйкиннар нәселе вәкилләре очрашты. Иң азактан чарада катнашучылар заманында бертуган Туйкиннар белем алган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә булдылар, бабалары рухына сәдакалар биреп, намазлар укып, догалар кылып таралдылар. Дога белән башланган сентябрьнең соңгы көне дога белән тәмамланды, Аллаһ разый булсын, милләтебезгә файдасы тисен!

Туйкиннар атналыгының башка көннәрендә исә нәсел шәҗәрәләрен ясау остаханәләре, күргәзмә-экскурсияләр, «Ачык уку» көнендә Фазыл Туйкинның «Әхкяме ислам» китабын иске татар телендә уку, остазлар көнендә – Нургали Надиев сәяхәтнәмәсен уку, бертуган Туйкиннарның әсәрләрен кычкырып уку, «Фазыл җырлары», дип аталган әдәби-музыкаль кичә һәм башка бик күп мәдәни чаралар узды.

Шунысын да әйтергә кирәк, бертуган Туйкиннарга багышланган атналык чараларына Казаннан, Әлмәттән, Уфадан, Бөгелмәдән аларның күп санлы туганнары, оныклары, нәсел дәвамчылары килгән иде. Гаять зур, затлы, көчле нәсел бу! Шушындый тарихи, бик кирәкле, мәгънәле, затлы атналыкны оештырган өчен Татар китабы йорты – Татар әдәбияты тарихы музее директоры Айдар Шәйхинга әфәрин, мең рәхмәт! Бу проект дәвамлы булсын иде... Башка шундый кадерле шәхесләребезне дә, бигрәк тә, Һади Атласи кебек золым корбаннарын да, Казаныбызның уртасында, зурлап искә алсак иде, алар моңа лаек. Быел Һади Атласиның «Сөембикә», киләсе елга «Казан ханлыгы» китапларының басылып чыгуына 110 ел тула. Менә шул вакыйганы Казанда, Татар китабы йортында тарихи-мәдәни атналык итеп билгеләп үтсәк, золым корбаннарына карата милләт алдында бурычыбызны үтәгән булыр идек.

*30.09.23. Казан–Чаллы*

*Рәшит Минһаҗ*

# КИНӘЛЕ ЕЛГАСЫ БУЕНДА, ТАУЛАР ИТӘГЕНДӘ

*Уңышлы татар авыллары сериясеннән*

Оренбур якларында берничә тапкыр булганым бар. Борынгы кыпчак-кимак бабаларыбыз, Идегәй яугирләре дәүләт тоткан бу тарафлар беренче күрүдә үк тигез һәм киң кыр-болыннары, мул сулы елга-инешләре белән хәтергә уелып калды. Дала-сәхрәләрендә, җылы җилләр куенында тирбәлеп, иркәләнеп утырган лалә чәчәкләре әле кичә генә күргән кебек. Сарылы-кызыллы лалә басуларын Голландиядә күреп шаккатканым бар-барын. Әмма болары – кеше кулы белән игелә, төрле илләргә озатыла, күпләп сатуга чыгарыла торган чәчәкләр түгел, табигать анабыз үзе бүләк иткән, төрки-татар халкы аеруча үз күргән, сәхрәдә, иркенлектә үскән матурлык, нәфислек өлгеләре!

Бу тарафларны быел яз көне урап кайту насыйп булды. Россиядәге уңышлы татар авылларын барлау проектын тормышка ашырып, мин Әсәкәй районының Кинәле елгасы буенда, таулар итәгендә утырган Яңа Солтангол, Иске Солтангол авылларын, шул исәптән йөз ел элек – 1923 елда гына Иске Солтанголдан аерылып башка чыккан, үр башында утырган Корбанай авылын 20–26 март көннәрендә гиздем. Биредә ташу киткәнен күрү дә насыйп булды. Ташу ел да китә, дип кайберәүләрнең моңа исе китми-китүен. Әмма табигать-тереклек яңаруның, кышкы салкыннардан котылу, чистарынуның үтә гайрәтле ишарәсе булганга, күңелләрне әсәрләндерә торган күренеш бу. Елга суы 4,5 метрга күтәрелеп, бәрәңге, яшелчә бакчаларына керсә дә, шөкер, зыян-зәхмәте сизелмәде. Дәү-дәү боз кантарлары, Корбанайга илтә торган тимер күпер субайларын бераз дөмбәсләп алды да, көче җитмәслеген чамалап һәм мул агымсу кодрәтенә бирелеп, ары таба юлын дәвам итте.

**Тарих битләреннән**

Әсәкәй якларына килеп чыгуыбыз тиктомалдан гына түгел, билгеле. Бердән, бу район – өлкәдәге татар халкы иң ишле яши торган төбәк. Әлеге районның – ярты халкын, район үзәге халкының 80 процентын татарлар тәшкил итә. Икенчедән, «Алга» агрохолдингының үзәге булган Яңа Солтангол өлкәдәге иң уңышлы авыллардан санала. Авыл картларының әйтүенә караганда, аерым алганда, Корбанайда туып үсеп, хәзерге вакытта Әсәкәйдә яшәп ятучы, төбәк тарихын өйрәнүче 85 яшьлек Әмир Сөләймановның сөйләвенчә, Кинәле буендагы Әсәкәй, Колшәрип, Яңа Солтангол, Иске Солтангол авылларына XVIII гасыр урталарында нигез салынган. Бу сүзләр галимнәребез раслауларына да туры килә. Галимҗан

Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясеннән чыгарган «Оренбург өлкәсе татарлары» дигән җыентыкта Лилия Дәүләтшина, Марсель Әхмәтҗанов бу төбәкнең XVIII гасырның 30 нчы елларыннан Россия тарафыннан ныклап үзләштерелә башлавы, илнең үзәк губерналарыннан, шул исәптән Казан губернасыннан күпләп күчеп килүләре турында яза. 1743 елда чик буе кирмән-крепосте буларак Оренбург шәһәренә нигез салынуы – моның бер саллы дәлиле (тарихчыларыбыз бу төшнең очраклы җир булмавын, Кимак каһанлыгының бер биләмәсе башкаласы торган урын икәнлеген искәртә). Яңа Солтангол авыл Советы рәисе Фатих Асылгәрәев, ерак тарих хакында сүз чыккач: «Авыл картлары Иске Солтангол белән Яңа Солтангол арасын дагы зиратта 1743, 1747 нче елларга караган кабер ташлары булуы турында сөйли иде»,– дип хатирәләрен яңартты. Биредә байтак еллар колхоз рәисе һәм авыл советы җитәкчесе булып эшләгән Ягъфәр Фәттахов үз чиратында, авылларның яшен аз гына яшәртеп, өлкәннәрнең сөйләве буенча, Иске Солтангол – 1760 нче, Яңа Солтангол 1770 нче елларда нигезләнгән булырга тиеш, дип исәпли.





Яңа Солтангул авылы зиратында сакланып калган, комташтан ясалган кабер ташлары.

Тарих белән кызыксынучы, шигърият сөюче, «Тормыш хатирәләре» дигән шигырь җыентыгы чыгарган 85 яшьлек Яхъя Җиһанголов, Солтанголга башкортлар нигез корган, бу якка Салават Юлаев яугирләре килеп чыккан, дип санаса, Әмир Сөләйманов, Кинәле буендагы авыллар-

га Казан, Касыйм ягындагы кысрыклауларга, милли, дини басымга түзә алмыйча, иркен җирләр эзләп киткән татар бабаларыбыз нигез салган, дип исәпли. Бу уңайдан аның «Яңа вакыт» өлкә газетасында «Хакыйкать кайда?» дигән саллы мәкаләсе дөнья күргән (2022 нче елның 14 декабрь саны). Ул анда тарихчылар Дамир Исхаков, Петр Рычков, тел белгечләре Дөрия Рамазанова, Радик Сибагатов, Әлмәттә яшәүче, төбәк тарихын өйрәнүче Булат Заһиров хезмәтләренә, Оренбург губернаторы А. Путятинның 1767 елда патшабикәгә язган аңлатма-хәбәрләренә нигезләнеп, бу тарафларда беркайчан да башкорт авыллары булмавын дәлилләп бирә. Ә. Сөләйманов, Б. Заһиров хезмәтләренә таянып, «1755 елда ясалган борынгы картада (П.И. Рычков картасы) Кинәле елгасы буенда Гәшир, Колшәрип, Солтангол авыллары төшерелгән»,– дип яза. Димәк, Ф. Асылгәрәев телгә алган теге кабер ташлары турындагы сүз чынбарлыкка туры килә, Иске һәм Яңа Солтангол авылларына XVIII гасырның 30–40 нчы елларында нигез салынган булып чыга.

Авыл атамасы кеше исеменнән алынуы аңлашыла инде. Әңгәмә корып утырганда Яхъя Җиһанголов, Солтангол исеменә аңлатма биреп, бу сүз Солтан колы дигәнне белдерә, дигән фикерен җиткерде. Тел белгече, күренекле галимебез Гомәр Саттаров «Татар исемнәре сүзлеге», «Татар исемнәре ни сөйли?» кебек хезмәтләрендә кеше исемнәренең бер өлеше булып килә торган -гол, -гул, -кол кушымча-сүзләрен, «кол» мәгънәсен белдерә, дип аңлата. Миңа калса, бу очракта әдәбиятчы галимебез Хатыйп Миңнегулов аңлатмасы чынбарлыкка якынрак. Әлеге сүз-кушымчалар «угыл» сүзенең үзгәртелгән варианты гына дигән фикердә тора ул. «Татар теленең этимологик сүзлеге» авторы, телче галим Рифкать Әхмәтьянов, борынгы бабаларыбыз, ир угыл, кыз угыл, дип сөйләшкән; бу сүз «бала, нәсел, токым» дигән мәгънәне аңлатучы – ог, -ок дигән тамыр сүзгә барып тоташа, дип шәрехли. Димәк, Солтангол – солтан колы түгел, солтандай бала ул. Димәк, 1920 елда Яңа Солтанголдан аерылып башка чыккан һәм 1997 елны таркалган Муллагол авылына нигез салучы кешенең исеме дә мулла колын түгел, мулла нәселе дигәнне яки мулла сыман абруйлы кеше булсын дигән теләктән чыгып кушылуны аңлата. Шулай итеп, Бурангол дигән исем, буран колын аңлатмый, буранлы көнне туган баланы белдерә. Йомагулның да җомга көнне туган бала икәне мантыйкка бик тә туры килә. Димәк, әдәбиятчы галимебез бабасының исеме Миңнегул да бәхетле колны түгел, бәхетле баланы аңлата булып чыга. Мәгълүм ки: халкыбыз миңне бәхеткә, уңышка юраган.

Шунысы да бар: авыл атамасын үзегез ничек әйтәсез, Солтангул дипме, Солтанголмы, дип кызыксынгач, авыл Советы башлыгы Фатих

Асылгәрәев: «Безнең халык Солтангыл дип сөйләшә»,– диде. Әлеге хәл үзе үк исемнәргә өстәмә булып килүче -гол, -кол компонентның «угыл» сүзеннән ясалуын күрсәтә. Дөрес, «кол» компоненты исемнең алдында килгән сурәттә, ягъни Коләхмәт, Колшәриф булганда гарәп теленнән кергән Габдулла, Шәрифулла сыман Алла колы мәгънәсен белдерүе бәхәс уятмый.

Алдарак телгә алган хезмәтендә Л. Дәүләтшина, бу якта яшәүче татар халкының сөйләм рәвеше телебезнең урта диалектына карый, анда көнбатыш, ягъни мишәр диалектының көчле йогынтысы сизелә, ди. Аерым алганда, диалектолог Зилә Садыйкова: «Говоры оренбургских татар» дигән хезмәтендә, Богырыслан, Бозаулык өязләрендә урта диалектның камышлы сөйләше киң таралуын яза. Иске һәм Яңа Солтангул авыллары инкыйлабка хәтле, әүвәл Бөгелмә, соңрак Богырыслан өязенә кергән (Богырысланга авылдан утыз гына чакрым). Мин үз чиратымда җирле халыкның Минзәлә, Мөслим ягындагы шикелле «әткәй», «әнкәй», «бидрә», «сөт өсте» дип сөйләшүенә, «җырлый» дип түгел, мишәрләр кебек «йырлый» дип йомшартуына игътибар иттем. Мишәр йогынтысы дигәннән, шуның тәгаен бер мисалы. Мине авыллар буйлап халык белән очраштырып йөргән Ягъфәр Фәттахов, шәҗәрәсе турында сүз чыккач: «Фәттах бабам Сәйфетдинов 1870 елны Татарстандагы Чирмешән районының Түбән Кәминкә авылында туган. 1898 елда, бәхет эзләп, Кинәле якларына килеп чыга, өйләнә. 1911 елны хатыны, өч баласы белән туган ягына әйләнеп кайтса да, дүртенче балалары – әтиебез Яхъя тугач, 1914 елны кире Солтангулга әйләнеп кайталар, шушында төпләнеп калалар»,– дип сөйләде.

Ни кызганыч, халыкта шәҗәрәләр сакланмаган. Авыл картларының берничәсе генә 5–6 нчы буын бабасының исемен әйтә алды. Күпчелек 3–4 буыннан артык шәҗәрәсен белми. Дөрес, Илдус Дәүләтов кына, 14 нче буынга хәтле бабаларының исемнәрен ачыклый алган. Аның нәселе күренекле Манаш бәккә барып тоташа.

**«Алга» алдан бара**

«1990 елларда авыл хуҗалыгында эшләүчеләргә бик кыен булды. Ленин орденлы, алдынгы «Коминтерн» колхозы бар иде. Ул да таркалып бетте. Шулай ук алдынгы саналучы «Тамьян», «Правда» колхозлары да таркалды. Нибары өч күмәк хуҗалык калды. Әгәр 2001 елны безнең «Победа» колхозында (бүген «Алга» агрохолдингы) җитәкче вазифасына Илдус Дәүләтов алынмаган булса, без дә таркалу чигенә килеп җиткән идек. Ул, ныклап тотынгач, ышанычлы адымнар белән алга барабыз»,– дип искә алды ул болгавыр елларны үзе шушы «Победа» колхозын 1993–1999 елларда җитәкләгән Ягъфәр Фәттахов.



Яңа Солтангул авылы ветераны Ягъфәр Фәттахов белән Шакир Манашев.

Ни кызганыч, илебездә үткәрелгән реформалардан соң, районда аягында басып кала алган күмәк хуҗалыклардан Куйбышев исемендәге (Колшәрип авылы) колхоз белән Димитров исемендәге колхозны (Юдинка авылы) гына атый алды әсәкәйлеләр. Башка колхозлар җирендә эреле-ваклы крестьян-фермер хуҗалыклары эшчәнлек алып бара. Хәер, «Алга»ны да бүген элекке мәгънәдә колхоз дип әйтү дөрес булмас. Хәзерге вакытта күп тармаклы авыл хуҗалыгы берләшмәсе-агрохолдинг ул. Илдус әфәнде, авыл хуҗалыгы белән генә шөгыльләнү җитми дип, автотранспорт компаниясе, битум чыгару заводы, төзелеш оешмасы да булдырган. Бүген ул оештырган нефть тармагында – 50, автотранспорт оешмасында – 30, төзелештә ике дистәдән артык кеше эшли. Авыл хуҗалыгы тармагында даими эшләүчеләр 100ләп булса, җәй айларында аларның саны 120гә җитә. Миңа калса, биредә уңышлы авыл, уңышлы хуҗалык булып яшәүнең төп сере: эшчәнлекне менә шушылай күп тармаклы итеп оештыруда. Хәзерге вакытта авыл җирендәге төп проблема, мәгълүм ки, эш урыннары җитмәүдә. Шушы рәвешле И. Дәүләтов авылны саклап калуның ышанычлы юлын тапкан. Әлеге тармакларда нигездә солтангуллылар эшли. Дөрес, вахта ысулы белән Себергә барып эшләүчеләр дә юк түгел. Иң мөһиме: күпчелек халыкка эш урыны бар.

– Халык белән килешеп, сөйләшеп эшләсәң, үз вакытында һәм яхшы хезмәт хакы түләсәң, китмиләр. Эшләүчеләребезнең уртача яше – 40–45. Хуҗалыкның барча эш юнәлеше белән даими кызыксынып торырга, системалы, эзлекле эшләргә кирәк. Максат куйдың, шуңа алындың икән,

максатыңа туры бару зарур,– ди хуҗалык башлыгы Илдус Дәүләтов эшчәнлекне оештыруның төп нигезләре турында. 2021 елда хуҗалыкта уртача хезмәт хакы 46 мең сумга җитсә, былтыр, рекордлы уңыш алу нәтиҗәсендә, ул күрсәткеч 55 мең сумны тәшкил иткән. Аннан, 27 мең тонна бөртек җыеп алдык, дигән сүзне ишеткәч, ул хәтле ашлыкны кая куеп бетердегез, дип кызыксынмый кала алмадым. Күрше-тирә хуҗалыкларның амбарларына салып торганнар икән. Инде шушындый уңыш булганда яхшы саклармлык урының булсын, дип бу көннәрдә алгалылар Әсәкәйдә, тимер юл буенда 25 мең тонна бөртек сыйдырышлы элеватор салып ята. Июнь-июль аеннан да калмыйча, аны ачып эшләтә башларга җыеналар. Әлеге элеваторның җиһазларын Төркиядән кайтартканнар. Төркиядән тегермән кайтарту ниятләре дә юк түгел.

Хәзерге вакытта бу хуҗалыкның 14 мең гектар сөрүлек җире бар. Былтыр шуның 4 мең гектарында көнбагыш иккәннәр. Сер түгел, узган ел көзен, кар иртәрәк төшкәнгә, шактый кына хуҗалыкның көнбагыш басулары яртылаш диярлек урылмады. «Алга»да бер гектар басу да җыеп алынмыйча калынмаган. Бөртеклеләрнең һәр гектарыннан уртача – 35әр центнер, көнбагыштан 30,9ар центнер уңыш алганнар монда. Былтыр бер сыердан 6817әр килограмм сөт савып, бу юнәлештә дә күрсәткечләрен шактый яхшыртканнар хуҗалыкта. Үз вакытында савым сыерларының санын бер мең, эре терлек санын өч мең башка җиткерәләр «Алга»да. Хәтта сөт заводы ачып эремчек, кефир, катык, сөт җитештерә, Әсәкәйдә кибет ачып, шунда сата башлыйлар. Әмма, мәшәкате күп дип, бу юнәлештән баш тартканнар. Бүген 200 баш кына савым сыеры бар монда. Хәзер биредә күбрәк ит җитештерү юнәлешенә басым ясыйлар. Чит илдән мәрмәр ит бирә торган токым кайтартканнар. Бүген аларның саны 160ка җиткән, бу көннәрдә әле тагын шундый 100 терлек кайтартмакчылар. Гомумән, якын елларда токымлы эре терлек санын бер мең башка җиткерергә исәпләре. Мәрмәр итне Казан, Уфа, Самара рестораннары бик теләп сатып ала икән. Эре терлек турында сөйләп, атчылык турында да әйтми китсәк, дөрес булмас. «Алга»ның ат абзарында 150 баш ат тотыла бүген. Елкы хайванын нигездә казылык ясау өчен асрыйлар. Хезмәт хакының бер өлеше буларак та, хуҗалыкта эшләүчеләргә ат бирәләр. Гомумән, монда шактый йорт үзләре өчен казылык ясый. «Тау битләренә, су, юл буйларына – 300 гектарда нарат утырттык. Нарат үсентеләрен таптамасыннар, дип әлегә атларыбызны агрохолдингыбызга кушылган Троицкое авылына күчереп тордык. Киләчәктә кымыз ясарга исәп. Авыр йөк атлары кайтарту нияте дә бар»,– диде атчылыкның киләчәге турында сүз чыккач И. Дәүләтов.

Биредә күпләп көнбагыш игүләрен яздык инде. Билгеле, аны сыгып, май итеп сату отышлырак. Агрохолдинг хезмәткәрләре моны яхшы

аңлап, үсемлек маен кайнар ысул белән дә, салкын ысул белән дә җитештерүне җайга салганнар.

– Игенчелек тармагында аеруча күркәм уңышларга ирештек. Үсемчелек буенча технология таләпләре ничек кушса, шулай эшлибез. Ашлама җитәрлек кертелә. Техника җитәрлек. Уңыш яхшы чыга. Казанышларыбызның сере шунда: җитәкчелеккә төпле, чын хуҗа килде, үз тирәсендә яхшы команда, белгечләр туплады,– дип сөйләде безгә, Оренбургтан ук килеп, биредә генераль директор урынбасары булып эшләүче Фәрит Мөхәммәтов.

**Йокы туймый**

Фермер хуҗалыгы оештырып, үзләренчә хуҗалык итәргә теләгәннәр дә аз түгел Кинәле буйларында. Нур Дәүләтов 1990 елларда ук бу эшкә алынса, соңгы елларда Илнур Сираев, Фәһим Нигъмәтуллин, Илдар Дәүләтов дәүләттән 5әр миллион сум грант алып фермерлыкка керешеп киткән. Нур Дәүләтов игенчелек һәм берләттән терлекчелек белән дә шөгыльләнсә, сыер малы, атлар асраса, күптән түгел генә тотынганнарның өчесе дә терлекчелек тармагына өстенлек биргән. Шунысы кызык: тәвәккәл егет Илнур бу эшчәнлекне мәктәптә физика, технология, физкультура укыту белән бергә алып бара икән.

Авыллар өчен яхшы программа бу. Абзарларым бар иде. Дәүләт биргән акчаның яртысына трактор, печән чаба, җыя, төргәкли торган җайланма – рулонник, яртысына мал алдым. 30 гектар җирдә – арпа, 10 гектар җирдә күпьеллык үлән чәчтем. Әле тагын арендага җир алырга, киңәергә исәп. Бер эшчем бар. Киңәйсәм, тагын берәү кирәк булачак. Бозауларны санамасаң, кырык баш терлегем – сыер, үгезләрем бар,– дип сөйләде безгә И. Сираев.

Фәһим Нигъмәтуллин фермерлык белән 2019 елдан шөгыльләнә башлаган. Төп булышчысы – хатыны Сәгадәт. Мәктәптә укучы уллары да буш вакытларында мал арасында кайнаша. 16 баш сыер, 19 баш үгез асрыйлар. Сөтне Богырысланнан килеп «Алга»ныкы белән бергә көн дә алып китәләр. Үгезләрен иткә тапшыралар, ашлыкка алыштыралар. «Рәхмәт яусын: дәүләт тә, Дәүләтов та булыша. Печән, арпа, катнаш бөртек кенә түгел, яз көне колхоз силос та бирде. Фермерлар да ярдәм итә. Бер генә проблема бар: йокы туймый»,– ди Фәһим.

Ирем Рафаил абый кебек алтын куллы. Белмәгән эше юк,– дип ирен мактап туя алмый Сәгадәт. – Агач ярдыру җайланмасы – пилорамыбыз бар. Заказлар күп, үтәп өлгерә алмый. Токарьлыкны да, эретеп ябыштыру эшен дә белә ирем. Техникалары ватылса, тегене-моны ясап бир әле, дип фермерлар безгә килә. Алар безгә игенләтә түли.

Сабантуйларга кирәкле җиһазларны да Фәһим ясый. Сыерчык оясы кебек матур чыга. Чын оста бу,– дип сүзгә кушыла Я. Фәттахов.

Алтын куллы Рафаил дигәннәре Иске Солтангул авылы клуб мөдире Рафаил Вагыйзов икән. Өендәге бөтен җиһазны ул үзе ясаган. Өен дә үзе салган. «Утыз ел автосервис миндә. УАЗ машинасын үзйөрешле бульдозер итеп үзгәртеп кордым. Кар күп яуганда урамнарны чистартырга, тигезләргә булышам. Ел да өлкә сабантуйларына Әсәкәй ихатасы ясыйбыз, быелтыр Оренбург Сабантуенда беренче урынны алдык»,– дип сөйләде ул безгә. Гөлләр үстерергә дә һәвәс икән оста. Аның клубы гөлбакчаны хәтерләтә.

**Уңышның сере нәрсәдә?**

Гадәттә уңышлы авылларда җирле хакимият белән хуҗалык җитәкчеләре уртак тел табып, бер-берсен ярты сүздән аңлап эш итә. Монда да җитәкчеләрнең киңәшләшеп эшләүләренә шаһит булдым. «Яшәсен колхоз! Илдус Ядкәрович сау булсын! Спонсор ярдәме булгач, башлаган эшләребезне тәмамламый калганыбыз юк. Берничә ел элек Корбанайда су торбаларын алыштырдык. Быел Яңа Солтангулда су үткәргеч системасын алыштырырга, асфальт юлны яңартырга җыенабыз. Бөтен смета-проект документларын эшләүгә «Алга» түләп бара»,– дип сөйли авыл Советы башлыгы Фатих Асылгәрәев. «Быел авыл территорияләрен комплекслы үстерү федераль программасы буенча грант откан идек. Әлеге 35 миллион сум акчага 4 километр озынлыкта су үткәргеч торбаларын алыштыру, ике су чыгару башнясы кую, 3 километр озынлыгында асфальт юл җәю каралган»,– дип сүзгә кушыла Оренбург өлкә Советы депутаты да булган Илдус Дәүләтов. Тагын да зуррак хыяллар белән яши солтангуллылар. 2024 елга 221 миллион сумга яңа проект ясаганнар. Анда тагын 4 чакрым асфальт юл түшәү, булган асфальт юлның киңлеген алты метрга җиткерү, юл кырында, яктырту баганалары куеп, 4 чакрым озынлыкта тротуар ясау каралган. Бирсен Ходай! Әле тагын инициативалы бюджетлаштыру программасы буенча зиратларны тәртипкә китерү, койма белән әйләндереп алу, юл буенда чүп җыю савытлары урнаштыру буенча шактый эш башкарырга исәпләре. Яңа Солтангул авыл Советына караган әлеге өч авылда биш зират бар. Аларның өчесе койма белән тотып алынган. Инде тагын икесен киртәләп алмакчылар. Өч авылда да мәчет бар. «Алга» агрохолдингы Корбанай белән Иске Солтангулда мәчет салышуда ярдәм итсә, Яңа Солтангулдагы Аллаһ йортын тулысынча үзе төзеткән. Яңа Солтангулдагы урта мәктәпне һәм балалар бакчасын төзекләндерүгә дә саллы өлеш керткән хуҗалык.

**Мәгариф ни хәлдә?**

Биредә балалар бакчасы, мәктәп тә Яңа Солтангулда гына. Ике Солтангул арасы бик якын инде, ике авылга уртак булса да ярый. Ни кызганыч, Корбанайда мәктәп яшендәге өч кенә бала бар. Шул сәбәпле андагы башлангыч мәктәпне дистә ел элек япканнар. Балалар бакчасында, мәк-

тәптә дә тәрбия, укыту эшләре нигездә урысча алып барыла. «Элек без мәктәптә укыганда татар теле, әдәбияты дәресе атнага өч мәртәбә керә иде. Әле 5–6 ел элек кенә икешәр сәгать дәрес укыттык. Хәзер нигездә 0,5 сәгать, ягъни бер атнада татар теле, икенче атнада татар әдәбияты керә»,– дип бәян итте мәгариф өлкәсендәге бүгенге вәзгыятьне татар теле укытучысы Миләүшә Акчулпанова.

Мондый хәлнең сәбәпләрен мәктәп директоры Энже Вафина соңгы елларда авылга шактый гына урыс гаиләсе күчеп килүе, катнаш гаиләләрнең артуы; мәктәпнең алты көнлек укыту атнасыннан биш көнлеккә күчүе, татар теле укытуның ата-аналар рөхсәтенә бәйле булуы, интернетның, социаль челтәрләрнең балаларга зур йогынты ясавы белән аңлатты. «Быелгы уку елында беренче сыйныфка килгән балаларның күбесе татарча бөтенләй белми»,– дип уфтанды ул. Бу вәзгыять уку расписаниесендә дә бик ачык күренә. I класста һәм IV класста татар теле дәрес буларак укытылмый, түгәрәк формасында гына өйрәтелә, VI класста бер сәгать әдәбият, ягъни уку дәресе буларак кына керә икән (әлеге сыйныфтагы унике укучының сигезе катнаш һәм урыс гаиләсеннән, дип аңлаттылар – Р.М.). Башка сыйныфларда татар телен атнасына 0,5 сәгать, ягъни бер атнада әдәбият, бер атнада татар теле укыталар. XI сыйныфта бер сәгать әдәбият дәресе керә.

Ханнынъ аякъчылары софраны джыйыштырмагъа кирдилер, корьселер – оларгъа бир кесечик биле эт къалмагъан, бир къашыкъ шорба къалмагъан. Аяткъа чыкъкъан сонъ: Яндыгъымы папазы! Бир кесек эт биле къалдырмагъан!» Къарт оларнынъ сёгюнгенини ешитти, сомурданып сёйленди:

Тавда джурген борю эдим,
Талчыгъыма тайлы бие ер эдим.
Ойгъа тюштим, къой болдым,
Къонкъулдашкъан коп ямангъа хор болдым, –

деди. Сонъ Нураддин ялакъчыларыны чагъырып сорады: «– Ашадымы къарт?» Ялакъчылар: «– Ашады. Бир къойны бир шей демей, ашады!» – дедилер. Нураддин сонъ анълады ки, бу онынъ бабасы экен. Кирди одагъа, бабасынынъ къолун-аягъын опти, афу сорады. Баба огълунынъ сучуны кечирди, афу этти. Шай етип, Нураддин хан бабасы Эдигени озь янына алды, раат этти.

Токътамышнынъ бикеси бир заманлар юклю къалгъан эди. Шимди о бир эр бала тапты, адыны Къадырберди султан къойдылар. Заман кечти, Къадырберди султан он секиз яшына кельди. Сонъ, башкъа ханлар онъа ярдым этти, аскер бердилер. Сонъ, баба улусындан адам топлады. Шай этип, аскери чокъ олды. Сонъ, баба тахтыны къыдырып, Чегерли гольге келип токътады.

Шу куньлерде, Нураддин Джанбайгъа эмир этти: «– Бар, Чегерли гольни къара – къуш бар экенми?» – деди. Джанбай атына минди кетти. Кельди Чегерли гольге, чыкъты секенинъ тёпесине, къарады. Корьди ки, Чегерли гольде чадырлар бар, чокъ аскер тура. Секеден ашагъы тюшедджекте аскерлер Джанбайны тутты, Къадырберди султангъа кетирдилер. Къадырберди султан сорады: «– Къана меним юртум? Къайда меним алтыным, малым? Къана меним Ханике, Джанике татайларым?» Джаны къыл устюнде олгъан Джанбай не айтсын: «– Юрт деген шей, гъайып болмай – бинъ йыл кечсе де тургъан еринде тура. Кобиси юртнынъ даваджысы гъайып олып кете. Айса, сен баба юртунъны дава этип кельдинъ – яхшы эттинъ. Мен сагъа Нураддинни алып келейим – малынъ,

алтынынъ ондан сора. Чегерли гольде къуш коп десем, Нураддин келир. Сиз азыр турынъыз, хан азретлери!» – деди.

Сонъ Джанбай кельди Нураддинге: «– Хан азретлери! Бир къуш бар! Бир къуш кельген Чегерли гольге – корьсенъиз акъылынъыз учар! Саны бар – сонъу ёкъ!» – деди. «– Айса, атлан, кетейик! Бир лячин учурайыкъ!» – деп къуванды Нураддин. Сонъ, Нураддин яхшы бир джюйрек сайлап минди. Джанбай да чарпыкъ ат минди. Атмаджа (авджы) къушларны алып, Чегерли гольге кельдилер. Джанбай Нураддинге: «– Султаным! Сагъа бу къушны ат чаптырып насыл учурылгъаныны корьсетир эдим, амма, атым мартавал. Сенинъ атынъа минейим де, къушны бир учурайым – сен онынъ учушыны сейир эт!» – деди. Нураддин разы олды. Сонъ Джанбай Нураддиннинъ джуйрюгине, Нураддин де Джанбайнынъ чарпыкъ атына миндилер. Джанбай аткъа мингенинен атмаджа къушны алды, синъди кетти секе артында. Нураддин не олгъаныны анъламады: «– Бу бадракъкъа (батрак) не мараз олды? Чыкъайым секенинъ тёпесине, къарайым»,– деди озю-озюне. Чыкъты секенинъ тёпесине – корьди ки, секенинъ о тарафы аскер толу. Шай дегендже, оны эки якътан аскерлер къамачавгъа алды. Нураддиннинъ джарты аты чапып олмады. Оны аттан тюшюрип, эки къолундан эки аскер тутып Къадырберди султаннынъ чадырына алып кельдилер. Къадырберди султан Нураддинге ер косьтерди, «отур» деп ишмар этти. Къызыл къадифе тёшельген бир шиндикни (кресло) корьсетти. Нураддин отурды. Амма шимди астындан къадифе тюбюне эки зеэрли пычакъ тиклетип салынгъан экен. Нураддин отургъанда эки пычакъ эки тизини тешип уджлары тёпеге чыкъты. Нураддин эки къолуман эки пычакънынъ уджларыны къапатып отурды. Къадырберди султан сорады:

Аргъавулдан кочькен алты арбам
Алтавы да къазна арбам
Тугъра-тамгъалы асыл арбам –
Оны къаттинъ, Нураддин?

Нураддин айтты:

Аргъавулдан кочькен алты арбанъ
Алтавы да къазна арбанъ –
Танъры магъа болсын деп бергенде,
Мен оны бутюнлей сайгъанман.
Улуснынъ къувети алтын! деп,
Акъ Субан батырны къазнаджы къойгъанман.

Къадырберди султан сорады:

Босагъасы юксек боз уюм,
Алтмыш алты козь уюм
Къышлав уюм, яз уюм –
Оны къаттинъ, Нураддин?

Нураддин айтты:

Босагъасы юксек боз уюнъ
Алтмыш алты козь уюнъ –
Мен оны ёкъ корьгенмен:
Эриккеним кетсин деп.
Мугъайгъаным къалсын деп,
Орьтмен откъа бергенмен.

Къадырберди султан сорады:

Секиз ерден чегели
Токъуз ерден тогъалы
Юзю къызыл чугъалы
Тонымны къаттинъ, Нураддин?

Нураддин айтты:

Секиз ерден чегели
Токъуз ерден тогъалы
Тонынъ магъа къалгъанда –
Мен оны авур тапкъанман:
– Бу къызыл тон сагъа! – деп
Бабамнынъ сыртына арткъанман.

Къадырберди султан сорады:

Толгъамалы меним ай балтам
Кумюш саплы сай балтам[1],
Ханике, Джанике джан тотам –
Оларны къаттинъ, Нураддин?

Нураддин айтты:

Толгъамалы сенинъ ай балтанъ
Чынгъыздан къалгъан сай балтанъ –
Айланышкъан урушта,
Толгъанышкъан токъушта
Онъ къолума алгъанман.
Ханикедай ёсманы
Джаникедай сылувны
Танъры озю манъа бергенде –
Бедава мал къылгъанман.

Къадырберди султан сорады:

Аягъы терек, мойны эрек
Атымны къаттинъ, Нураддин?
Юртнынъ ханы, бабасы –
Атамны къаттинъ, Нураддин?

---

[1] Сай балтам – сайланып алынгъан, сойдан къалгъан.

Нураддин айтты:

Аягъы терек, мойны эрек
Атынъны тутып мингенмен,
Бизни юрттан къувгъанчюн
Атанъа терс дёнгенмен.
Татар къыйыры Тунада
Токътамышдай атанъны
Сакъалындан туткъанман.
Боз бугъадай окюртип
Еди тавны янъгъыртып –
Башыны кесип алгъанман.
Къара мешинге саргъанман.
Эр башы къокъланыр деп –
Чильтер дорбагъа къойгъанман.
Чильтер дорбаны кетирип –
Бабамнынъ алдына салгъанман.
Очь-ачувын къандырып –
Бабамнынъ алгъышын алгъанман!

Онда Джанбай тильге кельди: «– Къадырберди султан! Изин этинъиз – меним де булардан сорайджакъ эсабым бар»,– деди. Къадырберди разы олып баш саллады, сонъ Джанбай Нураддинге сёз къатты:

Беш-беш оба, беш оба
Бельги тиктинъ, Нураддин.
Салыкъ салып коп халкъны
Урып сёктинъ, Нураддин.
Беш биеден бир къулун
Сен тилединъ, Нураддин.
Чынгъыз тахтынъ огъурлап
Къа, нейлединъ, Нураддин!
Тюштинъ къара тулпардан
Малиймен насыл кетерсинъ?
Шимди эсап сорайлар –
Эсапны насыл этерсинъ?

Онда Нураддин айтты:

Беш-беш оба, беш оба
Бельги тиксем – юрт ичюн.
Юрт сынъырын атлагъан
Къыбла билен сырт ичюн.
Беш биеден бир къулун

Мен истесем – сют ичюн.
Къалан, салыкъ кестирсем –
Сендай арсыз бет ичюн!
Кемал улы кок Джанбай,
Кери сёзлю ит Джанбай.
Озь эткенинъ ойлачы,
Тилинъни тыйып сёйлечи!
Тилинъни пычакъ сырты билен кесермен
Танълайынъа нал къыздырып басарман!
Эки джагъынъ эки якькъа айырып
Шорбалыгъынъ (агъзынъ) джыртарман!

Сонъ Къадырберди султан еринден турды да, сёйледи: «– Джигит экенсинъ, Нураддин султан, аферим сагъа! Мен бабамны бешбаш эткенинъе бек окюне эдим. Шимди корьдим ки, оны джигит киши енъген экен. Айса, окюнчим кетти, сагъа да биз языкъ эттик. Сенмен менде суч ёкъ – сучман къавгъа бабаларымыз арасында. Беринъиз Нураддин султаннынъ тулпарыны – кетеджек ёлуна джигитчесине ат минип кетсин!» – деди. Сонъ нукерлер Нураддинге онынъ къара тулпарыны кетирдилер, атланмагъа ярдым эттилер. Нураддин атланды кетти. Бир даа корьсе – бабасы Эдиге бир ат минген, къолунда дал къылыч – келеятыр Эдиге корьди – огълу Нураддин ат устюнде саллана, эки тизинден къан акъа–сыза келеятыр. Онда Эдиге айтты: «– Вай, улым! Шу къадарлыкъ эдими алынъ?» – деди. Сонъ, о ат салып барды, тюшти Къадырберди султаннынъ аскери арасына – онъуна солуна къылыч саллады. Бир къач аскерни кести, яралады. Сонъ такъаты битти къарт кишининъ – айландырды атыны, къачты. Къадырберди султан артындан къувды. Эдиге бир койге далды, эвлер арасына синъди. Сонъ тюшти аттан, кирди бир эвге. Къадырберди султан да къолда къылыч – далды шу эвге онынъ артындан: «– Папазнынъ башыны озь къолумман кесейим!» – деди. Эдиге исе, къамасыны алып, къапы артында беклеп турды. Къадырберди кирип, оны корьгендже, Эдиге бас этти къаманы онынъ къурсагъына – ичеклерини эшти. Къадырберди йыкъылды. Эдиге атылды тышары, минди атына – къачты.

Энди Токътамышнынъ, Къадриберди султаннынъ айтувлы мырзалары етишип кельдилер – корьдилер ки, Къадырберди султан, олеята. Къадырберди оларгъа яткъан еринде сёйледи: «– Магъа ким Эдигенинъ башыны алып кельсе, къан къарышкъысы онынъкидир!» – деди. Мырзалар ат салып, Эдигени къувып кеттилер. Кете-кете корьдилер: Эдигенинъ атынынъ излери Чегерли гольде къамыш ичинде биткен. Къамышкъа кирген ат излери ёкъ, амма чыкъкъан ат излери бар. Мырзалар: «– Бу насыл бола?» – деп къарап къалдылар. Сонъ Джанбай: «– Бу Эдиге бек

тильки адамдыр – бу да онынъ мерафетлеринден биридир. Мен беллесем, о атыны къамыш ичине арт-арткъа берип кирсеткендир. Сиз Барын мырза, Шырын мырза, азыр турынъыз! Мен Эдигени бир толгъайым (чынъман сырын ачайым). Эгер Эдиге къамыш ичинде болса, о мытлакъ сесленир»,– деди. Джанбай толгъады:

Озюнъден артыкъ джав корсенъ:
– Тур, атайым,– дер эдинъ.
Озюнъден эксик джав корьсенъ:
– Ат, турайым! – дер эдинъ.
Эр Эдиге даа савмы?
Бар болсанъ чыкъ, къарайым!
– Ат! – десенъ мен атайым.
– Тур! – десенъ мен турайым.

Онда къамыш ичинден Эдиге сесленди:

Токътамышны ольдирдим,
Огълунынъ чырагъын сёндирдим.
Очюм, ачувым къандырдым –
Энди къалгъанындан ким къоркъа!

Шай деп, ат чаптырып, къылыч ойнатып къамышлыкъ ичинден чыкъты, мырзалар онъа уджюм эттилер. Барын мырза Эдигенинъ башыны къылычнен кести. Башы тыгъырып тюшти ерге, къаталап кетти. Амма Эдигенинъ башы:

Барын, сагъа мен неттим?
Сизчюн девлет, юрт куттюм.
Биринъ эки болмасын!
Юртынъ, къаранъ къалмасын!
Ханлар ханын мен йыкътым,
Хан болып сен де къалмазсынъ!
Сют ерине къан тёктинъ,
Къанымны тёгип не эттинъ!
Къазан, Кърым, Аждархан (Астрахань)
Союмны сорап къалгъанда,
Не болгъанын анда корерсинъ! – деп къаргъады.

Барын мырза алды Эдигенинъ башыны – Къадырберди султандан онынъ къан къарышкъысыны аладжакъ. Шырын мырза онъа: «– Бер, Эдигенинъ башын мен тутайым, сен устюнъин къандан арындыр!» – деди. Барын мырза берди Эдигенинъ башын Шырын мырзагъа. Шырын мырза Эдигенинъ башын къолуна алгъанынен тутты къачты. Кетирип Эдигенинъ башыны Къадырберди султаннынъ алдына салды. Къан къарыш-

къысы Шырынгъа болды. Шырын мырза укюмдар болды. Барын мырза эди – мырза олып да къалды. Тап сонъу, Барын мырза айтты:

Ольди, битти Эдиге –
Мерафети битмеди.
Къарышкъысы Шырыннынъ –
Барынгъа къысмет этмеди.

* * *

Идиль юрты деврильди,
Яв устюне яв кельди.
Эдиге айткъан кунь кельди,
Чынгъызнынъ къойгъан хан дагъы
Хан дагъына айланды.
Алтын Орду таркъады,
Хан сарайы къалмады.
Къырым, Къазан, Аждархан
Айры-айры иль болды.

## Айры сёзлерге анълатув

**Адув** – душман.

**Аймакъ** – къабиле.

**Аталыкъ** – хан огълунынъ тербиеджиси: ханнынъ ярдымджысы, кенъешчиси.

**Бал, балбоза** – балдан япылгъан эсирткили ичимлик.

**Беринди** – бир де – бир укюмдаргъа бойсунгъан киши (подданный).

**Бешбаш** – аз къувет иле япылгъан чапул, чапкъынлыкъ (набег малыми силами).

**Быдаякъ** – байкъуш союндан бир къуш (ястребная сова).

**Джанбай** – Токътамыш ханнынъ везири.

**Зырых** – кольчуга, латы, панцирь.

**Йырты** – добыча.

**Кер бие** – ачыкъ къаверенки тюсте (каурая) байтал.

**Къазакъ** – озь эркине чёльде яшагъан адам.

**Къанджугъа** – эгер артына бир шей багъламакъ ичюн махсус пекительген сыджымлар (торока).

**Къутлукъая** – Токътамыш ханнынъ къушчысы, мангъыт урувындан олгъан.

**Мадай** – авам халкътан олгъан киши (простолюдин).

**Нукер** – ханны къоруджы аскерлер (ханская гвардия).

**Савру** – атнынъ арт аякъларынынъ тёпеси, (круп).

**Салар** – атнынъ аркъасында алд аякъларынынъ тёпеси, курегининъ устю.

**Самур** – соболь.

**Сулув** – гузель, дюльбер.

**Тёре** – чыкъарылгъан къарар, къанун; ханлар яки юкъары табакъаларгъа менсюп (человек из знати).

**Токътамыш** – 1380-нджи йылдан башлап акимлик эткен Алтын Орду ханы, Джучы хан несилининъ девамджысы.

**Чынгъыз** – Чынгъызхан (1155–1227). О 1206-нджы йылдан Монгъол империясынынъ ханы олгъан. Асиягъа, Шаркъий Авропагъа арбий сеферлер япкъан, чокъ ерлерни запт эткен.

**Шункъар** – чокъусы «сунгъур» деп адлангъан къуш (кречет).

*Чыганак: [Къырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгъы. Хрестоматия. Тертип этиджи Дж. Бекиров. – Ташкент: «Ўқитувчи», 1991. – 248 б.].*

*Фидаил Мәҗитов*
*Салауат Хөсәенов*

# БИКЛӘН АВЫЛЫ ТАРИХЫ ДОКУМЕНТЛАРДА ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАРДА

Чулман елгасының сулъяк ярында, Бикләнелгасы һәм аның кушылдыгы Камышлы янында урнашкан Бикләнавылы хәзерге вакытта Татарстанның Тукай районына керә.

Борынгы заманнарда әлеге уңдырышлы җирләрнең хуҗалары кемнәр булганлыгы хакында бәян итүче язма чыганаклар 1528 елга карый. Алат юлы Мәңгәр авылының йомышлы татарлары һәм Түбән Кама җирләрен актив колонизацияләүче Алабуга Троицк монастыре арасындагы низагны чагылдыручы ике гавами-хокукый документ Россия борынгы актлар дәүләт архивының икътисад коллегиясе грамоталары фондында саклана. [Мустафина: 2016. №6. С. 233–264.].

Әлеге документлардан күренгәнчә, низагны хәл итү вакытында, ягъни 1676 елның 3 декабрендә, Мәңгәр авылыннан Әлмөхәммәт Янбакты улы Исламов һәм аның иптәшләре, башка документлар белән беррәттән, татарчадан тәрҗемә ителгән милек рәсмиләштерү кәгазен дә теркәүне сорыйлар. Документта 1528 елның 16 сентябрендә (һиҗри буенча 935 ел) Бүләк (Булгак) Сәет-Әхмәт улының үзенең Зәй, Омшы, Курча, Сусар елгалары буендагы җирләрен Әлхуҗа Касыймовка сатып биргәнлеге раслана. Сатылган җир биләмәләренә Чулман елгасының сулъяк яры, Камышлы, Бәтке, Прости, Омшы, Аулаш, Сусар инеше буйлары керә (якынча хәзерге Чаллы шәһәре читеннән башлап, Түбән Кама шәһәренә кадәрге җирләр).

Бүләк Сәет-Әхмәт улына тархан ярлыгы 1521–1524 елларда Казан ханлыгы тәхетендә утырган Сәхип Гәрәй хан тарафыннан тапшырылган. Искәртеп узыйк, ярлык 1912 елда галим Сәет Вахиди тарафыннан Мамадыш ягындагы Мамалай авылында яшәүче крестьян Рәхмәтулла Әхмәревтә табыла. Ярлык 1523 елда җиде кешегә, шул исәптән Сәет-Әхмәткә, аның туганы Мөхәммәт Муса улына, уллары Якуп, Бүләк һәм Нур-Сәеткә бирелә [Вестник научного общества татароведения: 1925. №1–2. С. 33–34.].

1602–1603 елларда Иван Болтин җитәкчелегендә төзелгән Казан өязендәге җир биләмәләрен теркәү кенәгәсеннән («Писцовая книга Казанского уезда 1603–1605 годов») күренгәнчә, Мәңгәр авылының йомышлы татарлары Исламовлар үз авылларында гомер итә һәм Чулманның сулъяк ярындагы биләмәләрен умарталык һәм аучылык өчен файдалана.

1632–1633 елларда Шайтан шәһәрчегендә урнашкан монастырь җитәкчелеге, бу җирләрне файдаланылмаучы җирләр буларак күрсәтеп, монастырь карамагына тапшыруларын сорап хөкүмәткә мөрәҗәгать итә һәм воевода И.В. Морозовтан рәсми документ алуга ирешә.

Үзләрен бу җирләрне 1528 елда ук сатып алган Әлхуҗа Касыймовның нәсел дәвамчылары дип тәкрарлаучы йомышлы татар катламындагы Исламовлар, әлеге хәл белән килешә алмыйча, шактый еллар узгач, ягъни 1673 елда монастырьга дәгъва белдерәләр. Шул 1528 елгы документка нигезләнеп, алар хәтта үз хокукларын кайтаруга ирешәләр. Әмма 1690 елда монастырьның яңа башлыгы, йомышлы татарларның җир документларын тутыруда булган хаталарны үз файдасына борып, әлеге җирләргә ия икәнлекләрен раслап, йомышлы татарларның ата-бабаларына 1597, 1605, 1621 елларда тапшырылган документлар булуга карамастан, 2200 гектар җирне монастырь карамагына тартып алуга ирешә. Ул җирләрдә Бәтке һәм башка рус авыллары барлыкка килә.



Сәхип Гәрәй хан ярлыгы. 1523 ел.

Бу җирләргә каршы якта, Чулманның уңъяк ярында, Тана инеше буенда, Сарайлы авылы һәм Алабуга саласы буйларында бер төркем татарлар яши. Нәкъ менә аларның бабалары сулъяк ярдагыларга үз биләмәләрен саткан булса кирәк. 1619 елда Тана елгасы тамагындагы Сарайлы авылында Бисәр Кагтов һәм Тана авылында Яндигиз (Җәнҗегет?) һәм аның иптәшләре гомер итә [Шишкин: 2014. С. 45–47.].

Казан өязе буенча 1647–1656 елларда төзелгән җир биләмәләрен теркәү кенәгәсендә дә, Тананың ясаклы татар авылы икәнлеге күренә: «Того ж [Троецкого]

монастыря в сельце, что была деревня Таны, пашни и розчистеи семь длинников, // (л. 275 об.) семь поперечников, в другом конце дватцать поперечников, а вровно тринатцать поперечников с полупоперечником, итого девяносто четыре десятины с полудесятиною в поле, а в дву по тому ж. И в том числе два поля в споре с ясачными татары деревни Таны Беличик, Березник то ж. (Л. 276)» [Писцовая книга Казанского уезда: 2001].

Әлеге кенәгәдә Тана авылы янындагы җирләрнең Ишмөхәммәт морза Багыш кенәз улы Яушев һәм аның туганының улы Кадермөхәммәт морза Дусмөхәммәт улы Яушев кулы астында булуы искәртелә: «Да за рекою Тоймою два островка невеликих: один верхней, а другой середнеи. А на них сенных покосов нет, поросли лесом тальником, а выгон на них животиннои. // (Л. 281) Троецкого монастыря каменного городища, что на Елабуге, сенных покосов в лугу по одной стороне волошки Кривуши и меж гор и монастырские деревни Таны мерою в длину тритцать пять длинников, шестьдесят пять поперечников, итого две тысечи двесте семьдесят пять десятин. А на них сена ставитца сорок пять тысеч пятьсот копен. В другом месте того ж лугу в луке меж волошки Кривуши мерою пять длинников с полудлинником, пятнатцать поперечников, // (Л. 281 об.) итого восемьдесят две десятины с полудесятиною, сена ставитца тысеча шестьсот пять копен; опричь того, что в той ж луке отведено татаром ясачной деревни Таны Белекчи, Белек то ж, мерою пятнатцать длинников с полудлинником, пятнатцать поперечников, итого двесте тритцать две десятины с полудесятиною, сена ставитца четыре тысечи шестьсот пятьдесят копен. По другой стороне волошки Кривуши до дубников мерою дватцать один длинник, дватцать два поперечника, итого четыреста шестьдесят две // (Л. 282) десятины, сена ставитца девять тысеч двесте сорок копен. В другом месте от волошки Кривуши подле Камы реки вниз мерою пятьдесят два длинника с полудлинником, тритцать два поперечника, итого тысеча шестьсот девяносто десятин, сена ставитца тритцать три тысечи восмесот копен. И обоего по другой стороне волошки сенных покосов сорок три тысечи сорок копен. И всего за Троецким монастырем каменново // (Л. 282 об.) городища в большом лугу и по волошке Кривуше, по обе стороны той волошки по мере четыре тысечи пятьсот деветь десятин с полудесятиною, сенных покосов ставитца девяносто тысеч сто девяносто копен, опричь того, что отведено татаром ясачные деревни Белекчи, Березник Тана то ж, сенных покосов четыре тысечи шестьсот пятьдесят копен. // (Л. 283) за Ишмамет мурзою князь Багишевым сыном Яушева да за племянником ево за Кадраметем мурзою Досмаметева сына Яушева ж.» [Шунда ук].

**Казан өязе буенча 1678 елда уздырылган җанисәп кенәгәсенә** «починок на Березниках на Дичи а Тана тож» дип теркәлгән авыл Казан өязе Арча юлына карый. [РГАДА. Ф. 1209. Оп. 1. Д. 6453. Л. 589–592].



1678 елгы җанисәп кенәгәсенең бер бите.

***Биклән авылы нигезләнү турында тәүге язма чыганаклар***

Риваятьләрдән күренгәнчә, Биклән авылын Чулман аръягыннан, Алабуга ягыннан килгән кешеләр нигезли. Бу хакта шулай ук төбәк тарихы белән кызыксынган авыл аксакаллары да теркәп калдыра. Хәсән Галиуллинның 1966 елгы кулъязмасында: «<...> Кайбер картларның әйтүенә караганда, беренче мәртәбә Байчура исемле кеше килеп утырган. Шуңа күрә [авылны] Бичурин (Байчуриннан бозып үзгәртелгән) дип йөрткәннәр. Кайберәүләрнең: «Биклән авылын хәзерге Бәтке авылы урынына, Идел буена утырта башлаган да, суга төшеп үлүдән куркып анда утырмаганнар»,– дигән сүзләре бар». [Галиуллин, Вәлиев: 2007. 7–8 б.].

Шәех Абдуллин язмаларында исә авылны нигезләүчеләрнең исемнәре санап үтелә: «500 еллар элек, хәзерге Алабуга (ул заманнарда – Сөзем) тирәсендәге елга буйларында, үзәнлекләрдә, калын зур урманнар эчендәге аланнарда, ачык территорияләрдә (нигездә терлекчелек белән) балык тоту һәм ауга йөрү өчен уңай табигать шартларында яшәүче Бигелде, Бикчәнтәй, Бикчура, Урманай, Сарманай (*кайбер чыганакларда Маҗай исеме дә күрсәтелә – авт.*) кебек төркем башлыклары – кул астындагы борынгы бабаларыбыз – Чулман (Кама) елгасын үтеп чыгалар, калын урманнар белән капланган хәзерге Бәтке авылы җирлекләренә күчеп

киләләр һәм ярыйсы гына тормыш, көнкүреш алып баралар» [Абдуллин: 2016. №10 (5829)].

Шәүкәт Ханнан улы Йосыпов (1929 елда туган) сөйләгән сүзләр дә югарыдагы фикерләргә аваздаш: «Бабам Бикләнгә нигез салучылар нәселеннән булган. Петр I заманында, чукындырудан куркып, бик күп татарлар, Казан якларыннан бу төбәккә качкан. Борынгы бабалары, җәмгысе ун гаилә, иң башта хәзерге Бәтке җиренә килеп урнаша. Ләкин 1650 еллар тирәсендә аларны тәүге нигезләреннән урыслар куып җибәрә. Бәтке урыс авылына әверелә. Бәткедән куылган 4 татар хуҗалыгы бүгенге Біклән авылына нигез сала» [Фәләх: 2008. №2. Б. 127].

Бу урында шуны искәртеп узу мәслихәт, рус чыганакларыннан Бәтке нығытмасының күпкә иртәрәк, Явыз Иван чорында ук элеккеге татар авылы урынында төзелгәнлеге аңлашыла: «Многие из Государевых сел, вновь устроенных в пределах бывшего Казанского царства, были огорожены стеной с башнями и выкопанным рвом и валом, так мы знаем, что находящееся против Трехсвятского-Елабуги на другом берегу Камы село Бетьки имело крепость, которая, как и все подобные крепости носили название «острога», и было огорожено стеной и башнями. <...> [В 1617 г.] в Бетьковском остроге было 4 башни, а пятая развалилась, из этого видно, что крепость в Бетьках была старая, надо думать, что Бетькинский острог был устроен после покорения Казани вскоре» [Шишкин: 2014. С. 47–50]. Тагын шуны ассызыклап үтү мөһим: кайберәүләр «Биклән» атамасын чукындырудан качып киткән, каядыр урманга барып яшеренгән татарларның, имештер, үзләрен «бикләнгән кешеләр» дип атавыннан барлыкка килгән, дип фаразлый. Ә бит югарыдагы язмадан чыгып, борынгырак чорлардан алып фикер йөртсәк, баскынчылар үзләре татар авылы урынына килеп утырып, нығытма төзеп, шунда кереп бикләнгәннәр («<...> *от нападения татар, башкир и других инородцев*») [Шунда ук]. Ягъни кайчандыр татарлар яшәгән җир нығытма уртасында калган, бикләнгән...

«Биклән» атамасы очраган тәүге документ 1626 елга карый. Чаллы җирләренә рус крестьяннары күчереп утыртылу хакындагы әлеге документта Биклән елгасы турында әйтелә: «<...> велено новым крестьянам елабужанам Федьке Некантьеву сыну Попову с товарищи жити во крестьянах в Уфимском уезде на пашне на льготе на Чалне, на Мелекесе речке подле Камы реки на Уфимской стороне, с верхнею сторону пришла Шильна речка, а с нижнюю сторону подошла Бекляна речка, промеж тех речек с устья и до вершин» [РГАДА. Ф. 1209. Оп. 1. Д. 156. Лл.153–153 об.]. Биклән елгасы шулай ук 1629, 1643, 1649 елларга караган документларда да телгә алына [РГАДА. Ф. 1173. Оп. 1. Д. 136. Лл.10–11; Ф. 1173. Оп. 1. Д. 140. Лл.1–9].

М.С. Супоневның 1678 елда уздырган җанисәп кенәгәсендә авылның берничә атамасы теркәлгән: Сарысаз, Күкхуҗа кыры, Биклән (Сарысаз Коккозина Пустошь Беклян тож). Авыл Казан өязе Арча даругасының Чулман аръягындагы Килдебәк Башаев йөзлегенә карый. Биредә 19 хуҗалыкта 51 ир-ат исәпләнә, шуларның 27се ир балалар һәм яшүсмерләр була. Риваятьләрдә һәм совет чоры кулъязмаларында телгә алынган Бигелде, Бикчәнтәй, Бикчура, Урманай, Сарманай исемнәренә тәңгәл килгән яки охшаш исемнәр ясак кенәгәләрендә дә бар. Аларның берничәсе исем буларак сакланган, күбесеннән фамилияләр формалашкан, дип фаразларга мөмкин. Аларның русча вариантлары мондый: Бигильдин, Бегишев, Бекчюрка Козенбаев (Бикчура һәм Бикчәнтәй исемнәренең асылы охшаш, икенчесе беренчесенең кечерәйтү-иркәләү төсмере булуы ихтимал), Урматка, Сарбаев. Җанисәп кенәгәсеннән караганда, анда теркәлгән шәхесләрнең алдагы буыны 1650 елларда Бикләндә яшәгәнлеге аңлашыла. Алар, чыннан да, авылны нигезләүче булган һәм «Алабуга ягыннан» килгән, дигән нәтиҗә ясый алабыз. Чөнки ясак кенәгәләрендәге мәгълүматлар авыл кешеләре ясакны югарыда телгә алынган Тана авылындагы («в деревне Берзник на Дичи а Тана тож») биләмәләре өчен түләгәнлеген искәртә.

Биклән авылының борынгы атамасы кайчандыр бу җирләргә Күкхуҗа исемле кеше хуҗа булганлыгы һәм хәтта үзе анда яшәгәнлеге турында сөйли. Күп кенә документларда авыл «Бечурино» дип тә теркәлгән. Безнең фикеребезчә, торак пунктның шулай аталып йөртелә башлавы аны нигезләүчеләрнең берсе булган Бикчура Хуҗабаевка (Бекчюрка Козенбаев) нисбәтле. Аңлашыла ки, Бикчураның атасы Хуҗабайны халык телендә Күкхуҗа дип йөрткәннәр булса кирәк.

Шулай итеп, архив документларыннан Биклән авылы 1650 елларда Чулман елгасының уңъяк ярыннан, ягъни Танай, Туйма, Юраш (Ибраш) елгасы буйларыннан баскынчылар кысрыклавы аркасында күчеп утырган татарлар тарафыннан нигезләнгәнлеге аңлашыла. Якын-тирәдә исә Мортыш (Бикчура), Түбән Мәләкәс (Сүнчәләй), Мәләкәс елгасы буендагы Сөендек, Бадрак, Айкилде исемле авыллар урнашкан була.

***Биклән авылының зураюы һәм баскынчылар тарафыннан кысрыклануы***

Хөкүмәт алып барган христианлаштыру сәясәте аркасында, төбәктә чукындырылган авыллар саны арта бара. Әле 1678 елда гына да шактый ныклы булып күренгән Биклән авылы 1710 елда бушап кала. 1716 елгы халык исәбендә Мәләкәс авылында Бикләннән күчеп килгән 2 хуҗалык теркәлә. Җанисәп кәгазендә күчену сәбәбе «пуста от башкирского разорения» дип аңлатыла. Күченүчеләр үзләренең төрле авылларда булула-

рын, 1714 елдан Мәләкәстә төпләнеп калуларын әйтә [РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Д. 146. Лл. 1457–1458 об.].

1722 елда уздырылган беренче ревизия вакытында Казан өязе Арча юлы Габдерәззак Калдыбәк улы (Бура-Киртәдән) йөзлегенә караган Биклән (Сарысаз) авылында янә әйләнеп кайткан 14 хуҗалыкта 105 ир-ат исәпләнә. Уфа өязенә күчеп киткән 75 ир-ат, полковник Головкин экспедициясе тырышлыгы белән, мәҗбүри рәвештә кире кайтартыла. (Аңлашыла ки, алар үзләрен «талаган» халык янына барып сыенмас иде. Алдагы сан алу вакытында татарлар үз авыллары «башкортлар талавыннан соң бушап калды» дигән сүзне хөкүмәт җәзасыннан котылу өчен уйлап тапканмы, әллә инде хөкүмәт үзе шундый астыртын адымга барганмы – фаразларга гына кала.) Аларның җир биләмәләре Биклән елгасының уң ягында урнаша: «<...> от вершины до устья, сенные покосы в тысячу копен, черного лесу размером 5×3 версты совместно с окольными деревнями» [РГАДА. Ф. 350. Оп. 1 Д. 1119. Лл. 185–187 об.]. Бу вакытта староста вазифасын 1716 елда Мәләкәстә исәпкә алынган Бимәт Бигенеев башкара. Ул – Бикчура Хуҗамәт улының нәсел дәвамчысы. Мөгаен, авылның икенче атамасы шушы шәхескә нисбәтледер.

Россия борынгы актлар дәүләт архивының Минзәлә воеводалыгы канцеляриясе фондында Биклән авылына караган берничә документ саклан-ган. Әлеге фондтагы документлар, нигездә, төрле низагларны хәл итү, җинаятьләрне фаш итү процессы вакытында тупланган. Алар авылның иҗтимагый, дини-әхлакый тормышы хакында шактый мәгълүмат бирә.

Биклән авылы күбесенчә якын-тирәдә урнашкан рус яки керәшен авылларыннан матди зыян күрә. Мәсәлән, 1739 елда Чаллы крестьяны Александр Трофимов Биклән татары Туктагуловның сыерларын урлый. [РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 239]. 1755 елда Биклән татары Бишаевның умарта күчен Яңа Мәлкән иске керәшеннәре Ивановлар тотып яба [РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 1471]. Шушы эшне ачыклау өчен генә дә 15 бит кәгазь сарыф ителә. 1756 елда Биклән татары Камаевның атларын Пәнәче авылының иске керәшене Кузьмин урлый [РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 1539]. Бу эшне ачыклауга 20 бит кәгазь тотыла.

Бикләнлеләр милләттәшләренең хилаф гамәлләренә дә дучар ителә. Мәсәлән, 1745 елда Түбән Мәләкәстән Арсланов Биклән татары Уразаевның ике атын урлый [РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 674]. Шулай ук авылның үзеннән дә кайбер кыңгыр эшләрдә катнашучылар ачыклана. 1737 елда Кадыйров авылдашы Дүсмәтовны [РГАДА. Ф. 529. Оп.. Д. 210], ә 1755 елда Аблаев авылдашы Аитовны кыйнаганы [РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 1466], 1755 елда Тетаров авылдашы Мөкәевнең сыерын суйганы өчен [РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 1474] җавапка тартылалар. 1745 елда Биклән

татары Сермяков Дусайкичү авылы татары Бикчуринның атын тартып алуда гаепләнә [РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 588].

Башкортостан Республикасы Милли архивында саклануючы документлар арасыннан Биклән авылының 1849–1890 елларга караган метрика кенәгәләрен, 1795, 1811, 1816, 1834, 1859 елгы ревизия сказкаларын эзләп табу насыйп булды. Авылдагы дини тормышны күзалларга ярдәм итәрдәй документлар да шактый. Мәсәлән, мәчеттә кайсы елларда кемнәр муллалык иткәнлеген өлешчә шул документлар аша да ачыклый алабыз.

1862 елда Биклән авылының башкорт катламындагы указлы мулласы Вәлиәхмәт Фазлыйәхмәтев, шушы ук авылның дәүләт крестьяны катламындагы указлы яшь мулласы Гатаулла Әлмөхәммәтовның (Боһармәтовның) никах теркәү кәгазьләрен метрикага күчереп язганда үз имзасын куймыйча калдыруына борчылып, Диния нәзарәтенә хат яза [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 4. Д. 4433]. Өлкән мулла яшь мулланың хаталы адымнарын алга таба да фаш итәргә тырыша. Мәсәлән, 1864 елда Биклән крестьяны Вәли-Әбүхәмит Биктаһиров үзләренең туачак балаларын мулла Вәлиәхмәт Фазлыйәхмәтев никахсыз туучылар дәфтәренә теркәргә җыенуына каршы шикаять белдерә. Яшь парга никахны яшь мулла Гатаулла Боһармәтев укыган була. Ә өлкән мулла Вәлиәхмәт, никахлашу вакытында кәләш Бибихәмидәгә нибары 16 яшь кенә булу сәбәпле, никахны канунсыз дип таба [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 5875]. 1863 елда 62 мәхәллә әһеле (мәхәллә барлыгы ике имамнан һәм 500 кешедән тора) мулла Гатаулла Боһармәтевне, әхлаксыз гамәлләрдә гаепләп, вазифасыннан алуны сорый. Әмма аның 15 ел дәвамындагы дини эшчәнлеген бары тик уңай яктан бәяләүчеләр фикерен исәпкә алып, Диния нәзарәте кисәтү ясый һәм үз вазифасында калдыра. [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 5618].

1872 елда крестьян Галиулла Хәбибуллин Бикләннең яңартып төзелгән мәчетенә мөәззин итеп тәгаенләнә [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 4. Д. 9011]. 1881 елда «берничә дистә ел» элек төзелгән 1 нче җәмигъ мәчетне кичектермичә төзекләндерү кирәклеге хакында Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать юллана [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 10350]. 1886 елда башкорт катламындагы Әшрәфулла Галиуллин Бикләннең 2 нче җәмигъ мәчетенә имамлыкка указ ала [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 4. Д. 14913]. 1889 елда крестьян хатыны Бибилатыйфа Сәйфуллина яңа мәчет имамы Шаһиәхмәт Фазлыйәхмәтевкә карата, аны тәрбиясезлектә һәм ялганлашуда гаепләп, җитди шикаять белдерә. Ләкин бу эш Ш. Фазлыйәхмәтев файдасына тәмамлана [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 12298]. Мулланың үз вазифасында калганлыгы 1893 елның 16 августында Биклән авылында икенче мәхәллә мәчетен төзекләндерергә рөхсәт бирүче документтан күренә [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 13600].

1898 елның 27 февралендә Диния нәзарәте тарафыннан Бикләндә 3 нче җәмигъ мәчет төзү турында карар кабул ителә [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 15877]. 1901 елда башкорт катламында исәпләнүче Сәхәбетдин Гыймадетдин улы 3 нче җәмигъ мәчеткә имам-хатыйп итеп билгеләнә [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 589; Ф.И-295. Оп. 5. Д. 605]. 1909 елда 3 нче җәмигъ мәчет мөәззине итеп Бөгелмә өязе Кичүчат авылыннан Мөхәммәтнәҗип Фәсхетдинов раслана [РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 5778].

1909 елда Бикләннән Җиһанша Хәсәнша улы Сарманаев дини дәрәҗә алу өчен имтихан тапшыра [Ф.И-295. Оп. 5. Д. 7117].


ПОЛУЧЕНО
27 ФЕВ. 1902
13-1899 г.
№ 1789
Указъ ЕГО ИМПЕРАТОРСКАГО ВЕЛИЧЕСТВА, САМОДЕРЖЦА ВСЕРОССІЙСКАГО, изъ Уфимскаго Губернскаго Правленія Оренбургскому Магометанскому Духовному Собранію.

По Указу ЕГО ИМПЕРАТОРСКАГО ВЕЛИЧЕСТВА, Губернское Правленіе слушали: Докладъ по дѣлу о разрѣшеніи постройки 3ей новой соборной мечети въ дер. Биклянъ Сигуриной, Мензелинскаго уѣзда. Приказали: разсмотрѣвъ изложенное въ докладѣ, Губернское Правленіе опредѣляетъ: разрѣшить жителямъ дер. Биклянъ Сигуриной Мензелинскаго уѣзда, построить въ селеніи [illegible] новую соборную мечеть, по утвержденному чертежу и на избранномъ мѣстѣ, о чемъ и объявить имъ, съ выдачею чертежа, чрезъ Земскаго Начальника 4 участка Мензелинскаго уѣзда, съ тѣмъ, чтобы постройка мечети была произведена во всемъ согласно съ чертежомъ и на мѣстѣ, соотвѣтствующемъ требованію 259 ст. Уст. Стр. О настоящемъ распоряженіи дать знать, къ свѣдѣнію, Оренбургскому Магометанскому Духовному Собранію.

Февраля „26" дня 1902 года.

Губернскій Инженеръ [signature]

Дѣлопроизводитель [signature]

Отд. Стр.

Бикләндә 3 нче җәмигъ мәчетне төзү турында карар.

1911 елда Бикләндә 4 нче җәмигъ мәчет төзү турында карар кабул ителә [Ф.И-295. Оп.. Д. 2681]. 1913 елда 4 нче җәмигъ мәчетенә имам-хатыйп итеп Дәүләтша Мөхәммәтҗан улы Төхфәтуллин һәм мөәззин итеп Габдерәкыйп Хамматуллин сайлана [Ф.И-295. Оп. 5. Д. 10819].

Халык саны мәгълүматлары белән танышыйк. Биклән авылында 1678 елда – 51, 1722 елда – 105, ә 1748 елда 112 ир-ат теркәлгән. Алга таба ревизиядә хатын-кызлар да күрсәтелә башлаган: 1762 елда – 112 ир-ат һәм 132 хатын-кыз (1 кеше, чукынып, авылда калган, 4 бертуган, чукынып, Келәтле авылына күчерелгән); 1795 елда – 143 ир-ат һәм 199 хатын-кыз; 1811 елда – 143 ир-ат һәм 201 хатын-кыз (бер гаилә Түбән Бишендедән); 1815 елда – 193 ир-ат һәм 221 хатын-кыз (1820 елның 8 март карары буенча, Югары Бишендедән 38 ир-ат һәм 30 хатын-кыз күчеп килгән). Бишенде авылы исә 1716 елгы җанисәптә шушы ук йөзлеккә карый. Анда 1711 елгы җанисәптән соң Кирмән һәм Әҗмәкәй авылыннан 2 гаилә күчеп килә. Икенчесе 1825 елда Бишендедән Бикләнгә күчеп килгән типтәр Мәхмүт Мәсәгутов нәселе булса кирәк. М. Мәсәгутов гаиләсе белән күчеп килә, 1830 елда вафат була. 10 нчы ревизиядә аның уллары башкорт катламына кертелә. Бикләндәге дәүләт крестьяннары, җир җитмәүне сәбәп итеп, аларны авылдан кысрыклый башлый, җирсез калдыра. Хәйбулла, Абдулла һәм Хәбибулла Мәхмүтовларга башта Кувады, аннары Оренбург өязендәге Тимербай, соңрак Шикәрле Каен авылларына күчеп китәргә тәкъдим ителә. Ун ел дәвам иткән бәхәскә Мәхмүтовларның дәүләт крестьяннары катламына күчерелүе һәм Бикләндә калдырылуы белән нокта куела. Дәүләт крестьяннары шулай ук мулла Бохармәтевнең җиргә дәгъва итүенә дә ризасызлык белдерә [Ф.И-2. Оп. 1. Д. 8633; Ф. 172. Оп. 1, Д. 152].




Биклән авылында туган морза, Урал полкының 112 пехота
прапорщигы офицер Йосыф Саинов (сулда) хезмәттәше белән.
Хәрәкәттәге армия, август 1917 ел.

Авылда танылган морза нәселе Саиновлар да яшәгән [Ф.И-295. Оп. 5. Д. 8220].

Алдагы җанисәпләрдә авылда халык саны арта: 1859 елда – 1050, 1870 елда – 1304, 1897 елда – 2226, 1913 елда – 2886. Беренче Бөтендөнья сугышы, Гражданнар сугышы, ачлык нәтиҗәсендә халык саны кимүе күзәтелә: 1926 елда авылда 2435 кеше исәпләнә. Репрессия, сугыш алды һәм сугыштан соңгы елларда бу сан тагын да кими: 1938 елда – 1934, 1949 елда – 1429 кеше. Алдагы елларда халык саны бераз артып алса да, инкыйлабка кадәрге дәрәҗәгә җитә алмый: авылда 1958 елда – 1470, 1970 елда – 2014, 1979 елда – 1715, 1989 елда – 1348, 2002 елда 1270 кеше гомер итә.

**Әдәбият**


1. Абдуллин Ш.М. Биклән авыл тарихыннан кайбер истәлекләр / Якты юл. – 12 февраль, 2016 ел. № 10 (5829).
2. Галиуллин М.Х., Вәлиев Т.С. Биклән. Авыл тарихы. Казан: Идел-пресс, 2007.
3. Мустафина Д.А. Служилые татары через призму земельной тяжбы с монастырем // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2016. № 6.
4. Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 гг: Публикация текста. М.: Институт Российской истории РАН, 2001.
5. Фәләх А.Н. Биклән // Мәйдан. 2008. № 2.

6. Шишкин Н.И. История города Елабуги с древнейших времен: исторический очерк. Изд. 3-е, адапт. и доп. СПб.: Маматов, 2014.
7. Ярлык хана Сахиб-Гирея, 1523 г. // *Вестник научного общества татароведения. № 1–2. Казань, 1925.*
8. РГАДА. Ф. 172. Оп. 1. Д. 152.
9. РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Д. 146.
10. РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Д. 1119.
11. РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 239.
12. РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 1471.
13. РГАДА. Ф. 529. Оп. 1. Д. 1539.
14. РГАДА. Ф. 1173. Оп. 1. Д. 136.
15. РГАДА. Ф. 1173. Оп. 1. Д. 140.
16. РГАДА. Ф. 1209. Оп. 1. Д. 156.
17. РГАДА. Ф. 1209. Оп. 1. Д. 6453.
18. РГАДА. Ф.И-2. Оп. 1. Д. 8633.
19. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 5618.
20. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 5875.
21. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 10350.
22. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 12298.
23. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 13600.
24. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 3. Д. 15877.
25. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 4. Д. 4433.
26. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 4. Д. 9011.
27. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 4. Д. 14913.
28. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 589.
29. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 605.
30. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 5778.
31. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 7117.
32. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 8220
33. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 5. Д. 10819.
34. РГАДА. Ф.И-295. Оп. 6. Д. 2681

*(Дәвамы бар)*

**Мәкаләнең чыганаклар бирелгән кушымтасы алдагы номерларның берсендә биреләчәк.**

## ТАТАР БИСТӘЛӘРЕ, ЭЛЕККЕ ШӘҺӘР ТОРМЫШЫ

## ТАТАРСКИЕ СЛОБОДЫ, СТАРАЯ ГОРОДСКАЯ ЖИЗНЬ

*Р. Шагеева*

### ПАМЯТЬ ОБ ОДНОМ ИНТЕРЬЕРЕ



В середине 1950-х гг. Ново-Татарская слобода в Казани – ещё не оскудевший, благодатный оазис народного творчества, скрывающий за фасадами домов и увитых плющом палисадников тихую, скрытую жизнь затаённого ремесла в форме остатков знаменитого, скорняжного дела, ювелирного искусства, изготовления медных кумганов, а также таинственных, написанных на стекле прозрачными серебряными буквами из фольги, переливающихся перламутром, обдавая экзотикой и священным трепетом, татарских шамаилей… Я помню деревянный дом за резными воротами улицы Кызыл Татарстан, накренившийся сосновый золотистый пол, усеянный мозаикой разноцветных кож, и на нем на невысоком табурете своего «жизни» из Мемделей, репрессированного в 1930-е гг. как кустарь, затем участника Великой Отечественной войны, где он оставил свой один глаз, но удивительным образом сохранил профессиональную зоркость – с низменным молоточком в руке и с миниатюрным гвоздиком на губах – это он шьёт для меня очередную пару шуршащих – «поющих» чувяков из шелковистой кожи с аппликативными узорами, которые я «загублю» в высоких сенокосных лугах моего Бикета, снуя среди взрослых во время сенокоса в дни священного праздника «хоррият». А на стене дома, между полками драгоценных книг в кожаных переплётах – святая святых – шамаили, выполненные моей образованной слободской бабуш-

кой Гайшә с бездонными синими глазами и проворными крестьянскими руками. Она средняя сестра моей бабушки по материнской линии Бибиасмы – мастерицы устного фольклора, неистощимой на всяческую выдумку и небыль, наполненных остроумия и добродушного юмора!... Иногда вместе с «Карауджа дәүәни» – старшей из сестер, выходца из прославленного села Карахуджа, сидят три благоухающие старушки в белых платках на скамейке под красной калиной на проулке родной деревни, играют на гармони «Сибелә чәчәк», «Аппагым», потом «в йорт» ставят самовар, читают вслух древние, неведомые мне книги в старинных переплётах, рассказывают поучительные истории и пьют с каким-то удивительным чисто татарским упоением и благоговением чай… Все сестры владели прекрасной образной речью, любили шутку, напевную народную музыку, театр, почитали образованность. А вот «бистә дәүәни», владея арабо-персидской графикой, писала на больших цветных листах, затем переводя на стекло и фольгу, красочные наивные шамаили – с неизменными крупными цветущими маками по сторонам… Меня, не знающей арабский язык и древние письмена, это поражало и вызывало благоговение и трепет… Сейчас мне известны имена многих женщин – шамаилистов и знатоков каллиграфии из Казани, окружающих деревень (Шишинер Балтасинского района, село Б. Атня Арского района и др.). Но чтобы женщина писала какие-то волшебные знаки и рисовала диковинные буквы, тогда это для меня – школьницы-подростка казалось неслыханной редкостью. Гайша апа после смерти мужа сама занялась сапожным делом, шила узорчатые чувяки и туфли…

– Вот умру, возьмёшь себе эти «дога»,– говорила она, перехватывая мой взгляд, направленный на целый фриз старинных шамаилей на стене – плод труда профессиональных каллиграфов, затмевающих её самобытное творчество,– сохранишь их как память обо мне «төсем итеп сакларсың»... Только отчаянные свистки проходящих мимо поездов, как эхо другой, современной цивилизации, нарушали тогда нашу какую-то идиллистическую, почти сказочную жизнь, протекавшую в атмосфере поэзии и искусства.

Так в Музее изобразительных искусств очутился «зелёный шамаиль» из Ново-Татарской Слободы, переданный после смерти владелицы дочерью мне по ранней договорённости...

...«Зелёный шамаиль» – элегантный, строгий, благородный – классическое произведение подобного толка, автор которого, как всегда анонимен, неизвестен. По изяществу композиции, ясности и гармонии составляющих частей, живописному совершенству текстового каллиграфического исполнения – можно предполагать, что его заказчик и ис-

полнитель принадлежали к числу образованнейших, культурных людей своего времени. Среди прообразов – «кальк» в ручном исполнении на бумаге, из которых затем выполнялись живописные шамаили на стекле, хранящихся в отделе редких книг научной библиотеки им. Лобачевского, а также в ГОМТР, и архивах нашего Музея, обнаружить аналогичную композицию не удалось. Нет такого стереотипа и среди печатной литографированной продукции. Следовательно, перед нами шамаиль – уникум, нетиражированный, выполненный в единственном экземпляре, что, безусловно, поднимает его художественную, эстетическую ценность. «Зелёный шамаиль», таким образом, стоит особняком и от печатаемых по заграничным образцам, главным образом, по турецким клише литографиям, широко распространённым в Казани в начале века, так и от народных примитивов наивно – орнаментального стиля, бытуемых в сельской местности и окрестностях Казани. Отличие это заключено в сокровенном оригинальном, завуалированном сюжете, принципы которого восходят к традициям искусства восточной миниатюры и искусству оформления татарской книги. Облик его напоминает скорее всего оригинальную обложку литографской книги казанского производства – «басмаханэ»; о соотнесенности со структурой книги и книжным блоком свидетельствует и изящный в несколько цветов рамка, строгая и лаконичная, как бы сошедшая со страницы целомудренной священной книги...

В нижней части вертикального прямоугольного формата на бирюзово-голубом фоне размещена зеленовато-светлая, выполненная графическими средствами – силуэтно-лёгкая, как будто невесомая конструкция мечети, совмещающей в себе черты Стамбульской мечети Айя – Софья и Тадж Махалла в Агре (Индия): выше над зелёным центральным сводом следует текст по – арабски: «иннә әлләзийнә гыйндә аллаһи әссаләм» – «поистине, те, кто при Аллахе, да приветствуют!». По нему мы мысленно «всходим вверх» в небо, где перед нами на чёрном облакообразном фоне представлен широченный овал текста «аять-аль-корси» («престольный стих» Корана), фигурно выделяющий центральный, обведённый золотом зелёный островок со славословием Аллаху. Когда смотришь на следующий сверху справа влево текст, идущий широким, плотным ритмом, плавно огибая центр, неся в себе ворох изгибающихся, вьющихся, вдетых друг в друга букв, ещё раз убеждаешься в выдающихся возможностях арабского письма, позволяющего без деформации букв придавать им различные модуляции, приближающие графическую вязь к характеру орнаментального декора. «Красота и грация арабских букв напоминает модуляцию в пространстве совершенного человеческого тела»,– пишет турецкий учёный Исмагиль Хакки Балтаси в своем тру-

де «Искусство письма у тюркских народов» (Анкара, 1958). И на самом деле, широкий буквенный фриз, в обилии динамичных, живых деталей, как бы напоминает толпу людей, торжественно обходящих «древний дом» Каабы в Мекке.

(Кааба – главная святыня ислама, центральный объект хаджа, святилище со знаменитым «Чёрным камнем» в восточном углу. Паломники семь раз обходят вокруг Каабы и целуют древний камень... Кааба покрыта «кисвой» – чёрным покрывалом, на котором золотом вышита аяты из Корана). Кстати, чёрный фигурный овал на шамаиле наверху порождает неизбежные ассоциации с мекканской кисвой со священным текстом.

Что касается молитвы «аять-аль-корси», который является наиболее употребительным текстом в татарских шамаилях, он ещё известен как «стих престола»,– то в нём в поэтически – одической форме подчёркивается всесведущность, всемогущество Аллаха, беспредельность и необозримость его власти. «Престол его обнимает небеса и землю, и хранение обоих не обременяет Его, потому что Он высок, могуществен»... Таким образом, композиция «зелёного шамаиля» – с мечетью на земле, скрижалью божественных откровений на небесах, в космосе – великолепная метафора, иллюстрирующая знаменитый перл Корана, восхитивший Пушкина и Гёте. Читающие вслух Коран и понимающие его смысл сумеют ощутить удивительную адекватность поэтически отточенных, отшлифованных строк стиха прозрачно – символическому, благородному живописному языку работы безымянного шамаилиста начала века. Между тем, «сочинённость композиции», отсутствие культа чисто буквенных построений, явное преобладание изобразительного начала делает его одной из важных вех в рождении профессионального татарского изобразительного искусства, предтечей национальной живописи и графики.

«Зелёный шамаиль» украшает в настоящее время экспозицию музея «Хазине» в Кремле, воскрешая память о своей неординарной эпохе, уникальном национальном умении и подлинно народном интерьере.

## ИРЕК МӘЙДАНЫ: БӘХӘС КЛУБЫ

## ПЛОЩАДЬ СВОБОДЫ: ДИСКУССИОННЫЙ КЛУБ

*С.Ә. Хөсәенов*

# ТҮЙКӘ ШӘҖӘРӘСЕНӘ ТӘНКЫЙТЬ КҮЗЛЕГЕННӘН КАРАШ

*(Түйкә һәм аның токымнары Зәй-Каратай авылына күчеп утырганчы)*

***Аннотация:*** *Бу язмада хәзерге вакытта ачыкланган шәҗәрә тезмәсенә, архив чыганакларына таянып, Туйкиннар нәселенең Лениногорск районы, Зәй-Каратай авылына каян күченеп килүе ачыклана. Шулай ук Түйкә шәхесенә караган төрле фаразларны раслау яки кире кагу буенча анализ ясалды. Шәҗәрә башындагы Ындырча шәхесенең Себер татарлары белән бәйләнеше хакындагы фикер әйтеп кителде.*

***Төп сүзләр:*** *Карабаш***,** *Зәй-Каратай, Туйкиннар, Себер татарлары.*

Безнең карашыбызча, Зәй-Каратай авылыннан чыгышлы татар зыялылары бертуган Фазыйл һәм Кәрим Туйкиннарның борынгы бабаларының шәҗәрәсе мондый: **Ындырҗа (1590) – Тулунгуҗа (1615) – Туктагул (1640) – Түйкә (1675) – Сәет (1700) – Мостафа (1725) – Гәбделлатиф (1777) – Әхмәткәрим** рәвешендә бирелгән. Шәҗәрә Сарман районы Минзәләбаш (Бикбулат) авылында Фазыйл Туйкинның кыз туганы Гәзизә апа Вахитова карамагында сакланып, бертуган Туйкиннар тормышы һәм иҗаты турында язылган китапларда басылып чыкты.

Шәҗәрә тезмәсендә Зәй-Каратай авылында яшәгән Мостафа улы Әбделлатиф, аның икенче хатыны Мәрхәбә Рафикова һәм аннан соң яшәгән токымнар турында гына ныклы архив документларына бәйле мәгълүмат бирелә. Шулар нигезендә, Әбделлатиф 1776–1777 елда, икенче хатыны Мәрхәбә 1806 елда туган булып чыга. Шәҗәрә буенча, шуннан да элегрәк яшәгән кешеләр турында фаразлар гына яки телдән телгә күчкән мәгълүмат кына бирелә. Мәсәлән, Гәбделлатифның әтисе Мостафа Каратай мулласы Мәмкә мулла формасында Зәй-Каратай авылында нигезләнгән диелә.

Икенче фараз буенча, Түйкә бабай Урал якларыннан XVIII гасыр башында Зәй буйларына килеп урнаша. Яңа Кәшер авылы да искә алы-

на. Түйкәның хәзерге Азнакай районы Тойкино авылын нигезләве ихтимал диелә. Түйкәнең 1735–1736 елдагы Акай яки 1755 елдагы Батырша восстаниесендә катнашканы өчен, сөргенлеккә сөрелү версиясе дә читтә калмаган. Бер язмада хәтта Түйкә 1773–1774 елдагы восстаниедә Салават Юлаевның ярдәмчесе булган дип бирелә.

Эзләнүләр нәтиҗәсендә менә шушы фаразларны яклап чыгу яки кире кагу мәсьәләсен тикшерәсе килгән иде. Чынбарлыкта, шәҗәрә буыныннан безгә мәгълүм булган Гәбделлатиф Мостафин ике улы, беренчесе – Вәлимөхәммәтгәрәй, икенчесе – Миңнемөхәммәт белән Зәй-Каратай авылына указлы азанчы вазыйфасын үтәргә Бөгелмә өязе Карабаш авылыннан 1816 ел азагында гына килеп урнаша [ГАСО Ф. 150 Оп. 1. Ед. хр. 56]. Карабаш авылында Туйкиннарның борынгы бабалары Гәбделлатиф, указлы мулла вазыйфасын үтәүче абыйсы Мозаффар Мостафин белән Карабаш авылында янәшә яшәгән. Беренче хатынының исеме – Гөлзәгыйфә, 1788 елда туган. Димәк, аның белән яшь аермасы – 11 ел чамасы. Олы уллары Вәли-Мөхәммәтгирей – 1813, Миңнемөхәммәт – 1814, кызлары Мәүләфә 1807 елда Карабашта туган. Беренче хатыныннан тагын бер уллары Таҗетдин (1826 елгы), икенче хатыныннан Абделкәрим (1831) һәм Әбүталип (1847), кызлары Гайникамал (1824) инде Зәй-Каратайда дөньяга килә.

Әбделлатиф 29 яшьләр тирәсендә генә гаилә кора булып чыга. Бу хәлне төгәл аңлата алмыйбыз. Бәлки, дин гыйлемен озак алуына бәйледер. Беренче хатыны Гөлзәгыйфә Каратайда вафат булган дип әйтә алабыз. Бу мәгълүмат Карабаш һәм Зәй-Каратай авыллары буенча, 1816, 1834, 1850 еллардагы ревизияләргә таянып дәлилләнә. Алда әйтелгән шәҗәрә җебендәге Мостафа (кушаматы Мәмкә) мулланың Каратай авылына нигезләнеп утырган дигән фараз дөреслеккә туры килмәде.

Шәҗәрә буенча, төпкәрәк китү Мостафа Сәетовны эзләүне таләп итте. Олы улы Мозаффар 1763 туган дигән информация Мостафаның тумышы 1743 елдан соң түгеллеген исбатлый. Чөнки әни кеше олы улы туганда 20 яшьтән дә ким булмастыр. Бу буынны эзләү, Кама буеннан Урал тауларына кадәр яшәгән кардәшләребездән 1771–1772 елларда 3000 кешелек гаскәр төзеп, Польшада восстание бастыру өчен оештырылган 10 партия сугышчы исемлегенә китерде. Шушы гаскәрнең 9 нчы партиясенә 21 сугышчыны старшина Йосып Урәзмәтов командасыннан үз атлары һәм кораллары белән җибәрәләр [Гвоздикова: 2009. С. 33–134]. Белгәнебезчә, Йосып Урәзмәтов –Нәдер волостен оештыручы старшина Нәдер Урәзмәтовның олы улы. Шушы 21 кеше арасында Йосып Урәзмәтов командасыннан йөзлек белән идарә иткән сотник Мостафа Сеитов та бар. Нәдер волосте территориясенә хәзерге Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә һәм

башка районнар да кергән. Шул ук вакытта Урәзмәтов булышлыгы белән безнең Карабаш һәм Каратай авыллары да нигезләнгән булырга тиеш яки аның ризалыгы белән татарлар һәм башка катлам кешеләре кертелгән.

Алда әйтелгән 9 нчы партия сугышчыларын походтан башкаларга караганда соңрак, 1773 елның август аенда Казанга кайтарып җиткерәләр. Бу вакытка инде алдан, 1772 ел азагында кайтарылган партияләрдән, азатлык өчен көрәшергә ихласлы сугышчылар восстание күтәргән Пугачев гаскәренә кушылган була. Ләкин 9 нчы партияне Казанга кайтарып җиткергәч, таратмыйча, Пугачев восстаниесен бастырырга кулланалар [Гвоздикова: 2009. С. 16].

1771–1772 елда Польша походына җибәрелүчеләр арасындагы йөзбашчы Мостафа Сеитов Туйкиннар шәҗәрәсенә кагылышы барлыгы фаразын күпкә арттыра. Бу елларда сотник булуы, Мостафаның туу, яшәү еллары, бу шәхеснекенә тәңгәл килүе дә фаразны ныгыта. Чөнки сотник абруен 45–50 яшьләр тирәсендә генә алып булгандыр. Мостафа Сеитовның старшина Йосып Урәзмәтов янәшәсендә йөрүе дә мөмкин.

Ә менә Мостафа Сеитовның чыгышы каян икәнен белү кыенлык тудыра. Сүз без фараз иткән кеше турында барса, тумышы 1720 елларга туры килергә мөмкин. Ә Карабаш авылы документлар буенча, 1730–1739 еллар барышында гына телгә алына. Бу каршылыкны, аз булса да, чишәргә 1754 елда Җаек (Урал), Сакмар, Агыйдел, Каргалы, Чебенле елгалары буендагы җирләрне Мясников һәм Твердышевка бакыр рудасы алу өчен сатучылар арасында җир хуҗаларыннан Тамьян волостеннан сотник Мостафа Сеитов катнашуы турындагы мәгълүмат ярдәм итмәсме? [МИБ: 1936. Т. V-1. Док. №47]. Җирләрен саткач, Мостафа Сеитовның Карабаш авылы тирәсенә килүе дә ихтимал. Бу фаразны галим Әнвәр Әсфәндияров язмаларында, Каратай авылында Юрми һәм Тамьян кешеләре яшәгән дигән мәгълүмат ныгыта [Асфандияров: 2009. С. 577–578].

Алдагы хәбәрләргә караганда, Түйкәнең Батырша яки Пугачев восстаниесенә катнашы булуы икеле. Яше буенча якын килмәве дә сизелә. Түйкә яки токымы Урал буйларыннан килгән дигән фаразны бөтенләй кире кагу кирәкмидер. Түйкәнең Азнакай районы Тойкино авылына кагылышы юк, чөнки ул авылны 1726 елда хәзерге Әгерҗе районы үзәге урынында урнашкан авылдан Җөри юлы сотнигы Тойка Абдулов нигезли һәм 1730–1740 елларда Менделеевск районы Бизәкә, Туйхуҗа, Балтач районы Зур Норма авылларыннан чыгышлы кешеләр белән тулыландыра. Башта «новопоселенная деревня на устье реки Менеуз Стерли тож.» дип, соңрак сотник Тойка Абдуловка мөнәсәбәте булганга «Тойкино Стерли тож.» дип йөртелгән [РГАДА Ф. 350, Оп. 2, Ед. хр. 1142. С. 650, 661].

Хәзер Түйкә шәхесенә күчик. Чынлыкта да, архив чыганакларында 1704–1718 елгы Кучум Тлекеев җитәкчелегендә барган восстание вакы-

тында 1707 елны Зәй елгасы буена аңа ярдәмгә, Әхмәт һәм У(р)салы авылыннан Түйкә абызлар килүе телгә алына. Абыз дәрәҗәсе бик укымышлы кеше икәнен дә күрсәтә. Туйкиннар нәселендә гыйлемле указлы муллалар, мәзиннәр булган.

Галим Әсфәндияров мәгълүматы буенча, шушы восстание башлыгы Кучум Тлекеевның да Тамьян волостеннан булуын, Карабаш авылында да тамьян кешеләре яшәвен чагыштыру кирәк. Чөнки Түйкә нәселенең Карабашта яшәвен искә алып, восстание барышында искә алынган Түйкә-батырның без караган шәҗәрә тезмәсенә мөнәсәбәте булуы ихтимал.

Кучум Тлекеевның улы Акай Кучумовның 1735–1737 елларда Мәллә елгасы буенда – Акаево авылында яшәве (ул авылны Якеево авылы белән бәйлисе килә), соңрак Дим елгасы (Баулы, Ютазы районнары аша агучы Димскәй елгасы) буена күченеп утырырга мәҗбүр булганлыгы да архив документларында күренә.

Кучум восстаниясендә катнашучылар 1718 елда патша гаскәре кысрыклау нәтиҗәсендә Казахстан далаларына чыгып китәргә мәҗбүр була. Безнең уйлавыбызча, Түйкә-батыр да восстаниедә катнашканлыктан, шул далаларга китәргә мәҗбүр булгандыр. Фазыйл Туйкин язган шигырендәге «...бабам Зәй елгалары буен сагынып сөргенлектә үлгән»,– дигән юллар, шул вакыйгаларны сурәтлидер... Шигырьдә Түйкә бабасының Казахстан далаларыннан кайта алмыйча ятып калуы тасвирланган булырга тиеш.

Соңгы елларда тарихи шәхесләрне, токымнарны ДНК генеалогиясе ярдәмендә ачыклау алга китте. Туйкиннар токымының геннарын тикшерү, аларның геннары E1b1b1, Рязан өлкәсе Касыйм районы, Мылтык авылында (хәзерге Мунтово авылы[1]) яшәүче татар-мишәрләрнең геннары белән якын тәңгәл килүе ачыкланды, ди төбәкче Рәфгат Каримов [Интернет ресурс]. Бу инде, Туйкиннарның бик борынгы бабалары һәм Мылтык авылы кешеләренең бабалары бер булуын раслый. Бу фаразны Мылтык авылы кергән җирлекнең элек «Кара аймак» дип аталуы да ныгыта. Бәлки, Кара-баш, Кара-тай гидроним-топонимнарын да шушы «Кара аймак»ка кагылышлы кешеләр алып килгәндер[2]. Касыйм ханлыгында яшәгән мордваларның татарлашып, үзләрен «каратайлар» дип атап йөрүләре дә шуңа бәйле булырга тиеш.

Тарихның бер чорында Касыйм ханлыгы хезмәтчел (служилый) катлам кешеләренең Карабаш тирәсенә күчеп килү ихтималы бар дигән сүз нигезле. Монда Себер ханы Кучумне җиңгәч, Мәскәү патшасы аның оныгы Арсланны әсирлеккә төшереп, 1614 елларда Касыйм ханлыгы белән

---

[1] Бу авылда себер татарлары нәселләре яшәгән (ред.).

[2] Бәхәсле фикер (ред.).

идарә итәргә куя. Арслан-хан, безнең уебызча, Касыйм ханлыгына якын кешеләре белән күченгән һәм алар «Кара аймак» халкын тәшкил иткәндер. Ә инде Себер ханлыгы таралгач, туганлыклары булган халык таралышып, Урал тауларын кичеп, Карабаш, Каратай тирәләрендә төпләнеп урнашу ихтималы да бар.

Бу фаразны ныгытырга 1748 елда үткәрелгән 2 нче ревизия барышындагы Каратай авылы буенча язмалар ярдәм итә. Ревизиядә Каратай авылы халкы турында, бер урында Төмән уезды Кадермәт авылыннан, икенче урында Төмән уезды Каратай авылыннан Гөрләй Кунактаевның уллары күченгән диелә [РГАДА Ф. 350, Оп. 2, Ед. хр. 2450. ЛЛ. 202, 302]. Хәзерге вакытта Төмән өлкәсе Ишим районында да Каратай авылы барлыгы билгеле.

Себер ханлыгында Тура елгалары буенда урнашкан татар кардәшләребез дә Туйкиннар шәҗәрәсе тезмәсенең баш өлешендәге Ындырча шәхесенә якын авазлы исемнәр белән йөртелгән. Мәсәлән, XVII гасыр тарихи документларында Япанча йорты (хәзер Туринск шәһәре Свердловск губерниясе) сотник Япанча исемен йөрткән. 1602 елгы документта аның ярдәмчеләре Кайманча, хәтта Туйкиннар шәҗәрәсендәге Ындырча исеменә бик тә якын килүче исем – Оргынча исемле себер татарлары булуы искәртелә [Самигулов: 2019. С. 50–56].

Өстә күрсәтелгән фаразларның кайберләре документлар нигезендә расланса да, күп өлеше әле табышмак булып кала һәм чишүне таләп итә. Каратай, Карабаш авыллары һәм Лениногорск төбәге тарихчылары шушы мәгълүматларны кулланып, Туйкиннар шәҗәрәсен тагын да төптәнрәк өйрәнер дип ышанып калабыз.

*Кушымталар:*

**Ревизская сказка д. Карабаш. 1816 год август.**

№ 1. Указной мулла Музафар Мустафин 49/63 (1763 г.р.) года, жена Разыя (Мратова) 40 лет.

сын Мухаметзариф 3/7 лет, дочь Миртузиган 9 лет.

№ 2. Абдуллатиф Мустафин 36/40 (1776 г.р.) лет, жена Гульзагифа 25лет, сын Валимухаметгирей -/3года, дочь Муулафа 9 лет.

**Ревизская сказка д. Каратай 1834 года 31 января.**

№ 3. Причислен в кончении 7-й ревизии того же кантона (№ 12) из д. Карабашевой в 1816 г.

указной азанчей Габдулатиф Мустафимов 40/57 лет.

Габдулатифовы сыновья

Мухаметгирей 3/20 лет

Миннимухамет 2/19 лет

Тазитдин -/8лет
Мухаметлатив -/4 года
Мухаметкарим -/3 года
Курбангали -/1год
Габдуллатифа жены
1-я Мархубя 28 лет
2-я Сахипямал 36 лет
Дочь Гайникамал 8 лет

**Ревизская сказка 1850 г. августа 25 дня, Оренбургской губернии Бугульминского уезда, XIII башкирского кантона, юрты № 2, деревни Старого Каратая:**

мужчины:

№ 3. Указной имам-мударрис Габдул-Латиф Мустафинов (73 года).

От первой жены первый сын муэдзин Магомет-Гарей (36 лет).

Магомет-Гарея сын Магомет-Шакир (10 лет).

Габдул-Латифа Мустафинова от первой жены другой сын Минни-Магомет (35 лет).

Минни-Магометовы сыновья – Минигали (8 лет), Вильдан (5 лет), Шарафутдин (2 года).

Габдул-Латифа Мустафинова от первой жены третий сын Тазитдин (24 года),

Габдул-Латифа Мустафинова от второй жены первый сын Магомет-Латиф (20 лет).

Магомет-Латифа сын Абуталип (3).

Габдул-Латифа Мустафинова от второй жены другой сын Ахметкарим (19 лет). Его же от второй жены третий сын Курбангали (умер 1837 г.).

женщины:

№ 3. Габдул-Латифа Мустафинова вторая жена Мархаба Рафикова (44 года).

Его же третья жена Сахибзямал Габдуллина (52 года).

Его же от второй жены дочери: Гайнулзямал (13 лет), Хадича (11 лет). Магомет-Гарея Габдуллатифова жена Мирвафа Шамсутдинова (30 лет).

Тазетдина Габдуллатифова жена Газиза Тимирбаева (26 лет). Магометлатифа Габдуллатифова жена Минсулу Бикмагометова (30 лет). Ахметкарима Габдуллатифова жена Фатима Дильмагометова (22 года).

## Чыганаклар һәм әдәбият

1. Асфандияров А.З. Аулы мензелинских башкир. – Уфа: Китап, 2009. – 600 с.

2. Гвоздикова И.М., Азнабаев Б.А., Мухамедьяров К.А. Башкирское войско в Польском походе (1771–1774 гг.). Сборник документов. – Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2009. – 178 с.
3. Государственный архив Самарской области (ГАСО). Фонд. 150. опись 1. Ед. хр. 56.
4. Материалы по истории Башкирской АССР, том V-1 (ответственный редактор А. Чулошников), Москва, Ленинград, изд. Академии наук СССР, 1936. – 631 с.
5. РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Ед. хр. 1142.
6. РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Ед. хр. 2450.
7. Самигулов Г.Х., Маслюженко Д.Н. Понятие «Иштяк» как соционим. // Иштяки: Приуральско-сибирское пограничье. Казань, Казанский институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2019. С. 45–60.

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

## ИЗВЕСТНЫЕ ЛИЧНОСТИ

*Фәнзилә Җәүһәрова*

# ЭТНОГРАФ ЮБИЛЕЕ

*(Рәмзия Гыйният кызы Мөхәммәдованың 100 еллыгы уңаеннан)*

Оста китсә, эше калыр,
Эшенә тиң эзе калыр.

*(Татар халык мәкале)*



Кеше гомеренең яртысы диярлек белем алу, гыйлем туплау, дөнья көтәр өчен кирәкле дип табылган күнекмәләр булдыру юнәлешендә үтә. Мәктәп елларында, аннан соң югары уку йортында белем алган вакыт аралыгындагысы гомернең чиреген тәшкил итсә, калганы эшләү дәверендә танышкан коллегалар, дуслар, үзең булдырган даирә тирәсендәге кешеләргә бәйле туплана. Тупланган белемнең сыйфаты, сине үстерерлек булуы даирәңдә булган кешеләрнең аң-белем, эрудициясенә, кешелек сыйфатларына туры-

дан-туры бәйле. Юкка гына: «Синең кем икәнлегең хакында күбрәк аралашкан кешеләрең сөйләр»,– дигән гыйбарә барлыкка килмәгән.

Бүген сөйләр сүзем мине этнография фәнен, татар дөньясын, халкыбызның күзаллаулар системасын яратырга, аның белән мавыгырга, халкыбыз көн итешенә бәйле төшенчәләрне ишетү өчен колагымны сак торгарга өйрәткән, халкыбызның матди мәдәнияте белән рухи мәдәниятенең береккәнлеген аңлаткан остазым, укытучым, коллегам Рәмзия Гыйният кызы Мөхәммәдова хакында булыр.

Рәмзия апаны (аңа безнең буын вәкилләре зурлап шулай дәшә иде) моңарчы «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) китабы авторларының берсе буларак кына белсәм, 1997 елда «Татар фольклоры дәүләт Үзәге»ндә фәнни хезмәткәр булып эшли башлагач, ныклап таныштым. Беренче танышкан көннәрдән үк минем акылым Рәмзия апа портретын: мөлаем йөзле, Гыйльми совет утырышларында чыгыш ясаучыларны сабыр гына тыңлап утыра торган, уйлаганда күзләрен бераз йомып, салмак тавышы белән сүз башларга яратучы, утырышта җавап тотучы фикерен төгәл яисә анык итеп әйтә алмаса, кимсетмәслек такт белән белгәннәре белән бик теләп уртаклаша торган ханым буларак тудырды. 2000 елда мин Үзәкнең фәнни эшләр буенча директор урынбасары вазыйфаларын башкарган, аннан соң (2002 елдан) директор буларак эшләгән чорда Рәмзия Гиниятовна белән аралашып кына калмыйча, кулга кул тотынып эшләргә дә туры килде. Аның белән бергә татар авыллары, район үзәкләрендә эшләүче мәдәният сарайлары, йортлары хезмәткәрләре өчен татар халык мәдәниятен саклауга юнәлтелгән методик семинарлар, остаханәләр системасын булдыру концепцияләрен төзедек. Шушы концепция нигезендә семинарлар эчтәлеге сыйфатын тәэмин итү максатыннан Рәмзия апа дистәләгән лекция әзерләде, алар белән даими рәвештә чыгыш ясый торды. Аның лекциясен башлаганда: «Шуны белегез: мәдәниятсез халык юк. Кайсы гына халыкны алмагыз, һәркайсы үз җирлегендә ул гына тудыра алган бөек мәдәниятка ия. Ул беренче чиратта, яшәгән тирәлеге табигатенең мөмкинлекләренә: суына, урманына, балчыгына, анда үскән үлән-агачына, балыгына, җәнлегенә, җирлегенең ландшафтына таянган. Шушы табигатьнең көндәлек яшәешне тәэмин итү чыганагы икәнлеген аңлап, аны үзеннән соң киләсе буынга бозмый калдыру өчен тыюлар системасын булдырган»,– дип әйтә торган җөмләләре әле дә хәтердә. Рәмзия апаның нәкъ менә шушы фикерләре Үзәктә эшләүче яшь галимәләребезгә эзләнүләрен фольклористика, этнография, филология фәннәре казанышлары бөтенлегендә комплексллы алып барырга этәрде дә инде.

Әлбәттә, эзләнүләрнең чишмә башы булып, Рәмзия апа җитәкчелегендә әзерләнгән экспедицияләр оештыру системасы торды. Экспедици-

яләрдә эшләү өчен тематик бүленешле сораулыклар булдырылды. Ул сораулыклар Үзәкнең Гыйльми совет утырышларында кат-кат тикшерелде. Алар нигезенә моңа кадәр филологик фольклористика фәне кысасында тудырылган жанрлар системасы түгел, ә мәдәни күренешне халыкның яшәеш тирәлеге бөтенлегендә карап, гипертекст буларак теркәү алынды. Экспедициягә чыгар алдыннан тикшереләсе җирлектә яшәүче татарларның этногенезисына, теле, этнографик үзенчәлекләренә караган мәгълүматларны беркадәр белү мәҗбүрияте дә җитди шартларның берсенә әверелде. Бу гамәлләр дә Рәмзия Гыйниятовнадан башка булдырылмады. 2002 елда 79нчы яше белән барган олуг галимәбез Кукмара районына оештырылган экспедициядә фәнни җитәкче буларак системалы рәвештә җыелган бай мәгълүмат теркәүгә иреште. Бу экспедиция минем өчен менә дигән дәрес булды. 20 майдан 30 майга кадәр сузылган фәнни сәяхәт кысаларында без Кукмара районында яшәүче татарларда күрше авыллардагы мари, удмурт халкына бәйле материаллар да терки алдык. Иң мөһиме – аларны теркәү инструментларын да апробацияләдек. Болар барысы да салкын мәктәп интернатларының мичендә янган иске парталар җылысында кич утыру вакытларында тудылар. Тора бара Рәмзия апа белән башланган бу эшебез, «Мультифольклорные пространства Татарстана» дигән темалы яңа экспедицияләр программасына әверелде.

Шул ук елны Үзәк эшендә тагын бер традиция барлыкка килде. Анысы да Рәмзия Гиниятовна, Марсель Бакиров кебек галимнәребез эшчәнлеге катнашында булды. Экспедиция табышлары белән район мәгарифе, мәдәнияте хезмәткәрләрен турыдан-туры таныштыру максатыннан район күләмендә методик семинарлар үткәрелә башлады. Шушы семинарлар җирлегендә фольклор этнографик төркемнәр, күп кенә авыл мәдәният йортларында тарихи-этнографик почмаклар барлыкка килде, районның вакытлы матбугатында авылларда тупланган фольклор материаллары дөнья күрә, халык мәдәнияте фондлары булдырыла башлады.

2003 елда Санкт-Петербург шәһәре үзенең 300 еллык юбилеен билгеләп үтәргә җыенган февраль ае ахырында Россия этнография музееның Идел буе халыклары бүлеге җитәкчесе Лидия Михайловна Лойко Рәмзия Гиниятовнага (бу вакытта Рәмзия апа да 80 яшен тутырырга җыенып йөри иде) шалтыратып, шәһәрнең юбилеена татарларга бәйле зур экспозиция әзерләргә җыенулары һәм музей фондларында сакланган кием элементларыннан татар костюмнары комплекслары төзүдә катнашырга чакырды. Гомерен татар халкы этнографиясен өйрәнүгә багышлаган Рәмзия апа бу тәкъдимнән берничек тә баш тарта алмады. Әле дә хәтеремдә, өс киеменә әллә ни исе китмәгән галимәбез Питерның дымлы салкыннарын истә тотып, башына яңа төлке бүрек, килешле пәлтәләр сатып алып, юлга

кузгалды. Ике атнага якын эш дәвамында керәшеннәр, Казан, Касыйм татарларына бәйле костюм комплекслары корылды, моңарчы музей фондларында атрибуцияләнми яткан йөзләгән кием элементларына аңлатма язулары әзерләнде. Параллель рәвештә РЭМ фондларында сакланган бай материалларның фотоларын да булдырды. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, бүгенге РЭМ тарафыннан әзерләнгән каталогларда урын алган татар костюмнарының күпчелеге Рәмзия Гыйниятовна корган комплекслар.

Санкт-Петербург шәһәрендә эшләү Рәмзия апаны иҗат итәргә дәртләндерүче факт та булып чыкты. РЭМ фондларында төшереп алган фотолар, үзе туплаган материаллар нигезендә ул «Народный костюм татар кряшен» дип аталучы китап-альбом әзерләргә тотынды. Бик күп фактик материллардан торучы әлеге китап 2005 елда басылып та чыкты. Һәм ул керәшен мәдәнияте өлкәсендә хезмәт куючыларның өстәл китабына әверелде. Китапның гамәли әһәмиятен аңлаган Рәмзия апа альбомны рәссам-модельер Лариса Чубукова эскизлары белән махсус баетып, хезмәтен тагы да файдалы итә алды.

Шушы ук елларда Рәмзия апа Үзәкнең Гыйльми советына 1972 елда «Татары мишари» исеме белән дөнья күргән китабының тулыландырылган басмасы план-проспектын тәкъдим итте. Тугызынчы дистәне ваклаган галимәбез яңа дәрт белән эшкә кереште. Гыйльми утырыш карары нигезендә тумышы белән Касыйм якларыннан булган Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган рәссам-модельер Лариса Сергеевна Чубукова туган шәһәренең Төбәк музее фондларыннан «Татары мишари» китабына кертер өчен материаллар тупларга җибәрелде. Моннан тыш, Пенза, Ульян, Саратов, Саранск шәһәрләре музейлары белән элемтәләр булдырылды, алар белән мәгълүмат алышыну башланды. Өч ел буе дәвам ителгән зур хезмәт 2008 елда фәнни яктан тирән, фото-фактлар, костюм комплексы эскизлары белән баетылган тарихи-этнографик тикшеренү китабы буларак дөнья күрде. Рәмзия апаның бу хезмәте дә тиз арада танылып өлгерде һәм 2010 елда тагын бер тапкыр өстәмә тиражланды.

Рәмзия апа гомеренең соңгы көннәренәчә татар этнографиясенә тугры булып, белгәннәрен теләгәннәргә кызганмый бирүне кирәк санаган олпат шәхесебез. Тормышымның зур өлешендә аның фәнни куәсен аңлап, фикердәше булып яшәргә мөмкинлегем булуына сөенәм, Ходай Тәгаләгә рәхмәтләремне укыйм.

***Редакциябез авторның бу бәяләмәсен хуплап, Р.Г. Мөхәммәдованың башкарган эшләрен югары бәяләп кала, аның татар этнологиясенә керткән өлешен тагы бер тапкыр күрсәтеп үтә.***

*Хәмидә Гарипова*

# ТЕЛ ЯЗМЫШЫ – ИЛ ЯЗМЫШЫ




Туган телебезнең бүгенге четрекле хәле милләтпәрвәр шәхесләрне, милли үзаңы тиешле дәрәҗәдә үскән, газиз татарымның киләчәк язмышына битараф булмаган киң җәмәгатьчелек вәкилләрен хафага сала. Әмма телебезгә оятсызларча кизәнүче, аны милли мәктәпләрдән сөреп чыгарырга, татар гаиләләрен туган телдән биздерергә омтылучы даирәләрне сүгеп, эчтән көенеп, диванда борчылып ятудан ни мәгънә?

Хәрәкәттә – бәрәкәт, ди халык әйтеме. Ил язмышына тиң туган тел язмышын ихластан кайгыртып, теләктәшләр табып, уртак максатка йөз тотып, һәр көнне бер генә адым алга атласак та, бер генә изге гамәл кылсак та, кара көчләр туган телебезне юкка чыгара алмас. Алтынга тиң милли җәүһәрләребез киләчәк буыннарга исән-имин барып ирешер. Әлеге җәһәттән кем нинди алымнар куллана, ни рәвешле изге эш-гамәлләр кыла ала? Милләтпәрвәр түрәме син, шагыйрь, язучы, галим, рәссам, дин әһеле, мөгаллим, журналист, артист, җырчымы, гади эшче-хезмәткәрме, игенче-терлекчеме – бусы мөһим түгел. Тоткан кыйблаң дөрес, күңелең саф, туган телеңнең бүгенге кыерсытылган хәленә мөнәсәбәтең битарафлыктан ерак икән, көндәлек тормышта, үзеңнең эш урыныңда, гаиләңдә, социумдагы аралашу даирәңдә тел язмышын кайгыртып ясаган кыю адымнарың белән аның хәлен яхшырту, халәтен тотрыкландыруга үз өлешеңне кертә аласың. Бу мәкаләмдәге мөхтәрәм ханымның гыйбрәтле язмышы милләт язмышын ихластан кайгыртуның күпләр үрнәк алырлык ачык мисалы.

Укытучы-шагыйрә Галия Гайнетдинованың «Үз юлым» дип аталган, Бөтендөнья Татар Конгрессы башкарма комитеты химаясендә, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән китабын тәкъдим итү кичәсенә барырга чыккач, уйламаганда-көтмәгәндә, классик язучы Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестендагы «Без түбәннән – тормышның төбеннән күтәрелдек»,– дигән юллар исемә төште. Күрче, бу-

генге тантананың сәбәпчесе Галия Михей кызының гыйбрәтле язмышы да нәкъ менә шул юлларга сыеп беткән түгелме соң? Ул – Башкортостанның Тәтешле районындагы кечкенә генә Сараштыбыш авылында, дүрт ятим баласын сыңар канаты астына сыендырып, михнәтле нужа йөге, юклык-кимлек ачысы төялгән тормыш арбасын тартып баручы, кечкенә буйлы, ябык гәүдәле әнисе Сәгадәтнең кул арасына бик яшьли кергән, авыр физик хезмәттә чыныгып үскән татар баласы. Гап-гади авыл бичәсе, уймак авызлы, елтыр күзле сабыена хәләл күкрәк сөтен имезгән чагында, моңлы татар-башкорт көйләрен көйләгән. Кызыксынучан-тиктормас нарасые исәя төшкәч, шигъри аһәңнәргә бай татар телебездә әкиятләр сөйләгән, мөнәҗәтләр, догалар өйрәткән. Сөйкемле, хисчән, эшсөяр кыз туган авылы табигатенең, туган теленең матурлыгын тоярга, тормышны яратырга, кешеләрне хөрмәт итәргә әнисеннән өйрәнгән, иң мөһиме: авырлыкларга очраганда югалып калмаска, бирешмәскә, максат куеп, алга бару өчен кирәкле асыл сыйфатларны үзендә булдырырга омтылган. Туган туфрагында хезмәт сөеп яшәүче авылдашларыннан, Сараштыбыш, Күрдем авылы мәктәпләрендә үзенә белем биргән мөгаллимнәрдән, йотлыгып укыган китапларының геройларыннан – чын кешеләрдән үрнәк алып, хикмәтле фикерләрне күңел сандыгына таслап сала барган, шул рәвешле рухи көч туплаган. Күрдем – гади генә авыл түгел, күренекле шагыйрь, драматург Әнгам Атнабаевның туган җире ул. Галиябез аның иҗатына балачактан мөкиббән, китапларын су урынына эчә, шигырьләренең күпчелеген яттан өйрәнә. Шушы мохиттә тәрбияләнгән укучы бала үзе дә шигырьләр, мәкаләләр яза башлый, татар-башкорт халкының танылган әдипләре – Габдрахман Әпсәләмов, Гөлшат Зәйнашева, Мостай Кәрим, Илдар Юзеев белән хатлар алыша. Остазлары кыздагы сәләт чаткыларын сизеп, алтынга тиң киңәшләрен бирә, аны әдәби иҗатка илһамландыра.

Бүгенге көндә республикабызның югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе иясе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Әнгам Атнабаев һәм Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияләр лауреаты, җиде китап авторы Галия ханымның тормыш юлына күз салсак, артыннан этүчесе булмаган гади авыл кызының шушы мәртәбәләргә ирешкәнче шактый авыр, катмарлы, сөенеч-көенечләргә бай, озын хезмәт юлы үтүе сер түгел. Шунысы куанычлы: әледән-әле каршыга исүче ачы тормыш җилләре, кайвакытта таш бәгырьле, көнчел, хөсетле бәндәләргә юлыктырып, хаксызлыклар кылып, җанын тетрәндереп, хисчән күңелен яраласа да, Галиябезнең көчле рухын сындыра алмаган, авырлыкларга тешен кысып түзү, тоткан юлыннан тайпылмыйча,

үҗәтләнеп бары тик алга бару күркәм ханымның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан.

...Унынчы сыйныфны яхшы билгеләргә генә тәмамлаган җитү кыз, бөтен вөҗүде белән әдәбият-сәнгать дәрьясына чумарга ниятләп, татарның рухи Мәккәсе саналган Казанга ашкынып килә. Әмма монда аны кем колач җәеп каршыласын соң? Әйтерсең, киң дәрьяга бер юка йомычка очып төшкән... Даһи Ленин үзе укыган университет баскычларына кызыгып баккан хәлдә, һөнәри училищеда эшче һөнәрен үзләштереп, Камил Якуб исемендәге Полиграфкомбинатта хәреф җыючы булып эшли башлый ул. Башкалардан калышмас өчен, эшкә иртәрәк килә, соңгы кеше булып кайтып китсә – китә, тырыш кыз планын үти. Хезмәт сөючән, ачык йөзле Галиябезнең җитезлеге, өлгерлеге аңа уңыш китерә. Комбинат юлламасы белән Мәскәүдә укып кайтып, технолог һөнәренең серләренә төшенә. Актив комсомолка кичләрен сәхнәдән төшми, үзешчәннәрдән торган халык театрында лирик героинялар ролен бик оста башкара. Бауман район Советына депутат итеп сайлангач, башы-аягы белән җәмәгать эшләренә чума, социаль мәсьәләләрне кайгырта. «Шаулы яшьлегемнең янып торган ун елы Полиграфкомбинатка багышланды. Эшемне яратып башкарганга күрә, коллективта хөрмәт казандым, карьера баскычыннан күтәрелдем, әмма җаныма тынгылык тапмадым. Бу еллар эчендә кулымнан йөзәрләгән китаплар узды. Их, үзем язган күңел җимешләремне туплап, шигырьләремне шәлкемләп-шәлкемләп шушы китаплар хәленә китереп, әдәбият-сәнгать сөюче меңләгән укучыларга ирештерсәң икән ул!» – дип янып-көеп йөргән елларын сагынып та, моңаеп та искә ала Галия ханым. Саф күңелле татар кызының ихластан теләгән теләкләре фәрештәләрнең: «Амин!» – дигән вакытына туры килгәнче, ике дистә елдан артыграк вакыт үтәчәген ул чакта каян белсен соң Галиябез? Иң мөһиме – алдына зур, изге максат куела!

1990 елларда Татарстанда милли азатлык хәрәкәте гаять көчәеп, халык урамнарга ташып чыккан чорда, хикмәтле язмыш җилләре Галиянең көйләнгән хезмәт юлын гына түгел, тормышын йөз сиксән градуска үзгәртеп куя. Казанның «Жилплощадка» дип аталган үзәктән ерак бистәсендә татар мәктәбе ачылачак, бөтен фәннәрне ана телендә укытып, балаларны милли мохиттә тәрбияләячәкләр, әмма кадрлар кытлыгы галәмәт зур икән, дигән хәбәрне ишетүгә, татар җанлы Галиябез тәвәккәлләп шунда юл тота. Мәктәп директоры Фарис Харисов (соңрак Татарстанның мәгариф министры дәрәҗәсенә күтәреләчәк) белән очрашып сөйләшкәннән соң, Галия Михей кызы әйбәт хезмәт хаклы, җайга салынган технолог эшеннән гариза язып китеп, яңа оешып килүче мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытырга керешә. Бирелә нәрсәгә тотынсаң – шул юк, әмма ту-

ган халкыма хезмәт итәм, балаларга туган телне өйрәтәчәкмен, алардан милли җанлы, иҗади куәсле чын милләтпәрвәр шәхесләр тәрбияләячәкбез дигән изге максат күңелне алгысытып, җанга җылылык биреп тора. Татар мәктәбе үсеп, данлыклы 5 нче гимназия статусын алган арада, Галиябез читтән торып укып, Казан дәүләт педагогика университетының татар филологиясе бүлеген тәмамларга, яраткан егете Рафаил белән гаилә корып, ике бала табып үстерергә өлгерә.

Тарта торган атка йөкнең авырын төйиләр. Директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары Галия Михей кызы гимназия тормышын җанландыруның, татар балаларын иҗат мохитендә тәрбияләүнең кызыклы алымнарын уйлап таба һәм гамәлгә кертә. Гимназия радиосын оештыра, «Яшь хәбәрчеләр», «Театр» түгәрәкләрен җитәкли, дәресләрдән соң әдәбият-сәнгать сөючe йөзләгән балаларны татар театрларына, милли музейларга, татар редакцияләренә алып баралар, татар язучылары, артистлар, милли җанлы галимнәр, журналистлар белән күпсанлы очрашулар эзсез узмый. Галиянең һәм аның хезмәттәшләренең фидакярь хезмәте әрәм китми. Балалар милли, иҗади мохитта туган телен, әдәбиятын яратып, аның байлыгын, матурлыгын тоеп, фәннәрне ана телендә тирәнтен үзләштереп, тулы бер яшь буын чын милләтпәрвәр булып җитешә. Гимназияне тәмамлаучылар арасында нинди генә танылган, күркәм шәхесләр юк! Һәркайсы туган халкына намуслы хезмәт итеп сөендерә. Бүгенге көндә дә Галия педагог һөнәренә тугрылыклы. Ул әзерләгән укучылар йөзенә кызыллык китерми, республика күләмендәге олимпиадаларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә, «Татар кызы», «Татар егете» кебек милли рухлы бәйгеләрдә алдынгы урыннарны яулыйлар. Соңгы елларда туган телебезне рәнҗетү, кысу, белем учакларыннан кысрыклап чыгаруның киң колач алуы сер түгел. «Туган тел сагында без тормасак, кем торыр? Без көрәшмәсәк, кем көрәшер? Тел язмышын без кайгыртмасак, кем кайгыртыр? Мең еллык тарихы булган бай, гүзәл аһәңле татар телебезгә «Йәсин» чыгарга ирек бирмәбез!» – дип, милләтпәрвәр Галиябез, пенсия яшендә булуына, тынгысыз йөрәге чыгымчылауга карамастан, җиң сызганып эшләвен дәвам итә. Балаларга милли белем бирү белән беррәттән, татлы төн йокылары, җәйге яллары хисабына актив әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Туган телебезне, татар халкын яклап, шигырь-мәкаләләр генә язып калмый, радио-телевидениедән чыгыш ясый, татарлар яшәгән төрле төбәкләргә барып, китап укучылар белән очраша, кешеләрнең сүнеп барган күңелләренә өмет орлыклары салып, күңелләрен күтәреп, рухларын ныгытып кайту җаен таба.

Иҗатына күз салсак, җимешләренең муллыгы исең китәрлек. «Күңелем язлар көтә» (2004), «Җанда әгәр сөю яшәсә...» (2007), «Ярты җаным

яши авылда» (2010), «Яратам дип язып куйдым» (2014), «Ашыкма син, гомер!» (2018), «Күңел-бакча» (2020), «Үз юлым» (2023) дип исемләнгән шигырь китапларында милли рухлы, татар җанлы, олы йөрәкле, кече күңелле чын татар хатынының, мөхтәрәм мөгаллимәнең туган халкына мәхәббәте, хөрмәте, аның язмышы турында ихластан борчылуы, киләчәккә якты өметләре бай туган телебездә искиткеч җылы хисләргә, фәлсәфи тирәнлеккә ия зирәк уй-фикерләргә, урынлы метафораларга, чагыштыруларга бай хиссиятле-гыйбрәтле шигъри юлларга затлы итеп төреп бирелгән. Галия Гайнетдинованың лирик шигырьләре үзләре көйгә салуны сорап тора кебек. Егермеләп әсәренә Марсель Иванов, Виталий Агапов, Мәүлидә Нургали, Өлфәт Хаҗиев, Азамат Усманов, Айнур Айданов, Дәниф Бадыйков, Чулпан Фәйзелгатова кебек композиторлар көй язган.

Әдәби мәҗмугаларының соңгысын Татар Конгрессы бинасында презентацияләү бу мәртәбәле, җитди оешманың Башкарма комитеты җитәкчелеге, галимнәр, җырчылар, укытучылар, вакытлы матбугат әһелләре, әдәбият сөючеләрнең актив катнашында бик җылы мохиттә узды һәм уңай тәэсирләр калдырды. Татар Конгрессының Милли Шура Рәисе Васил Шәйхеразиев, КФУның атказанган профессоры, күренекле әдәбият галиме, китапны хәзинәгә тиңләп, тәфсилле кереш сүз язган остазы – Фоат Галимуллин, тарихчы-галим Альберт Борһанов, «Белем.РУ» радиоүзәге һәм «Әдәби марафон» директоры Раил Гатауллин, «Мәктәп» нәшрияты директоры Гүзәлия Яруллина, Казан шәһәре мәгариф идарәсе белгече Раиф Зиннәтуллин һ.б. чыгыш ясаучылар әдибәнең иҗатына югары бәя бирделәр, китаптан – китапка әсәрләре камилләшә, теле шомара, тематикасы киңәя, фикерләре тирәнәя баруын ассызыклап үттеләр. «Үз юлым» җыентыгының үзенчәлеге, өстенлеге аның берьюлы ике дәүләт телендә басылып чыгуында. Тәрҗемәче Томас Нигамәтҗановның хезмәте хөрмәткә лаек. Ул шагыйрәнең күңел тибрәнешләрен оста сиземләп, укучысына әйтәсе килгән төп фикеренә хилафлык китермичә, хиссиятен югалтмыйча, әсәрләрне әдәби-эстетик югарылыкта рус теленә тәрҗемә итеп, укучылар даирәсен киңәйтүгә ирешә алган. Бәйрәм кичәсен шагыйрә Илзирә Вәлиуллина бик матур итеп алып барды, биредә җырлар, шигырьләр яңгырады, күңелләребез яктырып, җылынып киткәндәй булды.

Г. Гайнетдинованың әлеге китабында кечкенә балалар өчен дә шигырьләр бирелгән. «Адымнар» мәктәбенең 3 сыйныф укучысы Шаһиева Раянә шагыйрә апасының балалар өчен язылган «Кемнәр елатты икән?» дигән шигырен яттан укыды. Югары дәрәҗәдә оештырылган әлеге кичә матур мизгелләре белән туган телен, әдәбиятны яратучы һәркем күңелендә озакка сакланыр.

## ТАТАР РУХЫ

## ТАТАРСКИЙ ДУХ

*Гөлзадә Сафиуллина*

# ТӨРКИ-ТАТАР БАЛАЛАРЫНЫҢ «СӨЕМБИКӘ ВАРИСЛАРЫ» ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЕ КЫРЫМ – КАЗАН АРАСЫНА КҮПЕР САЛДЫ (1999–2021).

*(Ахыры. Башын укыгыз: № 4, 2023)*



Әйдәманнар.

Ә фестивальнең тарихына килсәк: 1999 елда башланган төрки-татар балаларының иҗат фестивале 4 ел рәттән бернинди тоткарлыксыз Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән уздырылып килде. Төп иганәчебез – «Кара алтын» банкы җитәкчесе Ринат Мидхәт улы Абдуллин булды. Һәм кинәт, 2003 елгы фестивальгә бер атна кала, иганәчебез ярдәм күрсәтүдән баш тартты.

Фестивалебез биш номинациядә барды: җыр, бию, музыка уен коралларында уйнау, нәфис сүз һәм гамәли сәнгать. Һәр номинациядә солистлар һәм ансамбльләр бар. Барлыгы 25 лауреатка акчалата премия бирелә иде, шуның өстенә – 2 мең доллар күләмендә гран-при. Бердәнбер иганәчегә авыргарак төште шул. 400гә якын бала, билетлар кулда, санаторийда урыннар алынган, әмма фестивальне үткәрергә акча юк...

8000 доллар акча табарга кирәк. Төрле җирләргә хатлар язып карадым, әмма ярдәм итүче табылмады. Бер рус кешесе генә кесәсеннән 1000 сум акча чыгарып бирде. Шул чакта мин төп ярдәмчем Аллаһы Тәгалә булуын

исемә төшереп, төне буе намаз укып, елый-елый Алладан: «Йә Раббым, миңа шушы фестивальне үткәрергә акча табарга ярдәм ит!» – дип сорадым. Икенче көнне, иртән Донецкида яшәүче танышым Фәридә: «Гөлзадә апа, фестиваль буламы, мин балалар алып килмәкче идем?!» – дип шалтыратты. «Була, әмма акча юк. Фәридә, Ринат Ахметовка («Шахтер» футбол командасының президенты) хат язсам, син тапшыра аласыңмы?» – дидем. «Тапшырам»,– диде ул. Төне буе утырып, бу хатка бөтен йөрәк энергиямне салып: «Син дә бит татар баласы, татар балаларының фестивале өзелү алдында тора, ярдәм ит!» – дип хат яздым. Аны факс аша җибәрдем һәм иртән Ринат Ахметов фестивальгә 8000 доллар акча бүлеп бирүе турында хатка кул куйган. Балаларга тартма-тартма лимонадлар, футболка, бейсболкалар җибәрде. Фестивальне бик югары дәрәҗәдә үткәрергә ярдәм иткәне өчен, аңа Алланың рәхмәте яусын, Украинадагы бүгенге чолганышлардан иман белән чыгарга Ходай насыйп әйләсен!

Алдагы елларда, фестиваль спонсорсыз калгач, йөзләгән хат язып, иганәче эзләдем, әмма табылмады. Үзем дә җырчы кеше булгач, акча сорап йөрү түбәнчелек шикелле тоелды. Фестиваль утын сүндермәс өчен, Казанда үз көчем белән, 4 тапкыр фестиваль үткәрдем. Икесе – К. Тинчурин театрында, берсе – Менжинский исемендәге мәдәният сараенда, йомгаклау концерты узды. Дүртенче фестиваль М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында «Каһарман җырлар» фестивале буларак үткәрелде. Беренче көнне үземнең концертымны бирә идем, концерт акчасына читтән (Кырымнан, Дагъстаннан, Хакасиядән) килгән лауреатларның юл хакларын, яшәүләрен һәм туклануларын үз өстемә алып, фестивальне үткәреп килдем. Бер тапкыр исә Кырым Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Кырым – Украина күләмендә үткәрелде чара. Ул чакта Украинаның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Кырым-татар җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Какура Сервер Шаипович фестивальнең бөтен авырлыгын үз өстенә алды. 2010 елда мәдәният министры Зилә Вәлиевага мәдәният өчен җаваплы депутатыбыз хат яза. Ул хатта соңгы елларда Кырымда «Сөембикә варислары» фестивале уздырылмый башлады, безгә аның урынына «Алтын тәхет варислары» дип аталган фестиваль уздырырга акча бүлеп бирегез, дип язылган иде. Шундый ук хат Кырым мәдәният министры урынбасарыннан да килеп төшә. Бу хатларны үз күзләрем белән күргәч, өнсез калдым. Шундук мәдәният министры Зилә Рәхимҗановнага кердем. Бу хатлар турында белүемне аңа әйттем. Бу елны фестивальне үткәрү планга кертелмәгән булса да: «Быел «Сөембикә варислары» фестивален Кырымда үткәрәчәкмен, миңа ничек булса да ярдәм итегез»,– дидем. Министр ханым: «Бер җирдә ике фестиваль була алмый, мин «Сөембикә варисларын» хуплаячакмын, ул – Кырымда популяр, яраткан фестиваль»,– диде. Фести-

валь чыгымнары бу елның бюджетында каралмаган булса да, кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтте. Нәкъ шул көннәрдә Бөтендөнья татар конгрессы җыйган татар эшмәкәрләре җыенында мөрәҗәгать белән чыктым. Юлын, яшәү һәм туклану чыгымнарын үз өсләренә алып, һәр төбәктән берәр баланы фестивальгә җибәрүләрен үтендем. Барысы да, риза, дип тавыш бирде. Шул чакта, элеккеге спонсорыбыз, аягүрә басып: «Туктагыз, тавыш бирергә ашыкмагыз, бу фестиваль Гөлзадә Сафиуллина исемендә, ул аны конгресска бирсен, шул чагында тавыш бирербез»,– диде. Мин, торып: «Юк, бирмим, ул минем тудырган балам кебек, быел узмаса, алдагы елларда узар, барыбер фестиваль утын сүндермәячәкмен. Ярый ла хәзер конгресс рәисе милли җанлы кеше, ә алда кем буласын бер Алла белә, фестивальне бетереп ташлаулары да ихтимал»,– дидем. Шуннан соң, ярдәм итәбез дип, яңадан тавыш бирү булмады. Нәкъ шул минутта, 2010 елда, гәрчә, вакыт бик аз калган булса да, фестивальне үткәрергә дип, үземә сүз бирдем. Бу җыенда миңа каршы эш йөртүчеләрнең хәйләсе дә ачылды. Менә ни өчен 2003 елны, спонсорыбыз, фестиваль башланырга бер атна кала, ярдәм итүдән баш тарткан икән. Аларның уе: фестивальне үз кулларына төшереп, үзләре дигәнчә генә үткәрү, фестивальне үз мәнфәгатьләре өчен куллану булган.

Мин тиз арада катнашучылар арасына балаларны, волонтерларны, ата-аналарны, галим-голәмәләрне дә кертеп, катнашучыларның яшен дә арттырып, фестивальда катнашырга теләүчеләрне тупладым. Әмма, акча юк иде. Тагын үземнең төп ярдәмчем, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать иттем. Бүтән синнән акча сорап ялвармас идем, зинһар шушы фестивальне генә үткәрергә булыш дип, намаз укып, Раббымнан сорадым. Иртәнге якта, моннан 10 ел элек арендага бирелгән иске студиямнең арендаторы: «Гөлзадә ханым, сатасызмы, юкмы, студиягезне?» – дип шалтыратты. Ул күптән сатып алырга теләсә дә, бәясе түбән булу сәбәпле, кире каккан идем. Бу юлы шатланып ризалаштым. «Кесәңә бер миллион акча сал да, тиз генә килеп җит, калганын аннары сөйләшербез, договорларны соңрак төзеп бетерербез»,– дидем. Шулай итеп, бер миллионны кесәмә салдым да, Кырымга очтым. Фестивальне Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән моңарчы булмаган дәрәҗәдә үткәреп чыктык. Фестиваль җыенга әйләнде. Анда «Татар кызы», «Татар егете» бәйгеләре, Сабантуе, «Мин татарча сөйләшәм» акциясе, композиторыбыз Сара Садыйкова иҗатына багышланган кичә, татар халкының күренекле шәхесләре, тарихчылар, музыка-сәнгать белгечләре, язучылар, галимнәр белән очрашулар, кичке уеннар белән гөрләп узды. К.Тинчурин театры артистлары Артем Пискунов, Резедә Сәлахова, Илфак Хафизов, Лия Вильдановалар концертларны, чараларны алып барды, Сабантуйларда күрсәтмә чыгышлар ясап, ба-

ларның күңелен күреп, алар белән аралашып, әйдәп баручы булдылар. Фестиваль эченнән әйдәманнар үсеп чыкты, алар миңа зур таяныч иде. Күп чараларны балалар үзләре оештырды.

Аллаһы Тәгалә мондый саваплы эштә, халкыбызның бик мәрхәмәтле кешеләрен дә юлыбызга чыгарып тора. Бик авыр вакытта татар эшмәкәре Фәрит Фаиз улы Мифтахов ярдәм кулы сузды. Гәрәп илләренең берсендә татар рестораны ачып яшәп ятучы Исмәгыйль Шәнгәрәевне Аллаһы Тәгалә үзе җибәрде. 1990 елда фестивальнең акчалата бүләкләү фондын тулаем ул күтәрде. Исмәгыйль балалар мохитендә үзе дә бәхеткә чумды. Менә нинди шәп, намуслы, иманлы егетләребез бар безнең, Аллаһы Тәгалә аларны үзенең рәхмәтеннән ташламасын! Гомумән, фестиваль акчасына минем кагылышым юк иде. Еллар буена булган акчаларыма, балаларга бүләкләр туплый идем. Кызлар бәйгесенә төрле энҗе-мәрҗәннәрдән үрелгән тәкыяләр, егетләр бәйгесенә түбәтәйләр... Үземнең бертуган энемнең улы Шамил – түбәтәйләр тегүче. Ул бирә иде затлы, чигүле түбәтәйләрне. Үземнең хәзинәмдәге калфакларым, балалар белән мәктәптә очрашуда бирелгән бүләк-сувенирларым бихисап иде. Шуларны, һәм, әлбәттә, үземнең студиямдә дөнья күргән аудио-видео язмалар мине коткара иде. Конгресс биргән матур милли китаплар да бик ярап куйды. «Ялкын», «Сөембикә» журналларының затлы бүләкләре дә тамашачыларның йөрәкләрен яулап алган катнашучыларга барып иреште. Бер елны кызым Резедә Фәннәр Академиясе галимнәре чыгарган затлы китаплар төяп алып килде. Поезд вагоныннан бушатып бетерерлек түгел. Ярты автобус китап. Ничек границадан алып чыга алганбыздыр, хәтерләмим. Әмма бер нәрсә бик истә калган. Язучы, журналист, «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова, «Крымские татары – привет от Сталина» дигән китабын чиктән үткәрмәүләре аркасында Кырымга алып бара алмавын әйткәч: «Бирегез, үзем алып барам»,– дидем. Берничә йөз китапны балаларның кофрларына (костюмнарын сала торган капчык) тутырып, чикләрдән алып чыктык. Бер генә китапны да конфискацияләтмәдек. Венера ханым үзе дә килеп, балалар һәм өлкәннәр белән очрашу үткәрде. Ул китапта Кырым татарларының моңарчы әйтелмәгән, дөньяга чыкмаган яшерен тарихы, ачы язмышы язылган иде. Алар өчен китап әйтеп бетергесез зур бүләк булды. Бүген дә, Венера ханыма кырым татарлары рәхмәт укый, аны онытмыйлар.

«Сөембикә варислары» – халык фестивале. Талантлы балаларның юл һәм яшәү чыгымнарының күпчелеген ата-аналар, җирле эшмәкәрләр, җитәкчеләр каплый иде. Югыйсә, шул кадәр күп бала ерак юллар үтеп, чит илгә барып, ике атна дәвамында бәйгеләрдә, төрле чараларда катнашып, Кара диңгездә коенып, Кырым буйлап төрле экскурсияләргә йөреп, ял итеп кайта

алыр идеме?! Шул уңайдан, җирле җитәкчеләргә, татарның милли җанлы эшмәкәрләренә, ата-аналарга, укытучыларга, волонтерларга олы рәхмәтемне белдерәм. Бөтендөнья татар конгрессына да, ярдәм итүләре өчен, Алланың рәхмәте яусын! Алар берни дә югалтмады, бары отты гына. Заманында Илсур Гәрәй улы Хадиуллин (бүген Татарстан мәгариф министры) фестивальгә килеп, гала-концертта ялкынлы чыгыш ясап, Әстерханнан «Нур» ансамблендә биюче бик матур кызга чигүле татар читекләре бүләк иткән иде.



Гран-при лауреаты Марат Файрушин.

Чигүле читек, чигүле сөлге, калфак, түбәтәйләр фестивальнең символик бүләкләренә әйләнде, күпме балаларның күңелендә сүнмәс учак кабызды. Конгресс хезмәткәре Илдар Камил улы, бөтен фестивальләрдә дә олы ярдәмчем булды. Рәхмәт сиңа, газиз халкым! Син әйбәт, уңган да син, булган да, мәрхәмәтле дә, кирәк чакта усал да була беләсең. Бу сиңа бөтенләй дә җебеп бетмәс өчен кирәк. Алда бит әле милләтне, телебезне, моңыбызны, җырларыбызны, тарихыбызны саклыйсыбыз, яшәтәсебез бар! Ни дисәң дә, дөнья безнең иңнәрдә! Без тартмасак, кем тартыр? Нәкъ җырымдагыча.

Зур дәүләтләр корган халык без,
Җир тетрәткән батыр алып без.
Туган илгә яулар килгәндә,
Җан аямый торган халык без.

Бу юллар «Әй, татарлар!» дигән җырымнан. Әгәр ишетмәгән булсагыз, YouTube каналыннан карагыз, клип шулай атала.

Шушы 20 ел эчендә фестивалебезнең үз иҗат төркеме барлыкка килде. Ул композиторлардан, музыкантлардан, җырчылардан, балетмейстерлар-

дан, ана теленең нечкәлекләрен белгән остазлардан, дирижёрлардан – хор җитәкчеләреннән һәм гамәли сәнгать осталарыннан тупланды. Һәр ел саен өстәлеп, яңарып торды. Бу фидакарь җаннар балалар коллективларын туплап, үзләре юл, ашау, яшәү чыгымнарына акча табып, чикләрне узып (Кырым Украинага кергән заманда) йөзләгән баланы Кырымга – Ялта каласына алып килә иде. Шул фидакарьләрнең берничәсен атап үтәм. 1999 елдан башлап музыкант, фольклорчы галим Геннадий Макаров, Алсу Еникеевалар «Ак калфак», «Җомга көн», «Дәште Кыйпчак» фольклор ансамбльләре белән фестивальнең җыр сәнгате өлкәсендә, халык иҗаты өлгесен нигез итеп алырга булыштылар. Казаннан «Ләйсән» ансамбле җитәкчесе Венера Гатауллина, балалар күңелендә халык җырлары аша иҗатка мәхәббәт тәрбияләгән зат. Мәскәүдән яшьләр вокал ансамбле белән Роза Хабибуллина, «Шатлык» ансамбле җитәкчесе Зәмзәмия Сәхәбетдинова фестивальнең аерылгысыз дусларына әйләнде. Үзләре җитәкләгән вокал ансамбльләрен китереп, уңышлы чыгыш ясап, лауреат булдылар. Балаларга, яшьләргә ана телендә җырлар өйрәтүдә күп көч куйдылар, фидакарьлек күрсәттеләр. Яр Чаллыдан бертуган Рамил һәм Айгөл Закировлар «Баяным» дигән җырны җырлап, биеп, үзенә бер спектакль-тамаша ясадылар. Кырым ягыннан да берничә балалар вокал ансамбле бик матур (үзе заманча, үзе милли) киемнәр киеп, балалар җырларын җырлап, безне таң калдырды. Күбесенең инде исемнәре дә онытылган, әмма фотолары калган. Китабымда алар да үз урыннарын алыр, иншалла.

Түбән Камадан «Нәүрүз», бүген «Нардуган» ансамбле җитәкчесе Наил Мусифуллин, Кырымда һәм Казанда үткәрелгән фестивальләрдә остазлыкның иң югары дәрәҗәсенә ирешеп, залдагыларны таңга калдырды. Г. Камал театрыннан балетмейстерлар Сәлимә һәм Илдус Габдрахмановлар фестиваль өчен махсус сәхнәгә куйган «Казан шәкертләре» биюе Кырым тамашачысын аяк үрә бастырды, ул бию бүген дә сәхнәләрне ду китерә. Нүрбәк Батулланың илаһи энергетикасы аркасында бу өч шәкерт биюе мәшһүрлек казанды.

Казахстаннан Семи шәһәреннән татар-казах балаларын, гармуннарын, төрле уен коралларын төяп, Габдулхак Ахунҗанов килеп җитә иде. Татар дөньясын берләштереп, мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез сагында торучы батыр егетебез. Татар музыка мәктәбе ачып, шуны җитәкләп, анда татар һәм башка милләт балаларына да белем бирә, татар җырларын өйрәтә. Балаларга яңа репертуар туплап, өйрәтеп, милли киемнәр кидереп, берничә поездга, автобуска күчеп утыра-утыра чикләрне узып, мең бәләләр белән Кырымга фестивальгә алып килә иде. Аннан соң, «Иртыш моңнары» дип аталган фестиваль оештырып, милли яшәешебезне, сәнгатебезне алга сөргән шәхес ул. Үземә дә, «Иртыш моңнары» фестивален-

дә жюрида булып, Габделхакның ничек татар дөньясына җан өреп, рухын саклавын үз күзләрем белән күреп кайтырга туры килде. Ул бөтен дин әһелләре белән элемтәдә, зияратлар аның өчен үзе бер тарих, татар тарихы, мөселман тарихы... Күпме акыл иясе, күпме ишан анда җирләнгән, һәммәсенең дә исемен, чыгышын белә. Ул – тере тарих сакчысы, аны Аллаһы Тәгалә үзе сакласын! Фестивалебезнең олы терәге булдың, горурланам синең белән дустым. Фестивальдә Габдулхакның укучысы Диаз Мусалимов «Мин – джазмен» дигән җыры белән лауреат булган иде. Бүген Америкада, Нью-Йорк университетында вокал укыта, профессор. Ул Америкада казах спортчылары җиңү яулаганда аларга татар композиторы Латыйф Хәмиди язган Казах гимнын җырлап, Төрки дөньяның данын, мәдәниятын мәгъриб илләренә таныта. Диаз юбилеебызга килергә вәгъдә бирде. Иншалла, күрешәчәкбез! Гомумән, юбилеебызга барлык фестивальләрнең дә лауреатларын чакырдык. Новосибирскидан Габдулхакның укучысы, безнең лауреат Дания Хәйбуллина фортепианода уйнап, Мәскәүдә Чайковский исемендәге конкурста катнашып, 2 нче урынны яулады. Ул да фестивальгә киләчәк, иншалла! 2010 нчы елгы фестивальдә Семи шәһәре халыкара конкурслар лауреатлары Руслан Тураев һәм Руслан Галькеевлар мастер-класс күрсәттеләр. Татар халык көйләрен баянда уйнап татар сәнгатен дөньякүләм аренага күтәрделәр. Аларның дәвамчылары бүген татар халкына тырышып хезмәт итүче ике виртуоз – баянчыбыз Айнур Моратов һәм Татарстанның атказанган артисты Айдар Әхмәтҗановлар да «Сөембикә варислары»нда чыныгу алды. Алар икесе дә фестивальдә төрле уен коралларында – курай, кубыз, тальян гармуннарда уйнап катнаштылар. Аннары үзләре курайчылар ансамбле оештырып, фестивальнең гала-концертында күмәк чыгыш ясадылар. Айдар Әхмәтҗанов бүген Татарстан Дәүләт фольклор ансамблендә эшли. Ә виртуоз гармунчы Айнур Моратовның уйнавына мөкиббән китеп, күренекле шәхесебез, язучы-журналист Мәгъсум ага Гәрәй аңа тальян гармун бүләк иткән иде.

Чүпрәле районыннан килгән «Умырзая» халык уен кораллары ансамбле турында да берничә сүз. 2010 нчы елгы фестивальнең гала-концертын 2000 кеше сыешлы залда, «Салих Сәйдәшев маршы» белән ачып җибәрделәр. Җитәкчеләре Руслан Шәрәфетдинов, фестивальдә фонограммасыз бөтен балаларга баянчы булды. Татар музыка сәнгатенең киләчәге менә шушы егетләр кулында.

Кырым татарлары турында аерым бер китап язарлык. Алар фестивалебезне шулкадәр баетты. Кырым татарлары балалары мәдәни тәрбия алып үсәләр. Бигрәк тә бию ансамбльләренең фидакарь хезмәтләре ихтирамга лаек. Балалар шәһәрдәге ансамбльләргә авыллардан дүртәр-бишәр чакрым йөреп, җырларга, биергә өйрәнәләр. 20 ел эчендә безнең фестивальдә генә

дә, аларның меңләгән баласы берничә яшь категориясендә катнашты. «Гульдесте» кызлар ансамбле (җитәкчесе – Таҗикстанның атказанган артисты Эльзара Асанова), «Тиселли» җыр-бию ансамбле (җитәкчесе Украинаның атказанган артисты – Мөнир Аблаев), «Учан-су» (җитәкчесе – Кырым Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Али Алимов), «Җемиле» (җитәкчесе – Украинаның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кырым Республикасының атказанган артисты Җәмилә Османова) – болар барысы да төрле еллардагы лауреатлар. Алар Төркиядә һәм Европа илләрендә гастрольләрдә еш була, төрле халыкара фестивальләрдә катнаша. Кырым татар балалары менә шушы ансамбльләрдә сәнгать мәктәбен үтә, чыныгу ала, матурлыкны күрергә өйрәнә. Менә ни өчен аларның аркалары төз, куллары очар кош сыман биектә, үзләренә ышанычлары да зур. Кырым татар халкының ошбу остазларына бүген үк һәйкәл салырлык.

Элек, без үскәндә, мәктәптә хор белән җырлау бар иде. Шунда сәхнә һәм тавыш күнекмәләре аласың, кыюлыкка өйрәнәсең, кеше арасына чыккач, югалып калмыйсың, кызганыч, алар бүген популяр түгел. Бию дә шулай, балаларны үзләрен иркен, гәүдәләрен матур тотарга өйрәтә. Хәзер дә мәктәпләребездә, матур язу дәресләре кебек, матур сөйләм дәресләре кертергә иде. Югыйсә, балаларыбыз, аеруча, авыл балалары авызларын ачып, сүз әйтергә куркып тора бит. Бу безгә бик кирәк. Оныгым Амар шушы юнәлешне башлап, яшьләр арасында дебатлар үткәрә башлагач, бик сөенгән идем. Ул шактый балаларга, яшьләргә ораторлык осталыгы серләрен өйрәтте. Нәфис сүз жанры өлкәсендә күп еллардан бирле армый-талмый хезмәт итүче остазыбыз Алабуга шәһәреннән Наилә Биҗанова, бик күп балаларга ана телендә дөрес сөйләм күнекмәләрен өйрәтеп, аларны фестивальләрдә катнаштырып, лауреат иткән ханым. Әти-әнисе өйрәтә алмаган телнең матурлыгын, татлылыгын, җегәрен балаларның йөрәкләренә салган фидакарь зат. Наилә ханым, мең рәхмәтләр яусын сезгә! Сезнең укучыгыз Булат Сәхәбиев Ялтада ике мең кеше сыешлы залда фестивальнең гала-концертында Г. Тукайның «Китмибез» шигырен укып, Ватан кадерен белергә, татар рухын сүндермичә, нык булырга чакырды.

1999 елдан башлап, фестивальнең берсен дә калдырмаучы Эмине Мостафаева «Сөембикә варислары»ның символына әверелде. Урта Азиядән әтисе Сервер, әнисе Лилия белән Ватаннарына кайтып, Симферопольдә кечкенә генә, бернинди уңайлыклары булмаган тулай торакта яшәп, зур сәнгатькә хезмәт итүче җырчы һәм остаз булып үсеп җитте ул. Кырым индустриаль педагогиясе институтын тәмамлап, бер үк вакытта кырым-татар җыр-бию ансамблендә эшләп, үзе укыган институтта яшьләргә белем бирә, тагын әле кечкенә балалардан торган ансамбль оештырып, шулар белән эшләп ята. Кырым ансамбленә алмашлар әзерли. 2019 елда

аңа туенда Татарстанның атказанган артисты исемен тапшырдылар. Юбилеебызда ул ире Арсен Усеинов һәм Казаннан Альбина Насыйрова (Мухаметшина), Байбулат Батуллалар белән концертны алып барачак. Әлбәттә, Эминенең таянычы әтисе булды. Ул аны уңга-сулга тайпылдырмыйча туры юлдан, олы сәнгать юлыннан алып барды, ныклы белем алырга ярдәм итте. Сервер үзе дә композитор, музыкант, халыкара фестивальләр лауреаты. Эминенең энесе Энвер дә фестивалебездә катнашып, бик матур чыгыш ясады, кырым татарларының Ватан турындагы җырын җырлап лауреат булган иде. Алма агачыннан ерак төшми, дигән гыйбарә, нәкъ аларның гаиләсенә кагыла. Әниләре Лилия балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Миңа аларда күп тапкырлар булырга туры килде. Сервер миңа Кырымда татар балаларын барлау, фестивальгә әзерлекле катнашучыларны гына китерү өчен күп көч куйды. Кырымда ике Серверым бар. Берсе – Какура, икенчесе – Мостафа, ике канатым булды. Кырым татар балалары алар ярдәме белән фестивальләрдә катнаша алды. Сервер Какура үзе дә кырым татар җыр-бию ансамблен Төркиягә, чит илләргә гастрольгә алып чыкты. Казанга килеп, татар атналыгы көннәре үткәрделәр. Эмине – ансамбльнең алыштыргысыз солисты. Ансамбльдә шулай ук «Сөембикә варислары» лауреаты Арсен Бекиров та эшли. Сервер Какура аны – үзе бер карыш, кәпәче биш карыш баланы, су сибеп үстергәндәй үстерде. Ул да Татарстанның атказанган артисты исеменә лаек булды. Биюче Зарина Зәйнетдинова да ансамбль солисты, «Сөембикә варислары» лауреаты. Ул фестивальдә Җәмил Аблаев белән бергә биеп, чыгыш ясаячак һәм, әлбәттә, кырым татарларының мәшһүр биюе «тым-тым»ны тамашачыларга бүләк итәчәк. Ә Эмине – күпкырлы шәхес. Казанга берничә тапкыр КВН уеннарында катнашырга да килде. Казан белән Кырым арасына күпер салучылар «Сөембикә варислары» булса, Кырым ягыннан иң күренеклеләре Сервер Какура, Җәвит ага Кутдусов, Эмине Мостафаева, Сервер Мостафаев, Диләвир Османовлар иде. Без салган шул күпердән



Фестиваль лауреатлары
Ширин һәм Эмине Мостафаева.

сәнгать әһелләре Кырымга килеп, Татарстан сәнгать атналыгы уздырды. Ул күпердән эшмәкәрләр дә, сәясәтчеләр, икътисад өлкәсендә эшләүчеләр дә узды, күп аралашты. Алдагы фестивальләрне үткәрүдә ярдәмчеләребез – кырым татар егетләре Ришат Камилов белән Ришат Аблаев. «Соади Тур» дип аталган туристик оешманы җитәкләүчеләр. Балалар яшәгән ял йортларында көн-төн сакта торып, иминлегебезне кайгырттылар, уңай шартлар тудырып, бөтен җаваплылыкны үз өсләренә алдылар. Шуңа фестивальләр тыныч узды, бер генә күңелсезлек тә булмады.

Фестивальне әзерләүдә һәм аның барышында төп ярдәмчеләрем кызым Резедә (филология фәннәре кандидаты, илаһият галиме), оныкларым Амар белән Ширин иде. Амар тавыш операторы булып та, Сабантуйлар, төрле чаралар үткәрүдә, кунакларны каршы алу һәм озатуда төп җаваплылыкны үз өстенә алды. Ә Ширинем исемлекләр төзеп, компьютерда эшләнә торган бөтен эшләрне башкарды, программалар төзергә, кичке уеннар үткәрергә булышты. 2003 елгы фестиваль аерата истә калган. Кече оныгым Мурадның, тууына бер генә ай иде. Аны сумкага салып йөрттек. «Сөембикә варислары» Мурадны кулдан төшермәде. Резедәм, оныкларым режиссёрларым, тавыш операторларым, оештыручы администраторларым, карусыз йомышчыларым да иде һәм фестивальдә катнашучы балаларга да күз-колак булдылар. Боларның барысы өчен кеше ялласаң, акча түләргә кирәк булыр иде, ә үземнекеләр бушлай эшләде. Миңа акча сорап, теләнеп йөрергә туры килмәде. Кайбер фестивальләр турында рәсми җитәкчеләр белми дә кала, соңыннан гына, газета-журналлар аша ишетәләр иде. Без реклама ясап, эшебезне күрсәтеп, мактанып йөрмәдек, ә эшләдек тә эшләдек. Иң мөһиме – фестиваль утын сүндермәү иде. Исәпләсәң, исең китәр! Күпме чыгым тотылган! Читтә яшәүче балаларны Казанга китертү, аларны урнаштырып, ашату-эчертү, транспорт чыгымнарын күтәрү – барысы да үз өстемдә. Бер дә хәтеремнән чыкмый: зур автобус белән 200гә якын бала. Тукай Кырлайга барабыз. Юлга чыгар алдыннан тарихчы галимебез Габделбәр абый Фәйзрахманов Сөембикә манарасы янында балаларга тарихыбызны, Казанны саклаучыларның бу җирдә каны елга булып агуы турында сөйли. Балаларның күзләрендә яшь, дога кылабыз... Тукай Кырлайга юл тотабыз. Габделбәр абый юл буе тарихыбызны сөйли. Балаларның күзләрендә ут яна, сораулар яудыралар. Урыны җәннәттә булсын Габделбәр абзыебызның! Зур гыйлемле, ихлас, бик тә милли җанлы кеше иде. Тукай Кырлайда музейда, мәктәптә булганнан соң, клубта концерт куйдык. Бу апрель ае, әле чәчәкләр үсми. Шунда бер апаның концерттан йөгереп чыгып китеп, өеннән тәрәзә төбендәге гөлен чүлмәге белән алып килеп, балаларга бүләк иткәнен хәтерлим.

Мондый сәяхәтләр күп кылынды: Бахчасарайга, Ханнар сараена, музейларга, Кырымның һәм Казаныбызның тарихи урыннарына, Болгарга һәм башка җирләргә. Балалар тере тарих белән танышып, үзләренең кем, нинди милләт вәкиле икәнлеген аңлап, күп дәүләтләр төзегән халыкның оныклары булуын сизеп, горурлык хисләре кичереп, дуслашып, күрешергә сүзләр куешып, ана телебездә рәхәтләнеп аралашып, елап аерылыша иде.

Бер тапкыр лауреатларны гына туплап, 25 баланы самолетка төяп, Төркиягә бөтендөнья балалар фестиваленә алып бардым. Меңләгән халык алдында, стадионда һәм төрле мәйданнарда чыгыш ясадык. Балалар төрек гаиләләренә урнашып яшәде, яшәү рәвешләре белән таныштылар һәм дуслашып калды. Татарстан балалары өчен махсус өстәл әзерләп, Төркиянең милли мәҗлесе кабул итте. Төркиянең берничә шәһәрендә һәм тарихи урыннарда, Кемаль Ататөрек мавзолеенда булып, балалар үзләренә рухи яңарыш алып, берничә баскычка күтәрелеп кайтты.



Фестиваль лауреаты
Айгөл Зиятдинова.

Җырчы Марат Фәйрушин белән Илнара Хуҗиеваны сәхнәдән төшермәделәр, чәчәк бәйләмнәренә күмделәр. Анкара, Иске шәһәр, Истанбул урамнары буйлап, Татарстан байрагын җилфердәтеп, татар җырларын җырлап, биюләрен башкарып, Татарстан данын якладык. Сәнгатебез, үз-үзебезне тотышыбыз аша туган илебезнең, туган халкыбызның бөеклеген исбатладык. Гала-концертларыбыз кырым татарларының «Гүзәл Кырым» җыры белән тәмамлана иде. Аны Кырым һәм Казан ягыннан солист – лауреатлар Эмине Мостафаева, Айгөл Зиятдинова, Ширин Аль-Анси, Гүзәл Ахмадиева, Марат Фәйрушин һәм Үзәир Наймановлар башлап җырлады.

Татарстан төбәкләре арасында иң күп катнашучылар Түбән Кама шәһәреннән булды. Бигрәк тә Наил Мусифуллин җитәкчелегендәге «Нәүрүз» бию ансамбле чыгышы – татар халкының төрле биюләре, милли киемнәрнең зәвыклылыгы игътибарны җәлеп итте. Бөтен күзләр аларда иде, биючеләр фестивальнең күрке булды. Ә Наил Шәкүр улын, балалар

бик ярата, ихтирам итә иде. Ул – үз эшенең остасы һәм дисциплина ярата торган кеше. Юбилейга аларны да күтәбез.

Хаҗитарханнан (Астрахань) килгән Дәүләт Умеров җитәкчелегендәге «Мирас» ансамбле бию ансамбльләре арасына үзенә бер яңа дулкын булып килеп керде. Ул шул җирлектәге татар-ногай биюләре белән чыгыш ясап, бию сәнгатенә яңа сулыш өрде, аны тагын да тулыландырды. Ул хәзер Казанга кайтты, монда да бер дигән профессиональ ансамбльләргә торырлык, «Мирас» ансамблен төзеде, балаларга, яшьләргә белем бирә, бию серләрен өйрәтә. Хезмәтләрен искә алып, аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем бирелде. Тәбриклибез үзен, гыйлеме дә, тәҗрибәсе дә җитәрлек, Ходай саулык бирсен, ул безгә бик кирәк!


Гөлзадә Сафиуллина һәм ногай егете гран-при лауреаты Үзәир Найманов.

Хаҗитарханнан Миңнура Ялаева һәр елны фестивалебезгә «Нур» ансамблен алып килә иде. Сөембикә турында композицияләр ясап, күккә ашкан калфаклары белән безне борынгы заманнарга, Сөембикә заманнарына алып китәләр иде. Аларның юл һәм яшәү чыгымнарын һәр елны җирле татар иҗтимагый үзәге рәисе Алмаев Әнвәр Ибраһим улы күтәрә иде. Менә нинди алтын баганаларыбыз бар. Ни кызганыч, Миңнурабыз арабыздан китте, урыны җәннәттә булсын! Хаҗитарханнар үзләренең тыйнаклыгы, калфакларының, нәкъ Сөембикә калфагы кебек, югарыга үрмәләгән булуы белән аерылып торды. 1990 елда кечкенә генә бер календарьдән күреп, үз кулларым белән беренче Сөембикә калфагын тегеп, шуны киеп, бөтендөнья мәдәни миссиясендә катнашып, 7 илдә чыгыш ясаган идем. Шуңарчы андый калфакны беркемдә дә күргәнем булмады. Шул калфагымны, Сөембикә костюмымны киеп, балалар алдында чыгыш ясадым. Аннары «Сөембикә варислары» шундый калфакларны тегә, чигә башлады. Иң беренче, Альбина Мөхәммәтшинада күрдем. Шуннан соң китте, өскәрәк, биеккәрәк үрмәләде калфакларыбыз...

Нәфис сүз жанрында өч шәп егет истә калган. Булат Садретдинов (үзе шагыйрь, 4 китабы дөнья күрде), Байбулат үзенең тавышы, энергетикасы белән бөтен Кырымны шаккатырды, һәм Алабугадан Булат Сәхәбиев – бик

матур малай Габдулла Тукайның «Китмибез!» шигырен сөйләп, ачык дикция, тавыш аһәңенең көчле һәм матур булуы белән күңелләребезгә кереп утырды. Өчесенең дә өстендә Тукайча костюм иде. Булатны балалар «Тукай» дип йөртте. 6 яшьлек энегым Мурат та, алардан калышмаска тырышып, Рөстәм Мингалимов шигырен: «Атланырмын, ат бирсәң! Атта йөргән малай мин! Кылыч бирсәң, алырмын! Кылыч күргән малай мин! ... Бабаларым канында яуга кергән малай мин!..» – дип сөйләп, сәхнәне дер селкетте.


Гран-при лауреаты
Байбулат Батулла.

Нурбәк Батулланың хореографик училищеда укыган вакыты иде. Сәхнәдә, халыкны таң калдырырлык бер яңа бию юнәлеше күрсәтәсебез килде. Балетмейстерлар Сәлимә Әминова һәм Илдус Габдрахмановлар стейк-чечетка биюен куйды. Училищеда укыган өч биюче егет (әйдәп баручысы Нурбәк иде) шушы биюне аяктан ут чыгарып биеде, тамашачыны шаккатырды.

Нурбәкләр белән бер үк училищеда укып, балет сәнгате серләрен үзләштергән бик матур кызыкаебыз Әминә Имашева да фестивалебезнең очар кошы, аккошы булды. Балет алымнарын кулланып биегән «Аккош» биюе үзенә бер могҗиза булып, тамашачыларны әкият дөньясына алып китте. Әминә үзе дә бер хыял дөньясыннан чыккан нәфис зат булып күренде. Әтисе – җырчы-композитор Мәсгут Имашев, әнисе – җырчы Фатыйма бу балага үзләрендә булган иҗат рухын өреп, аны олы сәнгатькә хезмәт итәр өчен үстергәннәр, күрәсең.

«Сөембикә варислары» фестивалендә беренчеләрдән булып фольклор ансамбльләре мөнәҗәтләр һәм бәетләр белән чыгыш ясадылар. «Ак калфак» ансамбле җитәкчеләре – Геннадий Макаров һәм Алсу Еникеева. Геннадий Макаров – фольклорчы галим, музыкант, педагог. Беренчеләрдән булып балаларга мөнәҗәтләр, бәетләр өйрәтеп, күп кенә ансамбльләр төзеде. Фестивалебездә балаларга мастер-класслар оештырды. Татар халкының музыка уен кораллары белән таныштырды. Алсу Еникеева Казан дәүләт мәдәният институты педагогы, студентлары арасында тагын бер-

ничә «Җомга көн», «Дәште Кыйпчак» ансамбльләре оештырып, күп фестивальләрдә катнашып, борынгыдан килгән моңнарыбызны халык арасында пропагандалады. Алар «Сөембикә варислары» фестивальләрнең барысында да катнашып, зур җиңү яулады.

Күпме татар баласы күңеленә борынгы моңнарыбызны сеңдерде. Шушы башлангычның дәвамы булып тагын бер «Илаһи моң» фестивале туды. Аны Казан дәүләт федераль университеты һәм Рәсәй ислам университеты ярдәме белән, галимә, исламият белгече, кызым Резедә Сафиуллина җитәкләде. «Илаһи моң» фестивалендә дә Рәсәйдә яшәүче мөнәҗәтләр, бәетләр, халык җырлары җырлаучы ансамбльләр, галимнәр, әдәбият-сәнгать, илаһият белгечләре катнашып, тагын бер яңа күтәрелешкә ия булдык. Ә иң зур җаваплылыкны үз өстенә алып, инде менә биш тапкыр үткәрү мөмкинчелеге тудырган Россия Ислам университеты ректоры Рафик Мөхәммәтша улы Мөхәммәтшинга Алланың рәхмәтләре яусын!

Геннадий Макаров белән Алсу Еникееналардан күреп, татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә фольклор ансамбльләре оештырылды. Юбилей фестивалебезнең концертында да берничәсен күрү мөмкинлеге булачак. Чувашстаннан Фәрит Гыйбатдинов «Мин һичшиксез юбилей концертында ансамблем белән катнашачакмын, Илнар Хисамов сәнгать җитәкчелегендәге «Тамчы» балалар фольклор ансамбле төзедек бит»,– дип шатландырган иде. Менә бит дөньялар ничек, халкыбызга үзен аямыйча, ихлас хезмәт иткән бөек җаннар китеп бара... Сүзебез дога, урыны җәннәттә булсын! Ижау шәһәреннән Лариса Гайнетдинова җитәкчелегендә «Асылъяр» ансамбле катнашачак. Шушы жанрда эшләп килүче тагын бер кызыбыз – Лилия Җиһаншина җитәкчелегендә дә, Казан консерваториясе каршында фольклор төркеме инде байтак еллар халкыбызга хезмәт күрсәтә. Бу – иҗатчыларыбызның асылыбызга, тамырыбызга кайтуы, бабаларыбызның халык авыз иҗатында сакланып калган ялкынын сүндермичә яшәтүе.

Фестивалебезнең тагын бер номинациясе – ул да булса, гамәли сәнгать. Анда балалар үзләре ясаган Сөембикә рәсемен һәм башка бик күп төрле темаларны колачлаган рәсемнәрне, үз куллары белән ясаган курчаклар, сувенирларны алып килде. Бу балаларның күңел бизәкләре шунда ук төрле чараларда катнашучыларга бүләкләр булып таралып бетте. Әле дә хәтеремдә – фойеда мастер-класс оештыручы ханымның (ни кызганыч, исеме истә калмаган) 5 минут эчендә төрле чүпрәкләрдән матур курчаклар ясарга өйрәтүе. Кызлар барысы да үз курчакларын ясап, өйләренә алып кайтып китте. Балаларның күзләрендәге куанычны әйтеп бетерлек түгел!

Араларында иң бәхетлесе, әлбәттә, мин идем! Тормыш, фестиваль тәгәрмәче без дигәнчә тәгәри, Алла кушканча, хакыйкый юлдан барабыз. Миңа да үз гыйлемемне, тәҗрибәмне, энергиямне балаларга бирергә на-

сыйп булды. Бу бәхет түгелмени?! Сөембикә варислары бүген дә яши, милләткә хезмәт итә, матур гаиләләр кора, татарның генофонды дәвам итә. Бу өлкәдә, шөкер, үз өлешебезне керттек. Ходай кабул итсен! Ул яшь агачлар инде яфрак ярды, чәчәккә бөреләнде, таза, матур җимешләр дә бирер, иншалла! Шушы изге эшне башлап җибәргәндә матди ярдәм салган «Кара алтын» банкы җитәкчесе Ринат Абдуллинга, балаларны Кырымга кадәр килергә юл һәм яшәү чыгымнарын үз өсләренә алган җирле җитәкчеләргә, эшмәкәрләргә, әти-әниләргә, укытучыларга, сәнгать җитәкчеләренә, иң авыр вакытларда матди һәм рухи ярдәм күрсәткән «Шәһри Казан», «Әниен-Мама» газеталары баш редакторы, җәмәгать эшлеклесе Хәлим Гайнуллинга, Арча якташлык җәмгыяте рәисе Тәлгат Шиһабиевка, «Карамай» ширкате җитәкчесе Алимас Вәлиевкә һәм вакытында безне матбугатта яктыртып килгән Республиканың барлык газета-журнал редакторларына, журналистларына, волонтерларга, Сәидә абыстаебызга олы рәхмәтләремне белдерәм! Телебез, динебез яшәр! Ватаныбыз сау булсын! Алдагы көнгә, Аллаһы Тәгаләгә, үзебезгә, ышанычыбыз артсын! Безне алдап, хәйләләп туры юлдан яздыра алмасыннар! Хакыйкый гыйлем аша асылыбызны табарга Ходай ярдәм итсен! Шул чагында тел дә, дин дә, Ватан да һәм без дә яшәрбез! Авылларыбызны, үзебезгә бүленеп бирелгән кечкенә генә булса да кара туфрагыбызны, туган җиребезне саклыйк, бер-беребезне сатмыйк, бабаларыбызның ышанычын аклыйк, шушы юлда Аллаһы Тәгалә үзе безнең таянычыбыз булса иде! Амин! Бабаларыбыз калдырган тере, саф, мең яшәр орлыкларны чәчеп, тере күзәнәкләребезне саклап, туган җиребездә Ватан кадерен белеп яшәргә насыйп булсын!

Һәр халык үзенең тамырын онытмыйча, барлап яшәсә генә үз милләтен, ана телен, гореф-гадәтләрен саклап кала ала. Үзенең кем икәнен белмәгән, үзен хөрмәт итмәгән милләт башка халыкларны да хөрмәт итә, ярата, кабул итә алмый. Безгә иң әүвәл үзебезнең кем икәнебезне аңлау, үз аңыбызны үстерү кирәк. «Сөембикә варислары» фестивале нигез буларак менә шуңа таяна. Минем хыялым – төрле елларда үткәрелгән «Сөембикә варислары» фестиваленең лауреатларын Казанда зур, матур залга җыеп, гала-концерт үткәрү.

Соңгы елларда фестивалебезнең 20 еллык юбилеен Казанда уздыру өчен матди ярдәм күрсәтүен сорап, Рәисебезгә берничә хат язган идем, кызганыч, җавап булмады. Күрәсең, хатлар аңа барып җитмәгән. Рәис белән ике арада Кытай стенасы һәм терракот армиясе кебек түрәләр тора. Аларны үтеп булса, Рәисебез, һичшиксез, безне ташламас дигән олы өметтә калам.

*2021–2023 еллар.*

## ТӨБӘК ТАРИХЫ БУЕНЧА КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР ҺӘМ ОЧРАШУЛАР
## ХАТЛАР ҺӘМ КАЙТАВАЗЛАР

## КРАЕВЕДЧЕСКИЕ КОНФЕРЕНЦИИ И ВСТРЕЧИ
## ПИСЬМА И ОТКЛИКИ

### ПИСЬМО В РЕДАКЦИЮ

*(Отклик на статью Балгынай Норлан «Чәүчәккә сәяхәт».*
*Туган җир. Родной край. №3, 2019)*



**Главному редактору журнала Туган жир.**

В одном из выпусков Вашего журнала была статья про род Чанышевых. Я, Чанышева Альмира Ахмедулаевна, являюсь внучкой Хасанбая Чанышева и правнучкой Рамазан хаджи Чанышева. В этой статье было написано, что у Рамазан хаджи были дети. В действительности, у него не было родных детей, а были племянники – Хасанбай и Хусаинбай, которым он передал своё состояние. Сам же он занимался строительством мечетей. Одна из них – Красная мечеть, которую он построил в КНР в городе Чугучаке. В той же статье было написано, что он построил Красный дом, хотя на самом деле её построил мой дед – Хасанбай Чанышев. Прошу проверить информацию, поднять архивы... Самое главное, автор

статьи утверждает, что он является потомком рода Чанышевых, а на самом деле не имеет отношения к нашему роду.




Мы знаем свою историю. Фамилий Чанышевых много, как и Ивановых. Нам очень обидно, ибо это наша история и мы бы хотели, чтобы к ней относились с уважением. Историю моих предков не искажайте, прошу вас.



Автобиография.

Я, Чанышев Ахмедолла Хасанович, родился 5 декабря 1911 г. в г. Чугучаке КНР в семье торговца.
По национальности – татарин.
С 1920 г. – 1928 г. учился в г. Чугучаке в Духовной школе (Медресе)
С 1928 – 1950 гг. занимался частной торговлей в городах Чугучак, Урумчи, Турфан.
В 1950 г. переехал в г. Чугучак начал заниматься скотоводством, где и прожил до августа 1962 г.
3 августа 1962 г. по визе № 625659 переехал границу из КНР в СССР через погранпункт Бахты.
В 1929 г. женился в г. Чугучаке на Чанышевой Афифе Хуснудиновне, от этого брака имею детей:
дочь – Чанышева Раифа Ахмедоллаевна – 1935 г. рожд. в настоящее время проживает в г. Урумчи в КНР.
дочь – Чанышева Разия – 1939 г. рожд.
дочь – Чанышева Айша – 1941 г. рожд.
В 1943 г. жена Афифа умерла по болезни.
В 1953 г. вторично женился на Мухамедрахимовой Наиле Хасиджановне гр-ке СССР 1920 г. рожд. От второго брака имею детей:
дочь – Чанышева Альмира – 1955 г. рожд.
сын – Чанышев Наиль – 1958 г. рожд.
Мои родители:
Отец – Чанышев Хасан Нигматуллаевич родился 1872 г. в Тамбовской обл. Пурдашенский р-он село Дусай
В Китай выехал из России 1890 г. по торговым делам.
Умер 1939 г. в г. Урумчи.
Мать – Чанышева Гульсум Хасановна родилась в 1890 г. в Тамбовской обл. Пурдашенский р-он село Дусай, 1904 году вышла замуж за моего отца и приехала в Китай в г. Чугучак
В настоящее время проживает в г. Аягуз Семипалатинской обл.



В настоящее время в семье имею:
Жена – Мухамедрахимова Наиля Хасиджановна, татарка, 1920 г. рожд.
Дети – Чанышевы:
дочь – Разия, татарка, 1939 г. рожд.
дочь – Айша, татарка, 1941 г. рожд.
дочь – Альмира, татарка, 1955 г. рожд.
сын – Наиль, татарин 1958 г. рожд.
В настоящее время проживаю в Алма-Атинской обл. село Каскелен ул. Карла-Маркса дом № 24.
Подпись: (Чанышев)
3/IX-62 г.

## АЛТЫН БАГАНАЛАРЫБЫЗНЫҢ БЕРСЕ

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында оештырылган «Золотоордынское обозрение» халыкара фәнни журналының нәшер ителә башлавына 10 ел тулды. Шул уңайдан институтта редколлегиянең киңәйтелгән тантаналы утырышы үтте.

Бу – татар халкының этногенезын өйрәнүгә, татарны саклауга зур өлеш кертүче журнал. Милләтебезне саклаучы алтын баганаларыбызның берсе. Аңа озын гомер телибез, кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Тарих институты директоры Радик Салихов басмага менә шундый зур бәя биреп утырышны башлап җибәрде.

Үз чиратында журналның баш мөхәррире, институттагы Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев, узган дистә елдагы эшчәнлеккә кыска гына күзәтү ясады. «Шушы дистә ел эчендә 600дән артык мәкалә бастырганбыз. Авторларыбызның күпчелеге – җитди, зур галимнәр. Эшчәнлегебезне башлаганда, бигрәк тар юнәлеш бит бу, озак дәвам итә алырсызмы, дип шик белдерүчеләр булды. Илдә кризис, акча юк ич, дип тә әйттеләр. Әйе, темабыз тар, димәк, тирәнрәк «казырга» кирәк. Яхшы идея булса, акча табыла»,– дип белдерде ул.

– Бу журнал – уникаль күренеш, аны тудыру – шактый җитди эш. ВАК, Скопусларга кертү ансат түгел. Аның формаль таләпләре күп. Миңа Алтын Урда цивилизациясе дигән тема, төшенчә бик ошый. Бу журнал эшчәнлегендә үзем дә катнашырга, мәкаләләр биреп барырга тырышам. Без бит шушылай күп кенә мәсьәләләрне актуальләштерәбез, чынбарлыкта популярлаштырабыз,– дип Казан Мәдәният университеты проректоры, тарих фәннәре докторы Рафаэль Вәлиев журнал исеменә мактау сүзләре яудырды.

КФУ профессоры, тарих фәннәре докторы, «Тюркологические исследования» журналы баш мөхәррире Раил Фәхретдинов та мактау сүзләрен кызганмады. Шул ук вакытта галим: «Күрше-тирә республикалар, тугандаш халыклар безнең тарихны үзләштермәкче була. Мондый омтылышларга журнал үз вакытында җавап биреп барсын иде. Дөрес, мондый җаваплар бар, әмма алар күбрәк булсын иде»,– дигән теләген җиткерде. Моңа җавап итеп дигәндәй, online тарих фәннәре кандидаты, АБДИ Гуманитар тикшеренүләр интитуты директоры, Алматыда нәшер ителүче «Qazak Historical Review» журналы баш мөхәррире Канат Уксенбай, журнал төрле бәхәсләргә кермичә, уртада кала белә, дип белдерде. Аның ватандашы, Казакъстан Республикасының Фән һәм мәгариф министрлыгы каршында эшләүче Җучи Олысын өйрәнү институты директоры, фәлсәфә фәннәре докторы Җаксылык Сабитов та: «Журнал урталыкта

тора, читкә бәрелми, дип ватандашын хуплады. Дөрес, ул, беркемнең дә хакыйкатькә монополиясе юк, журнал төрле фикергә, үзгә карашларга урын бирә»,– дип тә өстәп куйды.

Россия Фәннәр академиясенең Россия тарихы институты өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Илья Зайцев: «Ун ел – журнал өчен шактый зур вакыт ул. Ун ел эчендә күп кенә журналлар туалар да үләләр, чыгудан туктыйлар. Басмабыз хәзер җитлекте, пик дәрәҗәсенә җитте, авторларны, мәкаләләрне сайлап алуга җентекләп, зур игътибар белән карый. Киң мәйданны, күп илләрнең галимнәрен берләштереп, җыеп тора. Журнал Алтын Урда яшәгән хәтле яшәр дип уйлыйм»,– дип басмага озын гомер теләде. Курган дәүләт университетындагы Гуманитар фәннәр институты директоры, тарих фәннәре кандидаты Денис Маслюженко журналга ун мәртәбә ун ел, ягъни йөз ел гомер теләгәннән соң, төрле төбәкләрдә эшләүче Алтын Урданы өйрәнүчеләрне бер мәйданда җыйганы, берләштергәне, төрле чыганакларны бастырганы өчен Илнур Миргалиевкә рәхмәт җиткерде.

– Башкортлар үз эчләренә йомылу ягын карады. Без ачылдык. Конкуренциясез, төрле идеяларга колак салмыйча, үсеп булмый. Безгә берникадәр конкурент булган казакълар да үсә. Әмма, әйтергә кирәк. Институт финанс ягыннан шактый кыен хәлдә. Татарстан Фәннәр академиясе журналны финанс ягыннан хупласа иде,– дип тарих фәннәре докторы, «Туган җир» журналы баш мөхәррире Дамир Исхаков басманың матди хәлен кайгырту зарурлыгына, аерым алганда, тиражның бик кечкенә булуына да тукталды. Ул, Алтын Урдабызның күчмәннәр цивилизациясе генә түгел, нык үскән, шактый алга киткән шәһәр цивилизациясе дә икәнлеген тәкрарлап, эпик әсәрләрне, тәгаен алганда, дастаннарны анализлау аша да, күп кенә материалларны фәнни әйләнешкә кертеп булачагын, әлегә Алтын Урда цивилизациясе чыганакларын яктыртуга игътибар җитеп бетмәвен искәртте.

Журналның һәр санында бәхәс тудыра торган мәкаләләр чыга. Яңа сан дөнья күргә, әйдә, мин җавап язам, мин килешмим, үз фикеремне язам, дип шылтыраталар. Татар тарихы төрле яклап яктыртылырга тиеш. Кайчагында бик үк уңай булмаган фикерләр дә ишетергә туры килә. Бу гаҗәп түгел. Без журнал сәхифәләрендә тарихыбызны тергезергә тырышабыз. Баш мөхәррир тантаналы утырышны менә шулай йомгаклап куйды.

*Рәшит Минһаҗ*

## ХРОНИКА

1–2 декабря 2023 г. в Тобольске состоялась Всероссийская научно-практическая конференция «Сибирские Валеевские чтения», посвященная 105-летию д.и.н. Фоата Тач-Ахметовича Валеева. По ходу конференции были прочитаны 18 докладов, в числе которых и доклады ученых из Казани: д.и.н. Д.М. Исхакова «Кыпчакское этническое составное в этногенезе сибирских татар: реальность или историографический фантом?», д. филол.н. О.Р. Хисамова «К вопросу о языковой идентичности волго-уральских и сибирских татар», к. филол. н. Ф.Х. Завгаровой «Мифологические образы в татарских дастанах», к.и.н. И.З. Гарифуллина «Дискурс о так называемом «северо-западном» диалекте башкирского языка». В рамках мероприятия состоялись выставка работ по мотивам сибирско-татарских сказок А.А. Закорюкиной-Рахимовой, презентация мусульманских метрических книг и «Словника», а также отчетный концерт ансамбля «Яшьлеккә сәяхәт» в ЦСТК Тобольска. Организатором конференции являлась с.н.с. ТКНС УрО РАН к.и.н. член редколлегии журнала «Туган җир. Родной край» З.А. Тычинских.

В с. Нижняя Майна Спасского района РТ 9.12.2023 г. состоялась республиканская научно-практическая конференция на тему «Проблемы изучения, сохранения и популяризации культурного наследия татарского народа» при участии краеведов ряда районов республики. В работе приняли участие ученые из Казани доктора исторических наук Ф.Г. Ислаев, Д.М. Исхаков, Ф.Х. Хузин, к.и.н. Ф.А. Байрамова. Н.Г. Гариф, А.З. Нигамаев и др. Конференция прошла организованно, краеведу Рафику Гумеровичу Насырову было вручено благодарственное письмо от журнала «Туган җир. Родной край».

10–13.12.2023 г. в Москве состоялась Международная научно-образовательная конференция «XX Фаизхановские чтения», посвященная 200-летию со дня рождения Хусаина Фаизханова и Году педагога и наставника в РФ. В рамках конференции состоялись выступления с докладами членов редколлегии журнала «Туган җир. Родной край» д.и.н. Д.М. Исхаков (тема: Открытие булгарского языка в переписке Хусаина Фаизханова с Шигабутдином Марджани), к.и.н. З.А. Тычинских (тема: Роль представителей дворянского сословия в общественном мусульманском движении начала XX в. в Западной Сибири), к.и.н. А.А. Бурханова (тема: Изучение жизненного пути, деятельности, творчества, подвига и

вклада в духовно-культурную жизнь народа и страны выдающихся деятелей татарского народа и увековечивание их памяти и наследия), а также других известных татарских ученых из Татарстана. В конце конференции была принята резолюция, направленная на сохранение и исследование творческого наследия Х. Фаизханова.

### В Институте Истории им. Ш. Марджани прошел Круглый стол посвященный основателю первого татарского радио

18 декабря в Институте истории им. Шигабутдина Марджани АН РТ состоялся круглый стол, посвященный «Общественному и культурному наследию Шамиля Усманова».

Мероприятие было приурочено к 125-летию со дня его рождения. Шамиль Усманов известен в истории как общественный и военный деятель, писатель и родоначальник татарского радио. В круглом столе приняли участие не только научные исследователи из Казани, но и зарубежный ученый из Японии, целенаправленно занимающийся жизнью Шамиля Усманова.

С приветственной речью к участникам обратился доктор исторических наук, директор института истории им. Ш. Марджани АН РТ Радик Салихов. Он отметил, что личность Усманова важна и интересна для нашей академической науки в первую очередь с точки зрения становления и развития советской государственности Татарстана, который опирался на культурные и образовательные традиции предшествующего периода.

Далее слово дали известному историку, академику АН РТ Индусу Тагирову. Он остановился на роли вообще всех значимых татарских фигур, участвовавших в рождении и становлении Татарстана. Среди них и был Шамиль Усманов.

Первым с докладом об одном из автобиографичных произведений Усманова выступил профессор Центра славянских и евразийских исследований Университета Хоккайдо Норихиро Наганава.

В романе «Легион юлы – тургай далаларында», опубликованном на латинице комиссаром красной армии Шамилем Усмановым, автор без прикрас рисует суровые картины Гражданской войны, воссоздав образы тех, кто в кровопролитных боях утверждал Советскую власть.

«Жизненный путь Усманова после гражданской войны шел в ногу с советским стремлением, что открывало перед мусульманской интеллигенцией широкие, пусть и контролируемые возможности для развития национальных культур. Один из ключевых моментов романа заключался в межнациональной розни и напряженности. Этот горький опыт заставил

Усманова задуматься о необходимости создания собственного татарского военного формирования, что позже воплотилось в марте 1919 г. в Первой отдельной татарской стрелковой бригаде»,– отметил Наганава.

Шамиль Усманов стал руководителем строительства первой татарской радиостанции, которая была построена на Арском поле. Там была организована студия, откуда в 1927 г. на 10-летие Октябрьской революции в эфир вышла пробная передача, вошедшая в историю татарского радио. Тогда именно голосом Шамиля Усманова в эфире прозвучала легендарная фраза: «Казан сөйли!» («Говорит Казань»).

Будучи человеком романтичным и мечтательным, Усманов выходил и с идеями, опережавшими свое время. К примеру в 1925 г. он написал фантастический роман «Радио с Памира», где предвосхитил идею создания телевидения, но об этом факте, к сожалению, у нас мало кто знает.

С большим докладом о наследии Шамиля Усманова из личных архивов его семьи выступила кандидат медицинских наук, доцент кафедры реабилитологии и спортивной медицины Марина Подольская.

В частности, ею были представлены отрывки из пока еще не опубликованного, а потому уникального дневника Шамиля Усманова, написанного им в период с 1924 по 1931 гг. Усманов много писал о своих родителях и семье, фантазировал о том, какой станет Казань через 10–15 лет, предвосхищая то, что в городе вырастут большие широкие проспекты.

Кандидат исторических наук Ильнар Гарифуллин рассказал о роли Шамиля Усманова в создании Первой татарской стрелковой бригады.

«В январе 1919 г. Центральная мусульманская военная коллегия приняла решение о создании в Казани, Самаре и других поволжских городах мусульманских военных частей. Инициатива Шамиля Усманова о формировании мусульманского полка на базе интернационального легиона не была поддержана Реввоенсоветом I Армии. Шамиль Усманов обратился в военную коллегию Центрального мусульманского комиссариата в Москве с просьбой поручить ему организацию отдельной татарской бригады. Пропаганда, проводимая не на родном языке, «не может оказать должного действия на безграмотных татар,– пишет он. – Основные массы их не могут поэтому получить настоящее революционное воспитание. Агитация же на родном языке не проводится из-за недостатка пропагандистов... Единственный путь для воспитания татарских красноармейцев – формирование больших татарских частей».

Республиканский Военно-революционный комитет принял решение о формировании Первой отдельной Приволжской татарской стрелковой бригады 24 марта 1919 г. Шамиль Усманов был утвержден политкомиссаром бригады. Вскоре был получен приказ Реввоенсовета об организа-

ции Отдельной татарской бригады. Комиссаром ее назначили Усманова» – сказал И. Гарифуллин.

25 декабря 2023 г. в музее Н.И. Лобачевского в К(П)ФУ состоялся круглый стол на тему «Актуальные проблемы современной этнографии», посвященный 100-летию видного татарского этнографа Р.Г. Мухамедовой – одного основоположников современной этнологической науки в КНЦ (КФ) АН СССР и руководителя отряда татарских этнографов, работавших в ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова над составлением «Историко-этнографического атласа татарского народа» в 1970-1990-х гг. Мероприятие проводилось в рамках «Года педагога и наставника» в РФ и «Года национальных культур и традиций» в РТ и сопровождалось открытием специальной, весьма качественной, выставки «Атлас жизни Рамзии Мухамедовой». Принявший участие в работе круглого стола гл. редактор журнала «Туган җир. Родной край», д.и.н. Д.М. Исхаков сделал на данном мероприятии выступление на тему «Становление татарского академического отряда этнографов и его исследовательская деятельность в 1970 – 1990-х гг. (воспоминания о жизни советских этнографов)».

Главный редактор журнала «Туган җир. Родной край», д.и.н. Д.М. Исхаков 22.12.2023 как делегат принимал участие в работе Внеочередной конференции РАЕН (г. Москва). В ходе мероприятия состоялись внесение изменений в устав данной общественной организации, выборы президента РАЕН (им стал П.И. Бурак), утверждение концепции ее развития и ряд др. вопросов. Были также заслушаны доклады ведущих ученых, а также отдельных руководителей комитетов Гос Думы РФ.

## ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН ХЕЗМӘТЛӘР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ. РЕЦЕНЗИЯЛӘР

## ИНФОРМАЦИЯ О КРАЕВЕДЧЕСКИХ ТРУДАХ. РЕЦЕНЗИИ

### ЯҢА КИТАП




**Служилые и ясачные люди в России XV – XIX вв.: особенности землевладения, сословные номинации: сборник статей / под ред Г.Х. Самигулова. Вып. 1. – Челябинск: Библиотека А. Миллера, 2022. – 195 с.**

Сборник представляет собой первую попытку собрать вместе исследования по таким, казалось бы, разным группам населения России, как служилые и ясачные люди. Представлены работы, рассматривающие ситуацию на больших пространствах – от Подмосковья до Центральной Сибири и охватывающие достаточно длительный период – от XIV до XIX в. Ряд работ демонстрирует, насколько тонка была граница между служилым и ясачным населением.




**Политическая история Тюменского ханства в 1430–1508 гг.: монография / А.В. Парунин. – Челябинск: Фонд содействия сохранению культурного наследия «Общественный фонд «Южный Урал»», 2023. – 247 с.**

Монография посвящена истории первого государственного образования на территории юга Западной Сибири – Тюменского ханства. В книге освещаются вопросы предпосылок и зарождения государственности в регионе, раскрываются этапы становления политической власти, исторической жизни правителей. Основное внимание уделено внешнеполитическому аспекту истории Тюменского ханства, связанному с общим состоянием источниковой базы. Отдельное внимание посвящено краткому описанию и анализу письменных источников, изучению достижений историографии. Расцвет и падение ханства прослежено сквозь призму военно-политического союза с лидерами Ногайской Орды.

# МИЛЛИ АШЛАР, СӘЛАМӘТЛЕКНЕ САКЛАУ ЮЛЛАРЫ

# НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ, ПУТИ СОХРАНЕНИЯ ЗДОРОВЬЯ

*Фирая Захарова*

## ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫ

**Нерв системасы**

Без барыбыз да төрле-төрле. Берәү тормышта килеп чыккан кыенлыкны ансат кичерсә, икенче берәү аны фаҗига итеп кабул итә. Кешегә әйләнә-тирәбездә даими үзгәреп торучы шартларга, борчу-мәшәкатьләргә әллә ни зур көч куймыйча да яраклашу сәләте бирелгән.

Борчу мәшәкатьләр бихисап: яңа яки үзгәреп торучы вируслар, һаваның, суның, туфракның пычрануы, зур, даими электромагнит нурланышлары, азык-төлекнең сыйфаты, дөньядагы сәяси вакыйгалар, җәмгыяви, табигатьтәге тетрәнүләр...

Тышкы мохиттә җавапсыз калдырмауны таләп итә торган конфликтлы вәзгыятьләр килеп чыкканда матдәләр алмашын активлаштыручы, нерв-мускуллар, гормоннар, кан тамырлары системасын эшкә җигүче йөзләрчә биохимик реакция туа. Бу җәһәттә Канада галиме Ганс Сельеның хезмәтләре бик зур әһәмияткә ия. Ул галимнәр арасында гомум яраклашу синдромын тикшерүче, универсаль ярсу-стресс концепциясе авторы буларак яхшы мәгълүм. «Стресс» сүзенең инглиз теленнән тәрҗемәсе киеренкелек, басым ясау, ярсу мәгънәсен белдерә. Нәкъ менә аны стресс һәм дистресс теориясенә нигез салучы дип исәплиләр (әлеге газаплану халәтендә килеп туган киеренке шартларга кеше җайлаша алмый һәм чыгырыннан чыга). Бу халәт дәвамлы киеренкелеккә әйләнергә ихтимал. Стресс-ярсуның физиологик гәүдәләнеше дә мәгълүм («Будь здоров» журналы, № 8, 2003).

Организмның тыныч, тотрыклы халәте канда күпме кортикоид булуга – бөер өсте бизе кабык матдәсе эшләп чыгара торган гормоннарга бәйле. Әгәр алар җитәрлек икән, нинди генә тышкы тәэсир булмасын кеше тынычлыгын җуймый. Тышкы йогынты артканда, эчке кичерешләр көчәйгәндә тагын да күбрәк кортикоидлар таләп ителә. Ярсытучы (бу теләсә нинди вакыйга, дулкынлану, әйләнә-тирәдәге тәэсир ясаучы

булырга мөмкин) бик нык яисә озак вакыт басым ясый икән, бөер өсте бизе кабык матдәсенең куәте бетә.

**Ганс Селье ярсуны өч мәлгә бүлә**

**1 нче мәл** – хәвефләнү. Ярсыткыч тәэсирендә гипоталамус – гипофиз – бөер өсте бизе кабыгы системасы активлаша. Бу үз чиратында бөер өсте бизенең эчке катлавында ясала торган гормоннарның – адреналин биз сыекчаларының күтәрелүенә, кандагы шикәрнең артуына, аның бавыр, мускуллардагы запасларын җәлеп итүгә китерә. Сизү, тою әгъзалары сагая, авыз эче кибә, маңгай, уч төпләре, аяклар тирләп чыга. Талак кан агышына тагын да күбрәк кан күзәнәкләрен куа.

**2 нче мәл** – яраклашу, каршы тору. Бу стадиядә әлеге вәзгыятьне ничегрәк йомшарту яки аннан котылу, арыну юлын эзлиләр. Кортикостероидларның биз сыекчалары көчәя. Алар хәвефләнү халәтен йомшарта. Иммун системасы да эшчәнлеген үзгәртеп кора. Организм кабат тотрыклылык халәтенә килә. Киеренкелек-стресс, икеләтә стресс (дистресс) халәтеннән аермалы буларак, яраклашу, җайлашу стадиясе белән тәмамлана.

**3 нче ахыргы мәл** – икеләтә киеренкелек стадиясе – талчыгу, йончу. Бу очракта организм бирешә, каршы торучанлыгын җуя. Җайлашу механизмнары калмау билгесе – ару, таркаулык, төшенкелек. Моннан тыш тән төзелешендә, әгъзалар эшчәнлегендә психик тайпылышлар килеп чыгарга мөмкин. Болар: тәнгә тимгелләр чыгу, баш, арка авырту, мускулларда көзән җыеру, еш сулыш алу, тын кысылу, йокы, ашкайнату тракты эшчәнлеге бозылу. Әлеге мәлне чирләп китү алды дип тә әйтәләр.

Ни гаҗәп, уңай, шатлыклы вакыйгалардан соң да кайберәүләрдә стресс халәте күзәтелә. Аның билгеләре алда санаганча булуы ихтимал. Әлеге кыска вакытлы уңай киеренкелекне организм җиңел кичерә. Ул рәхәт тынычлану, алга таба яхшы үзгәрешләр көтү, иммунитет күтәрелү белән тәмамлана.

Әле тагын гиперадаптация, ягъни артык җайлашу халәте дә бар. Мондый шартларда организм тышкы ярсыткычларга җавап бирүдән туктый, үз эченә йомыла. Бу халәткә таркаулык, үз-үзеңә ышанмау, төшенкелек, бар нәрсәгә чиркanып карау хас. Әлеге очракта яшәү рәвешеңне, һөнәреңне, максатларыңны тамырдан үзгәртү таләп ителә. Хәзерге тикшеренүчеләр киеренкелек халәтенең кайбер мөһим минераль матдәләр – магний, калий, цинк, хром һ.б.ның кытлыгына китерүен ачыклаган. Кыска вакытлы ярсу вакытында тәүлеклек магний (Mg) нормасының 80 проценты сарыф ителә икән. Бу хәл үз чиратында йөрәк-кан тамырлары системасында авырулар китереп чыгаруы ихтимал. Калийның (K) түбән булуы психик һәм физик талчыгу, бөер һәм бөер өсте бизләренең эшчәнлеге бозылу, лайла

ясалучы – мерокрин бизләрдә ялкынсыну башлану ихтималы (кутырлы яра һ.б.) турында сөйли. Цинк (Zn) җитмәү иммунитет кимүгә, хром (Cr) җитмәү йөрәк мускуллары һәм кан тамырлары эшчәнлеге бозылуга (еш кына бу хәл шикәр чире һәм катаракта башлануга ишарә) китерә («Будь здоров» журналы, №8, 2003).

Гомумән алганда, кешенең тән һәм психик халәте бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнештә тора. Икенче төрле әйткәндә, кешенең бөтен тормыш юлы тән һәм психикасының бергәлеге (психосоматика), бергәләп эшчәнлеге ул. Нерв системасындагы тайпылышлар күп кенә эчке әгъзаларга күчә. Болар – уникеилле эчәктәге, ашказанындагы җәрәхәтләр, күрүдәге кыенлыклар, йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары. Зур курку бөер авырулары китереп чыгара, сагыш ашказаны асты бизе эшчәнлеген боза, үпкә, рәнҗү үпкәгә зыянлы, ачу, нәфрәт йөрәккә, бавырга «суга», дип исәплиләр. Бронхиаль астма (бума чире, өянәге кабатланучан тын бетү авыруы) вакытында буылу өянәге хисси ярсытырга мөмкин. Психосоматика күзлегеннән нейродермит, ревматизмнарның ни сәбәпле килеп чыгуын аңлатырга була. Мәгълүм ки, курку, нәфрәт, көнләшүнең (бигрәк тә озак вакыт дәвамында кичерелсә) аналыктагы авыруларга, псориаз, простатит, колит, онкологиягә китерүе ихтимал. Моның өстенә кайберәүләрдә аңлаешсыз, озак вакытлы ару, кулларда, аякларда хәлсезлек күзәтелә. Гәүдәнең төрле җирләре – башы, аркасы сызлый; ашкайнату тракты бозыла: эч китү, эч кату, кысылу күзәтелә (мондый билгеләре булган кешеләр бик еш очрый хәзер). Кайберәүләрдә моның бөтенесе бергә күзәтелә. Мондый хәл неврозга – үз-үзеңне кулда, тәртиптә тота алмауга китерергә мөмкин. Андый кеше «тартылган җәя» халәтендә яши, вак-төяк мәшәкатьләр дә кәефен төшерә. Шушы рәвешле гасабилануның еш кабатлана торган газаплы халәте – йокысызлык барлыкка килү ихтимал. Баш мие көн дәвамында булган вакыйгаларны әледән-әле әйләндереп, кабатлап тора, йоклап киткәч тә начар төшләр керә. Нәтиҗәдә йокы туймый, баш авырта, гәүдә авырая...

Катгый фикерләү, ваклану, кинәт кәеф үзгәрү, теләсә нинди очракта кисәк җавап кайтару, тиз үпкәләү, тәнкыйтьне кабул итмәү әйләнә-тирәдәгеләрне сагайтмый калмасын иде. Гел начар кәеф белән йөрү, таркаулык, оныту, вакыт төшенчәсен югалту, карар кабул итәргә теләмәү дә үзеңне һәм якыннарыңны уйландырырга тиеш.

Әгәр шушындый хәл күзәтелсә, тиешле психотерапевтка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Кайчак махсус диета тота башлау, массажга бару, фитотерапия куллану, аутоген күнекмәсе (үз-үзеңне ышандыру, якты яшәешкә көйләү) дә булыша. Аутоген күнекмәсе ысулын 1932 елны алман психотерапевты И. Шульц тәкъдим иткән. Әлеге ысулның асылы шунда: үз-ү-

зеңне ышандыру аша гәүдәдә авырлык тойгысы уятыла, шул рәвешле релаксациягә – мускулларны йомшартуга ирешелә.

Барча авырулар да «нервадан» дип әйтсәләр дә киеренке вәзгыятьнең күпчелеген йомшартырга, җайларга мөмкин. Һәр кешенең эштә, җәмгыятьтә, гаилә һәм рухи тормышта максаты, яшәү мәгънәсе бар. Без бу дөньяга камилләшергә, күп нәрсә өйрәнергә, укырга, үзебез, гаиләбез, якыннарыбыз алдында куйган максатларны гамәлгә ашырганда тормыш сабаклары алырга киләбез. Әгәр киеренке вәзгыятьтәге хәлне үзгәртеп булмаса, аны табигый, шулай язган икән дип кабул итәргә кирәк.

Иң мөһиме: кеше һәрвакыт ни беләндер мәшгуль булсын, үзенә канәгатьләнү китерә торган эш белән шөгыльләнсен. Сер түгел, һәр кеше яраткан, белгән эше белән генә шөгыльләнми. Шуның өчен кешенең бушана, күңеленә хозурлык таба торган шөгыле булырга тиеш. Бу – һәртөрле иҗади эшләр, спорт, чыныгу, рухани кызыксынулар, күңелле һәм мавыктыргыч ял төрләре! Шул чагында үз-үзеңә, мөмкинлекләреңә ышаныч арта, яңа көчләр пәйда була һәм нерв, иммун системалары ныгый, гайрәт туплана.

Тормыштагы кыенлыкларны җиңү кыенлашса, нерв системасы чыгымлый башласа, традицион медицина ярдәме белән янәшә яки аңа өстәмә рәвештә халык медицинасы чаралары бар.

**Нерв системасын дәртләндерә торган үсемлекләр**

Неврология авыруларын үлән белән дәвалауда иләшү, җайлашу сәләтен арттыра торган шифалы үсемлекләр аерым урын тота.

***Аралия***

Аның тамырыннан ясалган төнәтмәләрне нерв системасы хәлсезләнгәндә, җәрәхәтләнгәннән соң хәл киткәндә кулланалар. Грек теленнән тәрҗемә иткәндә asthenia (астения) көчсезлек, хәлсезлек дигәнне аңлата. Мондый халәт тиз ару-йончуда, кәеф тиз алмашынуда, үз-үзеңне белештерми башлауда, түзеп тора алмауда, йокы бозылуда, физик яки акыл эшчәнлеген озак вакыт дәвам итә алмауда, каты тавышларны, көчле яктылыкны, кискен исләрне кабул итә алмауда чагыла. Мондый очракларда аралия (чертов, шип-дерева) йокыны, хәтерне, эшкә сәләтлелекне яхшырту, тиз аруны, гиперестезияне, тиз кабынып китүне дәвалау, кан тамырларындагы киеренкелекне нормага китерү чарасы буларак кулланыла. Аралияне шулай ук озак дәвам итә торган чирләрне (әйтик, тумыштан булган тайпылышларны, энцефалопатияне, миелопатияне, невралгияне, нерв-мускул авыруларын һәм башка чирләрне) дәвалаганда файдаланалар. Эпилепсия, гипертония, гиперкинез очракларында, тиз ярсып китүдән аны кулланырга ярамый. Төнге йокы бозылмасын өчен аны кичке сәгатьләрдә куллану тәкъдим ителми.

Аралия төнәтмәсе 1:5 нисбәтендә 70 процентлы спиртта ясала. Әзер төнәтмә гәрәбә төсендә, үзенчәлекле исле, шактый ук тәмле була. Аны ашау вакытында ай буе, көн дәвамында 2–3 тапкыр, 30–40ар тамчы эчәләр (кан басымы күтәрелү ихтималы булганда аны көнгә 2 мәртәбә 10ар тамчы эчәргә кирәк). Табиб күзәтүендә булса яхшырак. Дару күләмен тиешле белгеч билгели. Аралиянең барлык өлешләрендә агулы матдәләр бар. Агуланган сурәттә кеше һушын җуярга, тын алуы бозылырга, кан килергә мөмкин.

***Женьшень (тереклек тамыры)***

Тереклек тамырын тонусны яхшыртучы һәм гомум ныгытучы сыйфатында үзәк нерв системасындагы төрле авыруларны кисәтү һәм дәвалау; организмның эшкә сәләтлелек дәрәҗәсен күтәрү, киеренке вәзгыятьләргә, әйләнә-тирә мохитнең кырыс йогынтысына каршы торучанлыгын арттыру чарасы буларак кулланалар.

Женьшень шулай ук хәл киткәндә, төшенкелеккә бирелгәндә, һәртөрле невроз билгеләре күзәтелгәндә, йокысызлыктан, җенси хәлсезлектән интеккәндә нәтиҗәле чара санала. Аны кулланган күпчелек хасталарның гомуми халәте сизелерлек үзгәрә, баш авыртудан, тиз арудан, хәлсезлектән зарланмый башлыйлар, йөрәк-кан тамырлары эшчәнлеге яхшыра.

Тереклек тамыры, операциядән соң, хирургия хасталарының хәлен җиңеләйтә. Миокардиодистрофия очрагында, гастритны дәвалаганда – кан басымын көйләүче; вируслы гепатиттан, атеросклероздан зыян күргәндә иммун системасын дәртләндерүче буларак уңай тәэсир ясый, бөер өсте бизләре эшчәнлеген активлаштыра. Тереклек тамырының сезонга карап, тәэсире төрлечә. Аны көзен, кышын куллану аеруча зур файда бирә. Башка чакта аз микъдарда файдалану зарур яки бөтенләй кулланмавың хәерлерәк.

Йөрәк-кан тамырлары системасына – тахикардия очрагында, артериаль кан басымы югары булганда, борыннан кан киткәндә зыян китерүе ихтимал.

Үзәк нерв системасы җәһәтеннән – йокы бозылганда, баш авыртканда, йончыганда, ярсыганда киңәш ителми.

Ашкайнату системасында хилафлыклар булганда – укшытканда, косканда, диарея вакытында; гипогликемия, тән тиресендә аллергия күзәтелгәндә шулай ук зыяны булуы бар.

Гомумән, өянәк тотканда, көзән җыерганда, бизгәк тоту халәтендә (синдромында), 12 яшькә хәтле балаларга, йөклелек вакытында һәм имезгәндә, хроник бавыр авырулары күзәтелгәндә, калкансыман биз артыгын эшләгәндә шулай ук файдалану тәкъдим ителми.

30 г тереклек тамырын 1 литр аракыга салып төнәтмә ясыйлар. Аулакта 3–4 атна тотканнан соң, төнәтмәне сөзеп, көнгә 1–2 мәртәбә яки

3 тапкыр, ашауга ярты сәгать кала, 20шәр тамчы эчәләр. 30–40ар тамчы, табиб билгеләгән хәтле эчәргә кирәк. Гомумән, 45 яшькә чаклы эчәргә киңәш ителми.

***Сөйкемле куак (заманиха), биек эхинопанакас***

Сөйкемле куак төнәтмәсен һәртөрле хәлсезлек, төшенкелек, гипотония вакытында стимуллаштыру чарасы буларак кулланалар. Төнәтмә шулай ук баш мие кабыгы эшчәнлеген, кан тамырларын хәрәкәткә китерү үзәгенең периферия белән багланышын яхшырта.

Әлеге табигый хәл кертүченең табигате тереклек тамырына бик охшаган. Моннан тыш ул хатын-кызларның катлаулы физиологик мәле – менопауза җиткәндә аеруча файдалы. Климаксның бик күп төрле билгеләре бар – тиз ярсып китү, хәл бетү, йокы бозылу, бернәрсәгә ис китмәү, кинәт кәеф алмашыну. Сөйкемле куак төнәтмәсен даими эчкәндә әлеге тискәре кичерешләр күпкә кими.

Моның өстенә төнәтмәне куллану йөкле хатыннарда күзәтелә торган хәлсезлек (тиешле белгеч рөхсәт иткәч), аналык бизендә киста булганда уңай йогынты ясый. Күрем әйләнеше бозылганда да бу төнәтмә шактый уңышлы кулланыла.

Сөйкемле куак төнәтмәсе (70 процентлы спиртта 1:5 исәбендә ясала) – ачык көрән төстәге үтә күренмәле сыекча ул. Аны кәефне яхшыртучы чара буларак көнгә 2–3 мәртәбә ашау алдыннан, 30–40 тамчы исәбеннән, 30 көн дәвамында эчәләр. Төнәтмәне йогышлы авырулар кискенләшкән чакта, өянәк вакытында, инфаркт кичергәндә файдаланмыйлар.

***Сафлорсыман левзея яки марал тамыры***

Марал тамыры нык арыганда, төшенкелеккә бирелгәндә, начар кәеф булганда, ярсып киткәндә, баш авыртканда, йокы бозылганда, вегетатив-кан тамырлары дистониясе вакытында яхшы тәэсир итә.

Марал тамыры үзәк нерв системасы эшчәнлеген активлаштыра, баш мие кабыгына уңай йогынты ясый. Чыдамлылыкны арттыра, борчулар вакытында тотырыклылыкны сакларга булыша. Марал тамыры гипотонияне дәвалаганда кулланыла, кан тамырларын киңәйтә, стеналарын ныгыта, кан агышын көчәйтә, эшкә сәләтлелекне арттыра, хәтерне яхшырта.

Башка дарулар белән бергә эчкәндә начар йогынты ясарга мөмкин, шуның өчен табиб билгеләве мәҗбүри!

Өянәк тотканда, төрле җәрәхәтләр вакытында, артерия басымы югары булганда, хатыннарга йөклелек, имезү чорында һәм 12 яшькә чаклы балаларга куллану ярамый.

Ул үз «кардәшләреннән» әллә ни аерылмый, Себердә боланнар шуны ашап дәва тапканга аны марал тамыры дип әйтәләр дә инде. Дәвасының

сере – куәт бирүендә. Үсемлек зыян күргән күзәнәкләрне тергезә, яшәү көче бирә.

Марал тамыры төнәтмәсе 70 процентлы этил спиртына 1:5 исәбеннән тамыр һәм тамырчаларын салып ясала. Аны көнгә 2–3 мәртәбә 20–30 тамчы исәбеннән, ашау алдыннан эчәләр. Иммунитетны саклау өчен көздән язга кадәр кулланалар. Җәен кулланмавың хәерлерәк.

***Ал радиола – алтын тамыр***

Тышкы мохиттәге уңайсыз хәлләргә каршы торуны арттыручы, нәтиҗәле җайлаштыру, үзәк нерв системасын стимуллаштыру чарасы буларак халык им-томында да, рәсми медицинада да ул бик күптәннән файдаланыла. Алтын тамыр баш мие эшчәнлеген югары дәрәҗәдә саклый, баш миенең катлаулы вазыйфалар башкаруын яхшырта. Тискәре шартларга каршы torучанлык арткач, мәгълүматны истә калдыру мөмкинлеге, хәтер яхшыра. Шизофренияне психотроп матдәләр файдаланып дәвалаганда килеп чыккан тискәре күренешләрне бетерү ягыннан да уңай тәэсире бар.

Гипертония, йөрәк-кан тамырлары һәм үзәк нерв системасында каты авырулар килеп чыкканда, йөклелек вакытында, бала имезгәндә, нерв ярсучанлыгы күзәтелгәндә, тән температурасы күтәрелгәндә, 12 яшькәчә балаларга аны кулланмау хәерлерәк.

Табиб тарафыннан билгеләнгән микъдарын төгәл үтәү бик мөһим. Зыяны тимәсен өчен кирәк бу.

Алтын тамыр экстракты сыек. Аны 5–10 тамчы исәбеннән, көнгә 2–3 мәртәбә, ашауга 15–30 минут кала эчәләр. Дәвалану вакыты – 10–20 көн. Зарурлык булганда, микъдарын арттыра барып, 30–40ар тамчыга да җиткерергә мөмкин. Ул чагында дәвалану 1–2 айга сузыла.

***Чәнечкеле элеутерококк яки себер женьшене***

Элеутерококк экстракты баш миенең эшкә сәләтлелеген арттыра, физик авырлыклардан аруны киметә, күрү, ишетү сәләтен яхшырта. Хасталарның гомуми хәлен яхшырта, атеросклероз булганда холестерин һәм кан сулендәге липопротеидлар күләме кими. Җайлашу барышын арттыра, үзәк нерв системасын стимуллаштыра, йончуны, ярсуны бетерә.

Аллергия, йокысызлык, гипогликемия китереп чыгарырга мөмкин. Артерия гипертензиясе, эпилепсия авырулары вакытында, тиз ярсып киткәндә куллану ярамый; бөер, бавыр, миокард инфаркты (кан тамырлары тыгылу), йокысызлык, йөклелек кичергәндә, 12 яшькәчә балаларга куллану киңәш ителми. Йокы бозылмасын өчен аны көннең икенче яртысында, һәрхәлдә йокларга ятарга 3–4 сәгать кала кулланмау хәерлерәк.

***Кытай лимоннигы***

Хәлсезлек, төшенкелек халәтендә, эшкә сәләтлелекне киметүгә, таркаулыкка, йокы басуга, гипотониягә китерә торган реактив депрессияләр вакытында лимонник бик файдалы.

Лимонник кулланганда күрү торышы яхшыра, күп көч түгелгәндә дә талчыгу кими, төнге күрү шактый әйбәтләнә. Лимонник орлыкларын һәм төшләрен йөрәк мускуллары хәлсезләнгәндә, йөрәк «калтыраганда», бөер ялкынсынганда файдаланалар. Җимешләреннән ясалган кайнатма кандагы шикәр торышын төшерә, тукыма сулавын стимуллаштыра. Лимонник кәефне яхшырта торган кыйммәтле чара санала. Әмма аны башка дәртләндерә торган чаралар кебек үк төгәл табиб кушкан микъдарда файдалану зарур. Нервлар ярсыганда, йокысызлыктан интеккәндә, югары артерия кан басымы булганда, йөрәк эшчәнлеге хилафлыкларында аны кулланырга ярамый.

Лимонник җимешләренең төнәтмәсе (95 процентлы спиртта 1:5 исәбеннән ясала) – үтә күренмәле, куе кызыл төстә. Үсемлектән 70 процентлы спиртта 1:3 исәбеннән спиртлы лимонник экстракты да әзерлиләр. Аны ач карынга яки ашаганнан соң 3–4 сәгать вакыт үткәч, көнгә 2–3 тапкыр, 25–30 көн дәвамында эчәләр.

*Рәшит Минһаҗ тәрҗемәсе.*

## ЮБИЛЯРЛАР ТУРЫНДА СҮЗ

## СЛОВО О ЮБИЛЯРАХ

*Ш.Н. Хәлимова*

### «АК КАЛФАК»ЛЫ АСЫЛ ЗАТ



Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшләп килүче «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Кадрия Рәес кызы Идрисова турында булыр сүзебез.

Кадрия Рәес кызының тормыш юлына күз салып, моңа кадәр булган бар нәрсә – аның эшләгән эшләре, ирешкән уңышлары, яулаган үр-

ләре – барысы да бөтен дөнья буйлап татар хатын-кызларын барлап, әйдәп баручы, үз артыннан ияртүче дәрәҗәле исемне яулый алган «Ак калфак» оешмасын җитәкләүгә әзерлек булган икән.

Кадрия ханым – авыл кызы, 1958 елда Татарстанның Актаныш районы Чынык авылында туып үсә. Авылда көн итү балага кечкенәдән тормышның бар ягын төптән төшендерә, хуҗалыктагы авыр эш белән чыныктыра, башлаганның нәтиҗәсен күрерлек иттереп, җиренә җиткереп тәмамларга өйрәтеп, максатчанлык тәрбияли. Кадрия ханыма бу сыйфатлардан тыш, тәвәккәллек тә хас.

Мәктәпне тәмамлагач, алда – Казан дәүләт педагогия институты. Студент чактан ук лидерлык сыйфатлары белән башкалардан аерылып тора ул. 1981 елда Актаныш якларына кире кайтып, Сәфәр авылы урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый һәм беренче көннәрдән район җитәкчелеге игътибарын үзенә җәлеп итә. Алга таба – район үзәгендәге балалар бакчасында 14 ел буе мөдирлек хезмәтендә, 12 елдан артык Актаныш районы хакимияте башлыгы урынбасары. Гаиләсе белән Казанга килгәч, биш ел ТР Мәдәният министрлыгында эшли. Дәрәҗәле урыннарда хезмәт итсә дә, түбәнчелек, башкаларга карата игътибарлылык, ярдәмчеллек сыйфатларын югалтмый һәм алдынгы фикерле җитәкче буларак, үз эшендә моны һәрвакыт алгы планга куя. Мин «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы тарафыннан оештырылган чараларда – съездмы ул, форуммы, кучмә утырышмы – бөтенесендә диярлек катнашып килəм. Без төрле төбәкләрдә, төрле районнарда булабыз, читтәрәк урнашкан бик ерак авылларга да барып чыгабыз. Һәркайда безне шул җирлекнең ак яулыклы өлкән кешеләре каршы ала. Менә шунда Кадрия ханымның алар белән ничек җылы итеп, якын итеп исәнләшкәнен күрсәгез икән – үзебезчә, авылча ике куллап, аркаларыннан сөеп. Бу вакытта инде Кадрия ханымның гына түгел, һәркемнең йөзе балкый.

Кадрия Рәес кызы «Ак калфак» оешмасын җитәкләүгә алынуга миллилекне, гореф-гадәтләрне саклау буенча эш башлап җибәрә. Интернет, техник мөмкинлекләр җәмәгать үсеше өчен әйбәт нәрсә, тик шул ук вакытта ил белән ил, милләт белән милләт чикләрен югалтуга китерергә мөмкин. Моңа каршы торырлык көч, яшь буынны югалтмыйча, әйдәп баручы заман таләпләренә туры килә торган милли чаралар кирәк була. «Ак калфак» бергәләп киңәшү өчен Бөтендөнья татар хатын-кызлары җыеннары оештыра башлый. Менә ул алты тапкыр үтте инде. Һәр җыен программасы җентекләп төзелә, татар дөньясының хатын-кыз күзе төшмәгән, кулы тимәгән бер генә почмагы да калмый. Иң мөһиме, теге яки бу иң актуаль теманы җентекләп өйрәнү, аны һәр яктан барлау һәм яктырту

өчен дискуссия-бәхәс мәйданчыклары оештырыла. Аларны алып бару өчен танылган шәхесләр чакырыла. Без рәхәтләнеп сөйләшәбез, проблемаларны барлыйбыз, үрнәкләрне күрсәтәбез, фикер алышабыз.

Форум эшчәнлеге тагын да зуррак, яңа җыен үткәрү тәкъдименә китерә. Әйтик, 2017 елда, V татар хатын-кызлары форумында, Татар конгрессы съезд үткәрергә кирәк, дигән фикер белән чыга. Россиядә татар хатын-кызларының беренче съезды 1917 елда була. 102 елдан соң, татар хатын-кызлары иҗтимагый хәрәкәте II съезд җыярлык дәрәҗәгә ирешә, ә 2023 елда III съездга җыелдык.

– Съездларда күп кенә чит илләрдән – Австралия, Канада, Болгария, Швеция, Германия, Эстония, Гарәп Әмирлекләре, Казакъстан, Литва һәм башка чит илләрдән, шулай ук Россиянең 65 төбәгеннән, республикабыз районнарыннан делегатлар катнашты,– ди Кадрия ханым. – Беренче съездда күтәреп чыккан мәсьәләләр – хатын-кызның сәяси иреге, сайлау һәм белем алу, гаиләдәге хокукы, бер караганда, 100 ел эчендә тормышка ашты кебек, әмма көрәшеп алынган бу ирекнең башка ягы да бар бит. Хатын-кызның гаиләсенә, балалар тәрбиясенә вакыты азрак кала башлады. Хатын-кызларыбызны эштән тыш, ир хатыны, ана буларак та бәхетле итеп күрәсе килә. Гореф-гадәт, йолаларны югалтмый саклау да аның вазыйфасына керә. Безнең максатыбыз исә милли тәрбиядә буыннар алмашын тәэмин итү иде. 2023 елда татар хатын-кызларының III съезды үтте. 2023 ел Татар конгрессы тарафыннан «Дастаннар елы» дип игълан ителгән иде, шуны истә тотып, съездда «Калфак туе» үзәгенә тирән эзле мирасыбыз булган дастаннар темасы салынды. Дастаннарыбызда сәясәткә яраклаштырып үзгәртелмәгән чын тарихыбыз чагыла. Ул тарихны «Ак калфак» шәҗәрәләр аша да өйрәнә.

Кадрия ханым керткән эш алымнарының берсе – күчмә утырышлар. Алар елына 3–4 тапкыр төрле регионнарда үтә. Утырыш барышында бик күп татар авылларында булабыз, һәм мин Кадрия ханым тарафыннан күчмә утырыш формасында оештырылган чараларны, куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирә торган иң яхшы, иң нәтиҗәле эш алымы дип саныйм. «Ак калфак»ның күчмә утырышлары шундый ул: барып күргәч, яңа фикерләр туа, күтәргән мәсьәләләр күңелләрне кузгата, актара, камчылый! Бу сиңа Казанда утырып, акыллы кыяфәт белән гәп сату гына түгел!

Без, бүгенгене күз угында тотып, тарихи хәтерне югалтмаганда, бердәм булганда гына көчле. Нәрсә соң ул тарихи хәтер? Халкыбыз өчен иң аянычлы вакыйгаларны онытмаумы, сабакмы, гыйбрәтме? Көндәлектә тарихи хәтер ул башкачарак була. Мисалга Тукай районында урнашкан Чебенле авылы урынында (су басу зонасына эләгеп бетерелгән авыл)

булган бер хәлне сөйләп китәм. Австралия делегациясе составында Лилия ханым Сәмигуллина бар иде. Ул шактыйдан читтә яши, туган иленә һәрвакыт сагынып кайта. Бу юлы җирсү хисе тагын да көчлерәк иде, чөнки әбисе тумышы белән Чебенледән икән. Чебенлеләр шулай ук «Ак калфак»лыларны бик дулкынланып көткән. Чит илдән дә кешеләр булачагы кызыксыну тудыра һәм җаваплылык өсти. Чит илдән дигәннәре исә авылдашлары Кәрамнең оныгы безнең Лилия булып чыкты. Кәрам бабайның әнисе, 106 яшькә хәтле яшәгән Мәлихә апа авылда «кендек әбисе» булган. 72 яшьлек Гөлсәрия ханым Гәрәева, Лилия янына килеп, зур хөрмәт белән: «Мин синең әбиеңне белә идем»,– диде. – Әни ипи пешергәндә, һәрвакыт, монысы кендек әбиегезгә дип, кечкенәрәк итеп аерым ипи сала һәм мине Мәлихә әбигә шул ипине илтергә җибәрә иде. Авылда аны шулай итеп зурладылар»,– дип сөйләп китте.

Тарихи хәтер ул – авылның кендек әбиләрен дә онытмау, нәселен дә олылау. Гореф-гадәт ул менә шулай бөртекләп барлана. Елына берничә тапкыр үтә торган күчмә утырышларның барысы да Кадрия ханым тарафыннан җентекләп әзерләнә генә түгел, маршрут сайлангач, ул, башта аны үзе барып йөреп чыга. Без киләсе җирдә бары да ялт итеп җыештырыла. Кайсы район икәнлеге истә калмаган, берсендә, җитәкче иптәш, үз гомерендә буяу күрмәгән машина-трактор станциясе капкасына хәтле буядык дигән иде.

Кадрия ханым эшчәнлегенең бер бик матур җимешенә тукталып китмәсәм, язма тулы булмас. Ул да булса аның җитәкчелегендә чыга торган «Тәрбия баскычлары» циклы. Татар тарихында борынгыдан башлап бүгенгегә хәтле миллилеккә ачыткы сала торган тәрбияви китаплар бар, әмма яшь буын өчен аларның яңача яңгыраганы кирәк иде. Төрле өлкәдә эшли торган галимнәр һәм галимәләр, дин әһелләре фикеренә таянып эшләнгән видеопроект татар гаиләсе нигезен ныгытуга бик зур өлеш кертте инде, аның буенча алга таба да эш дәвам итә. «Ак калфак» оешмасы тарафыннан гамәлгә куела башлаган укучы кызлар һәм егетләр бәйгесе дә Кадрия ханымның иң уңышлы проектларыннан.

– Бәйге буларак, аның нигезендә мин яхшырак дигән үзара ярышу ята, әлбәттә, әмма җиңүчене билгеләгәндә биремнәр үтәлешенең бар ягы күздә тотыла: алай гына да түгел, жюри әгъзалары арасына алдагы ел җиңүчеләре дә кертелә. Үзләре сынаулар аша үтеп, бәйгенең бар нечкәлекләре, кыенлыкларын күргән кызлар гаделлек ягына зур игътибар итә. Бу миллилекнең иң матур чагылышларын үз эченә алган күркәм чара булып кына калмыйча, олы тормыш юлына аяк басканда безнең кызлар һәм егетләр үтә торган бер имтихан да булып тора,– ди Кадрия ханым.

«Ак калфак»ның укучы кызлар һәм егетләр бәйгесенә инде сигезенче ел әзерлек бара, ә аның белән параллель рәвештә 28 – 32 мең баланы үзенә җәлеп иткән «Татар кызчыгы, татар малае» (6-7 яшьлек балалар арасында) дигән чара да татар дөньясында хуплау тапты. Анысы да Кадрия ханым проекты һәм сабыйларны татар мохитендә тәрбияләү өчен иң уңышлы бәйге.

Бу урында татар хатын-кызына кире чигү энәсен тотарга җөрьият иттергән «Сабантуй батырына – чиккән сөлгем – минем бүләгем», «Илемне саклаучыга вәгъдә-бүләгем» – чиккән кульяулык, намазлык, мендәр тышлары, чигү бәйгеләре генә дә хатын-кызны үз асылына кайтаручы гамәлләр булып тора. «Гаиләдә һәм җәмгыятьтә хатын-кызның тоткан урыны» дигән темага язучылар һәм рәссамнар арасында оештырылган бәйге татар хатын-кызына карата зурлау һәм матурлык чагылышы булды.

Авыр эшләрне башкару өчен бергәләп өмәләр үткәрү, бәйрәмнәрне туй итеп уздыру – татарның борынгыдан килгән йоласы, гореф-гадәте. Бу юнәлештә дә бишек туе, калфак туе, шәл туе, сөлге туе, каз өмәләрен кайтару ак калфаклыларның нәтиҗәле хезмәт эшләре. «Ак калфак» оешмасы кызлары көче белән татар мамык шәле һәм мендәре бренды булдырылды.

Кадрия ханымның татар халкы өчен эшчәнлегенең зурлыгын һәм тирәнлеген бер язмада гына ачып бетереп булмый, ул гаять киң кырлы, зыялы зат һәм шәхесләр елы уңаеннан аны Ватаныбызның мәшһүр шәхесе дип атап була. Татарның мәшһүр кызларының берсе – Кадрия ханым Идрисова, яки, Җитәкче булса шундый булсын!

***Юбилярны «Туган җир. Родной край» журналы редакциясе дә котлый. Кадрия ханыма бәрәкәтле озын гомер, нык сәламәтлек, бик күп шатлык-куанычлар һәм бәхет теләп кала.***

## АВТОРЛАР БУЕНЧА БЕЛЕШМӘ

**Ахунов Айдар Габделислам улы**, төбәк тарихын өйрәнүче.

**Әскәров Рамил Рәхимьян улы**, тарихчы, төбәк тарихын өйрәнүче, БР Кыйгы районының төбәк тарихын өйрәнүчеләр берлеге рәисе.

**Бәйрәмова Фәүзия Әүхәди кызы**, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

**Гарипова Хәмидә Лотфулла кызы**, педагог-журналист, тәрҗемәче, ТР Журналистлар берлеге әгъзасы.

**Җәүһәрова Фәнзилә Хәким кызы**, филология фәннәре кандидаты, доцент, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр фәнни белем бирү үзәге фәнни хезмәткәре.

**Захарова Фирая Хәмзә кызы**, үләнче, үләннәр белән дәвалаучы.

**Исхаков Дамир Мәүләви улы**, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире.

**Ишмөхәммәтова Резеда Илгиз кызы**, тарих фәннәре кандидаты, Өлкә дәүләт учреждениесе «Саратов өлкәсе дәүләт архивы» баш архивисты.

**Курчаков Рөстәм Солтан улы**, икътисад фәннәре кандидаты.

**Мәҗитов Фидаил Васил улы**, ТР Язучылар һәм журналистлар берлеге әгъзасы.

**Минһаҗев Рәшит Рәкыйп улы**, журналист.

**Нигамаев Альберт Зөфәр улы**, тарих фәннәре кандидаты, К(Идел буе)ФУның гомуми һәм Ватан тарихы кафедрасы доценты.

**Салиев Равил Зөфәр улы**, төбәкче, РФ гомуми белем бирүнең Мактаулы хезмәткәре, ТР Биектау районының төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе.

**Сафиуллина Гөлзадә Гомәр кызы**, ТРның халык артисты, Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе.

**Сәйфетдинова Эльмира Гаделҗан кызы**, тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани ис. Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре.

**Сәмитова Сәвия Гималтдин кызы**, филология фәннәре кандидаты, Казан милли тикшерену технология университеты, ике телдә белем бирү кафедрасы доценты.

**Таҗиев Дамир Нәзир улы**, Россия журналистлар берлеге әгъзасы, Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия лауреаты, Әлмәт төбәгенең җәмәгать эшлеклесе, туган як тарихын өйрәнүче.

**Хәлимова Шәмсия Нурмөхәммәт кызы**, «Киров өлкәсе татарлары конгрессы» иҗтимагый оешмасы каршындагы «Ак Калфак» татар хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе, «Киров өлкәсе татарлары конгрессы» рәисе урынбасары, журналист.

**Хөсәенов Салауат Әнүәр улы**, төбәкче.

**Хуҗин Фаяз Шәрип улы**, археолог, тарих фәннәре докторы, ТР ФА-ның мөхбир-әгъзасы.

**Шаһиева Розалина Гомәр кызы**, сәнгать белгече, шагыйрә, тәрҗемәче, рәссам. ТРның Атказанган сәнгать эшлеклесе.

## СВЕДЕНИЯ ОБ АВТОРАХ

**Аскаров Рамиль Рахимьянович**, историк, краевед, председатель общества краеведов Кигинского района РБ.

**Ахунов Айдар Габделисламович**, краевед.

**Байрамова Фаузия Аухадиевна**, кандидат исторических наук, писатель, общественный деятель.

**Гарипова Хамида Лутфулловна**, педагог-журналист, переводчик, член Союза журналистов РТ.

**Завгарова Фанзиля Хакимовна**, кандидат филологических наук, доцент, заслуженный деятель искусств РТ, научный сотрудник Научно-образовательного центра стратегических исследований в области родных языков и культур Института филологии и межкультурных связей Казанского федерального университета.

**Захарова Фирая Хамзиновна**, травник-целитель.

**Исхаков Дамир Мавлявеевич**, доктор исторических наук, академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, главный редактор журнала «Туган җир. Родной край».

**Ишмухамедова Резеда Илгизовна**, кандидат исторических наук, главный архивист Областного государственного учреждения «Государственный архив Саратовской области».

**Курчаков Рустам Султанович**, кандидат экономических наук.

**Мазитов Фидаил Василович**, член Союзов писателей и журналистов РТ.

**Мингазов Рашит Ракипович**, журналист.

**Нигамаев Альберт Зуфарович**, кандидат исторических наук, доцент кафедры всеобщей и отечественной истории К(П)ФУ.

**Сайфетдинова Эльмира Гадельзяновна**, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

**Салиев Равиль Зуфарович**, краевед-исследователь, Почетный работник общего образования РФ, председатель Общества краеведов Высокогорского района РТ.

**Самитова Савия Гималтыновна**, кандидат филологических наук, доцент КНИТУ.

**Сафиуллина Гульзада Гумеровна**, народный артист РТ, лауреат премии им. Мусы Джалиля, заслуженный деятель искусств Республики Крым.

**Тазиев Дамир Назирович**, краевед, член Союза журналистов РФ, лауреат премии имени Рафаила Тухватуллина, общественный деятель.

**Халимова Шамсия Нурмухаметовна**, руководитель татарской женской организации «Ак калфак» при областной общественной организации «Конгресс татар Кировской области», заместитель председателя «Конгресса татар Кировской области», журналист.

**Хузин Фаяз Шарипович**, археолог, доктор исторических наук, член-корреспондент АН РТ.

**Хусаинов Салават Анварович**, краевед-исследователь.

**Шагеева Розалина Гумеровна**, поэтесса, переводчик, художник, искусствовед. Заслуженный деятель искусств РТ.

# ИНФОРМАЦИЯ ДЛЯ АВТОРОВ

Редакционный совет журнала «Туган җир/Родной край» сообщает что к публикации принимаются статьи и материалы как на татарском, так и на русском языках. В этой связи обращаемся ко всем заинтересованным в развитии указанного журнала авторам с предложением принимать участие в его издании. Для этого необходимо подготовить и направить соответствующие статьи в наш адрес.

Рекомендуемая тематика публикаций:

- *методика и методология историко-краеведческих исследований;*
- *история краеведения и историко-краеведческое наследие;*
- *проблемы региональной истории;*
- *новые археологические, нумизматические, фольклорные и эпиграфические находки;*
- *публикация источников;*
- *история конкретных сел и деревень;*
- *история музеев и публикация музейных коллекций;*
- *жизнь и деятельность выдающихся краеведов и земляков;*
- *использование краеведческих материалов и музейных коллекций в школе;*
- *популярные статьи по краеведению;*
- *краеведческая хроника (конференции, встречи и т. д.);*
- *рецензии, обзоры книг на краеведческую тематику.*

*Статьи оформляются согласно указываемым ниже требованиям:*

***Технические требования к оформлению статей***

*1. Внутри публикаций ссылки оформляются следующим образом* [Аминов: 2017. С. 82.]; [Денисов: 2012. С. 25; Черкас: 2005. С. 16.]; [ГАОО. Ф. 476. Оп. 3. Ед. хр. 609. Л. 6.]

*2.* Список использованной литературы оформляются согласно ГОСТу и приводятся в алфавитном порядке в конце статьи в виде нумерованного списка:

***Источники и литература***

1. Аминов Р.Р. Татары-казаки в составе Оренбургского казачьего войска (1748–1917 гг.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 348 с.

*2.* Государственный архив Оренбургской области (ГАОО). Ф. 98. Оп. 2. Ед. 25.

3. ГАОО. Ф. 98. Оп. 2. Ед. 26.

4. Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Оренбургского края (XVIII – начало XX в.). М. – Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2012. – 410 с.

5. Черкас Т.Г. Хронограф города. Орск: [Б.и.], 2005. – 67 с.

***Редакционные требования к оформлению****:*

Инициалы и фамилия автора указываются справа, далее по центру публикации идет название статьи.

1. Текстовый редактор – Microsoft Word, в формате .doc или .docx;
2. А4;
3. Поля: слева – 3 см., справа – 1,5 см. сверху и снизу – 2 см. Нумерация страниц снизу справа;
4. Шрифт – Times New Roman;
5. Размер шрифта – 14;
6. Межстрочный интервал – 1,5;
7. Абзацный отступ – 1,0.

***Требования к иллюстративным материалам***:

Фотоматериалы и рисунки (сканкопии) принимаются только качественные (в формате JPEG, объемом не менее 3,50 МБ).

Объем публикаций в пределах от 0,5 до 1,0 п. л. (20 000–40 000 знаков с пробелами). К публикациям прилагаются аннотации из 5–6 предложений, а также выделяются ключевые слова (4–5).

***Сведения об авторе:***

1. Фамилия, имя, отчество ____________________
2. Ученая степень ____________________
3. Ученое звание ____________________
4. Занимаемая должность ____________________
6. Почтовый адрес с индексом ____________________
7. Адрес электронной почты (e-mail) ____________________
8. Контактный телефон ____________________

Редакция отмечает, что после получения статьи от автора и детального его изучения членами редколлегии, она, в случае соответствия всем требованиям, передается в печать. Если материалы не соответствуют техническим и научным требованиям, статья возвращается автору с замечаниями для устранения недостатков. В связи с большим объемом поступающих материалов редколлегия может ограничиться пересылкой автору, в случае необходимости, соответствующих правил оформления для приведения ее в соответствие с требованиями.

Редколлегия оставляет за собой право размещения публикаций в журнале согласно рубрикаций и наличия мест в выпускаемых номерах. После выхода журнала авторы статей могут получить по одному экземпляру издания.

Авторам выплачивается гонорар. Для этого необходимо вместе с материалом прислать сканкопии паспорта, ИНН, СНИЛС, счет со всеми банковскими реквизитами.

Электронная версия журнала размещается на сайтах Всемирного конгресса татар и «Всетатарского общества краеведов».

Материалы следует присылать по эл.адресу: monitoring_vkt@mail.ru с указанием темы: «Для журнала «Туган җир/Родной край». Допускается и прямая передача публикаций в редакцию, но лишь в электронных версиях. Для этого указываем адрес нашего журнала: Казань, ул. А. Пушкина, 52, офис 303, редакция журнала «Туган җир/Родной край»

# Туган җир

*Төбәк тарихы буенча журнал*

# Родной край

*Краеведческий журнал*
1’2024

Подписано в печать 22.02.2024 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 999 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов



*Галия Гайнетдинованың «Үз юлым» китабын тәкъдим итү кичәсе.*




*«Татар төбәкчеләре җәмгыяте»нең түгәрәк өстәле.*




*«XX Фаизхановские чтения». Москва.*




*Республиканская научно-практическая конференция «Проблемы изучения, сохранения и популяризации культурного наследия татарского народа». с. Нижняя Майна.*



*Совещание в АН РТ о создании Центра евразийских исследований кочевых культур.*



*«Валеевские чтения». Тобольск. Декабрь, 2023.*



*Участники беседы «О вечном».*
*Р.Курчаков, Д.Исхаков и Н.Наккаш.*



*Рашида апа Курманова и Д.Исхаков после награждения на «Валеевских чтениях». Декабрь, 2023.*




*Выставка изделий учащихся и народных умельцев. Школа с. Нижняя Майна.*

*Татарстан Республикасының халык артисты, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе*

# *Гөлзадә Сафиуллина*

